ТАТАРСТАН

2’2000

TATARSTAN

ISSN 0869 - 5083

Илһам ШАКИРОВка ничә яшь соң?

Илһамыбыз - халык яшендә.

Рәсемнәрдә:
сессия
ачылган көнне.

В. ЗОТОВ һәм
С. ИСХАКОВ фотолары.

ПАРЛАМЕНТ старт алды

21 гыйнварда Татарстан Дәүләт Советына яңа сайланган ундүртенче чакырылыш халык депутатларының беренче сессиясе булды.

Гадәттәгечә, беренче сессиядә оештыру мәсьәләләре каралды. Дәүләт Советының җитәкче органнары сайланды, даими комиссияләр, парламент контроле комитеты оештырылды, Дәүләт Советында даими эшләячәк депутатлар ачыкланды.

Баш мөхәррир
Рифат ФӘТТАХОВ

ТАТАРСТАН

TATARSTAN №2 2000

РЕДКОЛЛЕГИЯ:
Флорид ӘГЪЗАМОВ,
Казан дәүләт университетының журналистика факультеты деканы,
Ислам ӘХМӘТҖАНОВ,
Татарстан газета-журналлар нәшрияты директоры,
Мөнир ӘҺЛИУЛЛИН,
баш мөхәррир урынбасары,
Зилә ВӘЛИЕВА,
Татарстан Республикасының матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникация чаралары министры,
Разил ВӘЛИЕВ,
Татарстан Дәүләт Советының Фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр даими комиссиясе рәисе,
Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,
академик, КДУның татар филологиясе факультеты деканы,
Марат ГАЛИЕВ,
Татарстан Дәүләт Советының Президиум әгъзасы,
Васил ГАРИФУЛЛИН,
КДУның татар журналистикасы кафедрасы мөдире,
Әнәс ИСХАКОВ,
Азнакай районы хакимияте башлыгы, район һәм шәһәр берләштерелгән Советы рәисе,
Гүзәлия МИНКИНА,
Мәскәү районы хакимияте башлыгы, район Советы рәисе,
Роберт МИҢНУЛЛИН,
Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары,
Ирек МОРТАЗИН,
Татарстан Президентының матбугат үзәге җитәкчесе,
Сәйфихан НАФИЕВ,
Татарстан Республикасы прокуроры,
Ринат НӘБИЕВ,
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Дин эшләре советы рәисе, профессор,
Булат СОЛТАНБӘКОВ,
профессор,
Илдус ТАРХАНОВ,
Татарстан Республикасы мәдәният министры,
Индус ТАҺИРОВ,
академик, Татарстан халык депутаты, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе,
Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ,
баш мөхәррирнең беренче урынбасары,
Рафаэль ХӘКИМОВ,
Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт киңәшчесе,
Илгиз ХӘЙРУЛЛИН,
Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары,
Рүзәл ЮСУПОВ,
Казан дәүләт педагогика университеты ректоры, академик.

Бүлек мөхәррирләре: Госман Гомәров, Солтан Исхаков, Гөлүсә Закирова.
Бизәлеш мөхәррире: Розалина Мусабирова.
Компьютер версткасын Татьяна Шмарина һәм Марат Сиразиев башкарды.
Гамәли хезмәткәрләр: Лариса Әхмәтова, Лүзия Әюпова, Клара Миңнуллина, Фирадия Хәйруллина.

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
Телефоннар:
баш мөхәррир - 43-55-62,
баш мөхәррир урынбасары - 49-36-68,
коммерция буенча баш мөхәррир урынбасары - 49-36-25,
җаваплы сәркәтип - 49-36-27,
баш бухгалтер - 43-54-33,
бүлек мөхәррирләре - 49-36-23,
фотокорреспондентлар - 43-51-92,
компьютер үзәге - 49-36-31, 49-36-29.

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Килгән хатлар, кульязмалар һәм рәсемнәр рецензияләнми, авторга кире кайтарылмый.

Производствога бирелде 27.01.2000.
Басарга кул куелды 21.02. 2000.
Кәгазь форматы 60/84 1/8.
Күләме 10 басма табак.
Заказ Э - 82. Тиражы 6500.

Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәү таныклыгы N 95.
Татарстан газета-журнал нәшрияты типографиясе.

Тышлыкның беренче битендә - Р. ЯКУПОВ фотосы

ЭЧТӘЛЕК



4 **Республика сулышы**

6 **Таныш булыгыз!**

Ф. Мөхәммәтшин.
8 **Җимермәскә, ә иҗади реформаларга...**

В. Заһитов.
12 **Безнең халык - кайсына лаек?**

14 **Чистай варианты**

16 **Авыл - ил тоткасы** *(Премьер-министр урынбасары, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры М. Әхмәтов белән интервью)*

19 **Җиләк-җимеш, яшелчә - барысы да күп бездә**

Илшат Ганиев:
20 **Яшелчә үстерү - фидакарьләр эше**

22 **Тәмле аша - озак яшә**

Ә. Мөниров.
24 **Җидегән йолдыз**

М. Абдулов.
26 **Казан сөт комбинатында ярыш**

В. Гарифуллин.
28 **Башка чыккан Максабашта**

Х. Ибраһим.
30 **"Вираж" яулаган үрләр...**

А. Хәсәнов.
33 **"Хуш, авылым!" диярге ашыкмыйк**

М. Әһлиуллин.
36 **Дала егете калада**

Иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни журнал
Оештыручылары: Татарстан Республикасы хөкүмәте һәм редакциянең хезмәт коллективы.
1920 елның декабрь аеннан башлап чыга.

Т. Авдеева.
Салым сәясәте ник аксый? *38*

Әйтер сүзем бар... *40*

Татар дөньясында *42*

И. Таһиров.
Революция һәм татарлар *43*

Ф. Мусин.
Гаяз Исхакый *48*

Т. Миңнуллин.
Һәйкәл итик хәтерне! *53*

Я. Шәфыйков.
Фикрәт Табеев *54*

М. Мәрдиева.
Тормыш белән бергә үзгәргән *62*

Казансу буендагы Бәйтулла-йорт *64*

Республикабыз - матбугат дәрьясында *69*

Ю. Сафиуллин.
Күз алмасы *70*

Галиҗәнап шигырь! *74*

Мәдәни манзара *76*

Эш беткәч *78*

БЕЗ - ИЛҺАМЛЫ ХАЛЫК!

Илһам Шакировка 65 яшь тулды. Бу датаны Татарстан радио-телевидениесе, республикабыз матбугаты да киң яктыртты. Күпсанлы тамашачылар да әлеге вакыйгага битараф калмады, алар хәтта Илһамның зур юбилей кичәсе булыр дип тә өметләнгәннәр иде. Дөрес, 65 яшь - рәсми юбилей түгел, диләр. Әмма Илһам Шакиров туган көн, аның юбилее - ул гадәти вакыйга гына түгел. Ул - тарихи әһәмияткә ия халык бәйрәме. Чөнки Илһам Шакиров ул - татар халкының кабатланмас даһи җырчысы. Ул - халкыбызның намусы һәм вөҗданы. Илһам - татар җыр сәнгатенең, татар халкының символына әйләнгән легендар шәхес.

Илһам Шакиров - безнең горурлыгыбыз, мактанычыбыз да, ул - безнең йөрәк ярабыз да. Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе И. Шакиров иҗаты безнең татар сәнгатендә, гомумән татар дөньясында, аерым бер урын алып тора. Аның иҗаты - үзе бер чор. Татар халкына төгәлләнеп килүче XX гасыр биргән бөек шәхесләр арасында, һичшиксез, Илһам Шакиров исеме дә бар.

Һич тутыкмас милли җәүһәрләребез булган татар халык җырларын, гомумән татар җыр сәнгатен Илһам Шакиров өр-яңа баскычка күтәрде, ул башкарган әсәрләр, классик дәрәҗәдә булып, татар мәдәниятенең "алтын фонд"ын тәшкил итә.

И. Шакиров гел юлда, гел гастрольдә. Мөгаен, ул булмаган бер генә шәһәр дә, бер генә татар авылы да юктыр. Халкыбыз өчен иң авыр гарасатлы елларда Илһам җырлары рухи юлдаш, рухи таяныч булды. Димәк, татар халкын саклап калуда Илһамның роле дә биниһая зур.

Ни кызганыч, без Илһамыбызны да дөньякүләм мәйданга чыгара алмадык. Без аңа бүген дә тиешле кадер-хөрмәтне, социаль яклауны күрсәтә алмыйбыз кебек. Бөекләрнең кадерен белмәү - татарның милли традициясе шул.

"Илһам Шакировка ничә яшь соң?" дигән сорауга халык шагыйре И. Юзеев: "Илһамыбыз - халык яшендә!" - дип җавап биргән иде. Әйе, Илһам һәм татар халкы - аерылгысыз бөек төшенчәләр. Халык яшәгәндә - Илһам яшәр. Ә җырлы халык, Илһамлы халык үлми. Без - Илһамлы халык!

Газ күбрәк киләчәк

19 гыйнварда Татарстан хөкүмәтенең һәм "Газпром" ачык акционерлык җәмгыяте җитәкчеләгенең 2000 елда үзара хезмәттәшлек мәсьәләләренә багышланган киңәшмәсе булды. Аның эшендә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев, Премьер-министр Рөстәм Миңнеханов, "Газпром" ачык акционерлык җәмгыяте идарәсе рәисе Рем Вяхирев, республиканың эре предприятие җитәкчеләре катнашты.

Киңәшмә барышында 1999 елда Татарстанны газлаштыру программасын гамәлгә ашыру йомгаклары тикшерелде, газ кулланучыларның бурычларын бетерү буенча "Татгазинвест" ябык акционерлык җәмгыятенең эшенә йомгак ясалды. Анда шулай ук нефть-химия комплексы предприятиеләрен чимал белән тәэмин итү мәсьәләләре, "Газпром" җәмгыяте белән уртак инвестиция проектлары каралды.

Олы кунак

Россия Федерациясе хөкүмәте рәисе урынбасары Илья Клебанов Казанда булды. Ул Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев белән С. П. Горбунов исемендәге Казан авиация берләшмәсе цехларында йөрде, коллектив белән очрашты.

Кунак Казанда җитештерелә торган ТУ-214 самолетына югары бәя бирде. Аның фикеренчә, бу лайнер бүгенге көндә конкурентлыкка сәләтле һәм ул Россия авиакомпанияләре өчен бик кирәк. Россия Федерациясе вице-премьеры, бүгенге көндә илебезнең авиация техникасын кулланучылар Россиядә җитештерелгән самолетларны сатып алу мөмкинлегенә ия булсын өчен шартлар тудырыла, дип искәртеп үтте.

Россия Федерациясе Премьер-министры урынбасары И. Клебанов шулай ук Казан дәүләт техник университетында студентлар, укытучылар, профессорлар белән очрашты.

Әтнәгә, тәҗрибә өйрәнергә

20 гыйнварда Әтнә районында 1999 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше йомгакларына, шулай ук терлекләрне кышлатуны оешкан төстә үткәрү мәсьәләләренә һәм кыр эшләренә әзерлеккә багышланган республика семинар-киңәшмәсе булды.

Семинар эшендә республика Президенты, Министрлар Кабинеты, Дәүләт Советы аппаратлары җитәкчеләре һәм җаваплы хезмәткәрләре, министрлык һәм ведомстволар, республика оешмалары һәм предприятиеләре җитәкчеләре, республика районнары һәм шәһәрләренең хакимият башлыклары, район авыл хуҗалыгы идарәләре начальниклары катнашты.

Премьер-министр Р. Миңнеханов промышленностьта җитештерүнең үсүен билгеләп үтте. Бу исә республикада күп кенә конкрет социаль программаларны үтәүгә мөмкинлек биргән.

- Февральдә пенсияләренең 20 процентка артуы көтелә. Минималь пенсия хәзер 575 сум булачак. Шуның белән без уртача яшәү минимумына чыгачакбыз, - диде М. Шәймиев.

Шушы уңайдан Президент социаль яклауны барлык районнарда максималь дәрәҗәдә адреслы итү бурычын куйды. Бүген мәгълүматларның компьютер банкын, урыннарда булышлык фондларын булдырырга, ярдәм итүнең башка вариантларын эзләргә кирәк.

Ромашкиноның киләчәге бар

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев, Премьер-министр Рөстәм Миңнеханов һәм Россия Федерациясе ягулык-энергетика министры Виктор Калюжныйның Казан Кремлендә очрашуы Ромашкино нефть ятмасының киләчәк язмышын хәл итүгә багышланды.

Билгеле булганча, дөньядагы ун эре җир мае чыганагының берсе булган Ромашкино ятмасы аны эшкәртүнең соңгы чорына керде. Икенче төрле әйткәндә, аның мае 80 процентка суланды һәм чыгаруы да бик кыенлашты. Хәзергә кадәр ике миллиард тоннага якын углеводород чималы биргән ятманы эшкәртү файдалы булмый башлады.

- Без Россия һәм Татарстан хөкүмәтләрен, шулай ук "Татнефть"не дә канәгатьләндерә торган хөкүмәтара килешүгә ирешергә тырышабыз, - диде Премьер-министр Р. Миңнеханов. - Илдә еш булып торган сәяси үзгәрешләр аны юкка чыгарырлык булмасын.

Хезмәттәшлек киңәя

17 гыйнварда Казан Кремлендә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев MRH фирмасы президенты Рудольф Кренинг белән очрашуы вакытында республикабызга

А. Титов фотосы.

углеводород чималы, табигый газ җибәрү һәм "Минеральойл Рош-тофф-Ханедль Гамбург" (MRH) немец фирмасының Татарстан белән уртак предприятиеләрдә катнашуын киңәйтү мәсьәләләре тикшерелде.

Татарстанда Германия компанияләренең "Татойлгаз" һәм "Петрокам" ябык акционерлык җәмгыятьләре белән ике уртак предприятие уңышлы эшли инде. Татарстан Президенты әйтүенә караганда, MRHның "Татнефть" һәм Түбән Кама "Нефтехим" белән берлектә гамәлгә ашыра торган барлык проектлары һәр ике якка керем китерә. Хәзерге очрашу уртак проектларны гамәлгә ашыруга яңа этәргеч бирергә тиеш.

Законнар гамәлгә керде

Гыйнвар аенда Татарстан Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителгән берничә закон гамәлгә керде. Шуларның берсе - "Халыкның санитария-эпидемия иминлеге турында". Әлеге закон халыкның санитария-эпидемия иминлеген тәэмин итүгә һәм гражданнарның сәламәт әйләнә-тирә табигать мохитенә хокукларын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән.

"Наркотик чараларның яисә психотроп матдәләрнең әйләнешенә һәм кулланылышына бәйле хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында" Закон гражданнарның сәламәтлеген саклау, дәүләт һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү максатларында наркотик чаралар куллануга бәйле рәвештә хокук бозулар өчен җаваплылыкны билгели.

"Кама Аланы махсус икътисадый зонасы турында" Закон бу эшчәләр бистәсендә махсус икътисадый зона төзүнең, аның эшчәнлегенең хокукый, икътисадый һәм оештыру нигезләрен билгели, ул конкуренциягә сәләтле продукция җитештерү, халыкны эш белән тәэмин итү өчен инвестицияләр, технологияләр җәлеп итүгә юнәлдерелгән.

Мәскәүдә сөйләшүләр

Татарстан Премьер-министрының беренче урынбасары Равил Моратов Мәскәүдә Россиянең стратегик эшләнмәләр үзәгенең күзәтчелек советы рәисе Герман Греф белән очрашты.

Бүгенге көндә нәкъ менә шушы үзәк ил тормышындагы барлык өлкәләрдә үзгәрешләр стратегиясен формалаштыра һәм ул Россия яңа Президентының эш-гамәлләре программасы булып торырга тиеш. Очрашу барышында Федерация һәм аның субъектлары үсеше стратегиясенә кагылышлы мәсьәләләр тикшерелде. Татарстанның соңгы елларда ирешкән казанышлары республиканың социаль-сәясәт, икътисадый программаларны тормышка ашыру нәтиҗәсендә мөмкин булуы хакында билгеләп үтелде.

Комбайннар, тракторлар кайта

Татарстанга Ростов-Доннан 55 "Дон-1500" комбайны кайтартылды. Бу - Россия машина төзүчеләреннән республика сатып алган яңа техниканың тәүге партиясе.

Татарстан хөкүмәте ашлык уручы 200 машина сатып алуга килешү төзеде. Үзебезнең илдә җитештерелгән комбайннардан тыш, быел Америкадан "Кейс" комбайннары сатып алыначак. Моның өчен "Татнефть" акционерлык җәмгыяте кредит бирде.

Волгоград заводы белән мең "ДТ-75" тракторы сатып алуга килешү төзелде. Аның 200 е Татарстанга кайтарылды да инде.

Татарстан корабы сынау үтә

Зеленодол суднолар төзү заводында чыгарылган "Самум" ракета корабына Балтыйк диңгезендә дәүләт сынавы төгәлләнде. Россиянең Хәрби диңгез флоты җитәкчелеге, корабның диңгездә йөзү сыйфатын югары бәяләп, аны кабул итү актына кул куйды.

"Самум"ны сынау вакытында оештырылган хәрби шартлар корабның йөзү тизлеге һәм оста хәрәкәт итүнең югары дәрәҗәсен күрсәтте. Белгечләрнең бәяләвенчә, куелган мәсьәләләрне кораб тиз арада чишәргә сәләтле.

Катамаран принцибы буенча ясалган "Самум" корабының йөзү тизлеге 50 узелдан да арта. Флотта "Самум" турында "Җилне генә уза алмый" дип әйтәләр. "Җиңел" алюминий-магний эретмәсеннән ясалган кораб корпусы маневрларның тиз башкарылуын тәэмин итүче җайланмалар белән җиһазландырылган. Ул заман таләпләренә туры килгән "Москит" ракеталарга каршы җайланма һәм зенит ракеталары белән коралландырылган.

ПАРЛАМЕНТ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕН САЙЛАДЫ

Фәрит Хәйрулла улы МӨХӘММӘТШИН - Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе.

Агымдагы елның 21 гыйнварында пленар сессиядә халык депутатлары вәкилләр киңәшмәсе тәкъдимен хупладылар һәм Дәүләт Советы Рәисе итеп Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшинны сайладылар. Яшерен тавыш бирү өчен бюллетеньнәр алган барлык 120 депутат Ф. Мөхәммәтшинны яклап тавыш бирде.

Ф. Мөхәммәтшин - Татарстан Республикасы халык депутаты, аны 122 нче Шөгер территориаль округы буенча Лениногорск районының Тимәш авылы сайлаучылар җыелышы тәкъдим иткән. Ул 1947 елның 22 маенда Әлмәт шәһәрендә туган. Әлмәт газ промышленносте техникумын, Уфа нефть институтын, Саратов Югары партия мәктәбен тәмамлаган. "Дуслык" ордены белән бүләкләнгән.

Хезмәт юлын 1963 елда Әлмәт шәһәренең Ленин комсомолы исемендәге газ-бензин заводында токарь булып башлаган, Совет Армиясе сафларында хезмәт иткән. Әлмәт бораулау тресты конторасы шоферы, "Әлмәтнефть" идарәсе контроль-үлчәү приборлары слесаре, ВЛКСМның Әлмәт шәһәр комитеты инструкторы, халык депутатларының Әлмәт шәһәр Советы башкарма комитеты рәисе урынбасары, беренче урынбасар, КПССның Әлмәт шәһәр комитеты секретаре, икенче секретарь, халык депутатларының Әлмәт шәһәр Советы башкарма комитеты рәисе, Татарстанның сәүдә министры, КПССның Әлмәт шәһәр комитеты беренче секретаре, Татарстан АССРның Министрлар Советы Рәисе урынбасары, Югары Совет Рәисе, Премьер-министр, Дәүләт Советы Рәисе булып эшләде.

Ирина Андреевна ЛАРОЧКИНА - Дәүләт Советы Рәисе урынбасары.

Ирина Андреевна Ларочкина Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары итеп сайланды. Ул - Татарстан халык депутаты. Аны 89 нчы Алиш территориаль сайлау округыннан "ТатНИПИнефть" институты сайлаучылар җыелышы тәкъдим иткән.

И. А. Ларочкина 1950 елның 14 гыйнварында Әлмәт шәһәрендә туган. В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетын, Мәскәүнең Плеханов исемендәге халык хуҗалыгы институты каршындагы менеджерлар әзерләү үзәген, Целле шәһәрендәге (Германия) менеджмент академиясен тәмамлаган. Геология-минералогия фәннәре докторы, Татарстан Республикасының атказанган фән һәм техника эшлеклесе.

Хезмәт юлын 1972 елда Бөгелмә шәһәренең "ТатНИПИнефть" институтында инженер булып башлый һәм бөтен баскычларны үтеп, институтның бүлек мөдиренә кадәр күтәрелә.

Роберт Мөгаллим улы Миңнуллин Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары итеп сайланды. Ул - Татарстан халык депутаты. Аны 129 нчы Сарман район үзәк хастаханәсе сайлаучылары җыелышы тәкъдим иткән.

Роберт Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН - Дәүләт Советы Рәисе урынбасары.

Р. М. Миңнуллин 1948 елның 1 августында Башкортстанның Илеш районында туган. В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетын тәмамлаган. Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Башкортстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре. Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты. Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнгән. Дәүләт Советының үткән чакырылышында мәдәният һәм милли мәсьәләләр даими комиссиясе рәисе иде.

Алексей Иванович Демидов Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары итеп сайланды. Ул - Татарстан халык депутаты. Аны 25 нче Алексеевск административ-территориаль сайлау округыннан Алексеевск сөт консервы комбинаты унитар предприятиесе сайлаучылары җыелышы тәкъдим иткән.

Алексей Иванович ДЕМИДОВ - Дәүләт Советы Рәисе урынбасары.

А. И. Демидов 1952 елның 20 мартында республикабызның Лаеш районы, Среднее Девятово авылында туган. М. Горький исемендәге Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган. "Дуслык" ордены белән бүләкләнгән.

Хезмәт юлын 1969 елда Лаеш районының "Россия" совхозында эшчедән башлый. Һәм шул ук совхозның директоры дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Аннан - халык депутатларының Алексеевск район Советы башкарма комитеты рәисе, КПССның район комитеты беренче секретаре, халык депутатларының Алексеевск район Советы рәисе, район хакимияте башлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары. Бүгенге көндә - халык депутатларының Алексеевск район Советы рәисе һәм район хакимияте башлыгы, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары.

Валентина Николаевна Липужина Татарстан Республикасы Дәүләт Советы секретаре итеп сайланды. Аны 112 нче Биләр территориаль сайлау округыннан Алексеевск районының Биләр авылы сайлаучылар җыелышы тәкъдим иткән.

Валентина Николаевна ЛИПУЖИНА - Дәүләт Советы секретаре.

В. Н. Липужина 1943 елның 1 апрелендә Алексеевск районының Балахчино авылында туган. Алабуга дәүләт педагогия институтын тәмамлаган. Ике тапкыр "Почет билгесе" ордены, өч медаль, Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнгән.

1964 елда ВЛКСМның Алабуга шәһәр комитетының икенче секретаре, беренче секретаре, ВЛКСМ өлкә комитетының бүлек мөдире урынбасары, укучы яшьләр белән эшләү буенча секретарь, КПССның Татарстан өлкә комитетының фән һәм уку йортлары бүлеге мөдире урынбасары, КПССның Казан шәһәре Бауман район комитеты беренче секретаре, халык депутатларының Бауман район Советы башкарма комитеты рәисе, Бауман районының хакимият башлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими нигездә эшләүче халык депутаты, социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эше даими комиссиясе рәисе урынбасары, Дәүләт Советы секретаре.

Фәрит МӨХӘММӘТШИН,
Татарстан Дәүләт Советы Рәисе,
Россия Федерациясенең
Федерация Советы әгъзасы.

Җимермәскә, ә ИҖАДИ РЕФОРМАЛАРГА...

(Федерализмны үстерүнең кайбер тенденцияләре)

Россия һәм Татарстан дәүләт органнары арасында 1994 елның 15 февралендә кул куелган Шартнамә федерацияне демократик формалаштыруның мөһим факторы булды. Шуның белән бергә, бу документның нормаларын һәм положениеләрен, яңа тип федератив мөнәсәбәтләр урнаштыруда аның әһәмиятен ирекле аңлату җәмгыятьтә кайнар сәяси һәм фәнни бәхәсләр тудыра.

Россиянең федератив мөнәсәбәтләренең бүгенге торышы һәм үсеш перспективаларының иң актуаль проблемаларының берсе булуы бераүгә дә сер түгел. Федерализм социаль тотрыклылык тәэмин итү һәм бердәм дәүләт үсешенең шарты булып тора. Унитар дәүләттән аермалы буларак, реаль федерализм сәяси процесс субъектлары энергиясен күп кенә проблемаларны конструктив хәл итү юнәлешенә борырга, каршылыкларны цивилизацияле рәвештә чишәргә мөмкинлек бирә.

Хәзергә Россиядә ныклы демократик традицияләр формалашмаганлыктан, тулы кыйммәтле гражданлык җәмгыяте төзелмәгәнлектән, нәкъ менә федератив система барлык дәрәҗәдәге хакимиятләр арасындагы мөнәсәбәтләрне тотрыкландыруга ярдәм итәргә, аларның бербөрсенә карата башбаштаклыгыннан үзенчәлекле сакчы ролен дә үтәргә тиеш була. Шунлыктан бүген Россия Президенты вазыйфаларын башкаручы В. Путинның: "Россияне күтәрү һәм яңартуның ачкычы бүген сәяси тармакта... Россиядәге көчле дәүләт хакимияте - демократик, хокукый, эшкә сәләтле федератив дәүләт ул", - дигән тезисы белән килешми мөмкин түгел ("Независимая газета", 30.12.99).

Илебез тарихының борылыш мизгелендә Татарстан яңа федератив дәүләт моделен төзү механизмын башлап эзләүче булды. Шуңа карамастан, республиканың һәр адымы Россиянең бөтенлегенә куркыныч ясау буларак та кабул ителә. Әмма Татарстан тәкъдим иткән вариантның демократияне ныгытуга китерүен, Россияне ныклы федерализм юлына чыгаруын тормыш үзераслады инде.

Шартнамә төзүгә китергән вакыйгаларны искә төшерүне кирәкле саныйм.

1990 елның июнендә РСФСР, СССР составында булганда ук, Россиянең дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул итте. Россия Федерациясе суверенлыгын игълан итеп Халыкара хокук принциплары һәм нормалары тарафдары булуын, демократик хокукый дәүләт төзергә омтылышын күрсәтте. Алга таба үзенең статусын ныгыту өчен ике референдум үткәрелде. 1991 елның 17 мартында РСФСР Президенты постын булдыру, 1993 елның 12 декабрендә Россия Федерациясенең яңа Конституциясе проекты буенча.

Бу процесста Татарстан Республикасының позициясе РСФСРның башка субъектларыннан аерылып торды. 1990 елның 30 августында Татарстан Югары Советы дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул итте. Ул республиканың күпмилләтле халкы тарафыннан игълан ителде. 1992 елның мартында дәүләт статусын күтәрү, Россия һәм Татарстан арасында мөнәсәбәтләрне килешүләр нигезендә урнаштыру буенча референдум уздырылды. Соңрак (1992 елның ноябре) халык теләге республиканың яңа Конституциясендә ныгытылды.

Россиянең 1993 елның декабрендә референдум юлы белән кабул ителгән яңа Конституциясенең республика сайлаучыларында яклау тапмавын аеруча билгеләп үтәргә кирәк, шул ук вакытта Татарстанда Россия Федерациясенең беренче чакырылыш Дәүләт Думасына сайлаулар үткәрелмәде. Бу исә киләчәктә республика нинди юлдан барырга тиеш, Россиядә яңа федерацияне ничек реформаларга һәм оештырырга дигән сорауларга Татарстан халкының катгый җавабы да иде. 1922 елда Татарстанның ССР Союзының мөстәкыйль соучредителе булуы да мөһим тарихи факт булып тора. Үз вакытында Россия империясе, аннары РСФСР составына ирекле рәвештә кергән субъектлардан аермалы буларак, Татарстан бервакытта да андый сәясиюридик акт кабул итмәгән.

90 нчы еллар башында Россия - Татарстан мөнәсәбәтләрендә килеп туган сәяси-хокукый билгесезлекне ике як өчен дә кулай сәяси алымнар белән хәл итәргә кирәк иде. Бу чорда мөнәсәбәтләрне килешү нигезендә урнаштыру хакында 1991 елның 15 август беркетмәсе дә гамәлгә керде, сөйләшүләрнең өч еллык тәҗрибәсе дә тупланды.

Татарстанның эшчәнлеге һәрвакыт халыкара хокук нормаларына нигезләнде, ә һәр халык үзбилгеләнү хокукына ия. Икътисадый, социаль һәм мәдәни хокуклар; гражданлык һәм сәяси хокуклар турындагы халыкара пактлар (1966 ел) нигезендә һәр халыкның, кайда яшәвенә карамастан, үзбилгеләнү хокукы бар. Һәр халык үзенең сәяси статусын ирекле билгели, икътисадый, социаль һәм мәдәни үсешен тәэмин итә, үзенең табигый байлыкларыннан һәм ресурсларыннан файдалана. Пактта катнашучы барлык дәүләтләр (шул исәптән Россия дә) үзбилгеләнү хокукын гамәлгә ашыруны хупларга, бу хо-

И. Зәйнетдинов фотосы.

Бу тарихи документка беренче Президентларыбыз - М. Шәймиев һәм Б. Ельцин кул куйды.

кукка хөрмәт белән карарга тиеш.

СССР катнашында БМО тарафыннан кабул ителгән халыкара хокук принциплары турындагы Декларациядә халыкларның үзбилгеләнү хокуклары кодлаштырылды. Суверен һәм бәйсез дәүләт төзү, бәйсез дәүләткә ирекле кушылу яки аның белән берләшү аны гамәлгә ашыру чаралары булып торалар. Шул ук вакытта халыкара бергәлек бу алымнарның барысының да халыкларның үзләре тарафыннан ирекле рәвештә, читтән басымсыз башкарылуын таләп итә.

Югарыда күрсәтелгән алшартлардан һәм халыкара хокук нормаларыннан чыгып, 1994 елның 15 февралендә Россия һәм Татарстан арасында "Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында" Шартнамә төзелде.

Шартнамә - барыннан да бигрәк Татарстанның Россия белән РФ Конституциясе, ТР Конституциясе, дәүләт вәкаләтләрен үзара ирекле рәвештә алмашкан килешү нигезендә берләшкән махсус статусын билгеләүче сәяси документ. Болай билгеләү Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы белән мөнәсәбәтләрдә РФ Конституциясенә генә түгел, вәкаләтләрнең бу документта каралган күләмендә Шартнамә нормаларына да таянырга тиешлеген белдерә.

Шартнамәнең гамәлдә булу вакыты чикләнмәгән, федераль законнарны да кертеп, берәүгә дә аны берьяклы рәвештә яңадан карарга, аңа ревизия ясарга ярамый. Ул эшләр бүлешү һәм республика вәкаләтләре кысаларында Татарстанның үз законнарын формалаштыру мөмкинлеген күздә тота. Шунлыктан Дәүләт Думасы тарафыннан 1999 елда кабул ителгән "Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары арасында эш бүлешү һәм вәкаләтләрне чикләү принциплары һәм тәртибе турында"гы Закон Россия һәм Татарстан арасында Шартнамә нигезендә урнаштырылган мөнәсәбәтләргә кагыла алмый. Федераль законда каралган вәкаләтләрне чикләү түгел, ә ике дәүләтнең ирекле рәвештә аларны үзара алмашуы Шартнамә темасы булып тора. Россия - Татарстан Шартнамәсенең бу законнан концептуаль аермасы нәкъ менә шунда да инде.

Бу тарихи документка кул куюга алты ел үткәч аның әһәмиятенә лаеклы бәя бирергә мөмкин инде.

Шартнамә:

- Россиянең яңа тарихында тиңе булмаган вакыйга. Ул Татарстанның дәүләт суверенлыгы Декларациясен, республика референдумы йомгакларын, республиканың яңа Конституциясен Россия Федерациясенең фактик рәвештә тануы булып тора;

- сәяси реализмның җиңүе, Россия дәүләтчелегенең беренче өч елындагы низаглы хәлләр һәм киеренкелек сәяси алымнар белән хәл ителде. Бу - Россия һәм Татарстан мөнәсәбәтләрендә тарихи этап, аларны ирекле рәвештә килешү нигезендә берләштерүче беренче юридик документ;

- Россиядә һәм Татарстанда сәяси тотрыклылыкны ныгытуда җитди адым. Шартнамәгә кул куелу республикада яшәүче барлык милләт вәкилләрен тынычландырды, милләтара мөнәсәбәтләрдә киеренкелек туу мөмкинлеген юкка чыгарды, Россия Федерациясеннән чыгу зарурлыгын алга сөрүчеләрнең дә, унитаризм позициясендәге радикаль караштагы торучы сәясәтчеләр фикерләренең дә нигезсезлеген күрсәтте;

- демократик принципларда Россия дәүләте эволюциясе өчен куәтле импульс тудырды. Бу процесска каршы торучы күп кенә сәяси көчләр булса да, Россия җитәкчелеге дөнья җәмәгатьчелеге алдында Федерация төзелешендә демократик, хокукый алымнар ягында булуын күрсәтте.

Ниһаять, Шартнамәнең халыкара әһәмияте турында аеруча басым ясап әйтергә кирәк. Бүген дөньяда низаглы нокталар аз түгел. Аларда безнекенә охшаш проблемалар уннарча еллар буе хәл ителә алмый. Еш кына алар кораллы бәрелешләргә әверелә. Бу мәгънәдә Татарстанның мөстәкыйльлеге һәм территориаль бөтенлекне саклау арасындагы каршылыкларны бетерүгә мөмкинлек тудыручы вәкаләтләрне федераль үзәккә бирү белән бергә, халыкара хокук субъекты элементлары булган дәүләт статусын беркетү белән Шартнамә низаглы хәлләрне көйләүдә чын мәгънәсендә үрнәк булып тора ала.

Бүген үзәкнең Федерация субъектлары белән мөнәсәбәтләрен килешүләр аша формалаштыруы дәүләт төзелеше практикасына ышанычлы рәвештә керә бара. Төбәкләрнең яртысыннан артыгы без салган юлдан бара. Шунлыктан кайбер төбәк җитәкчеләренең "компетенцияләрне чикләүнең килешүләр тәртибе үзенең камил булмавын күптән раслады, шунлыктан... авызлыклауга мохтаҗ", дигән фикерләре гаҗәпсенү уята (А. Усс. "Тигез мөмкинлекләр федерациясе". "Известия", 11.08.99).

Тупланган позитив тәҗрибәне дәлилсез тәнкыйтьләүнең аңлау табуы шикле. Федераль һәм төбәк хакимият органнары арасында килешүләр гамәлен үстерүнең федератив мөнәсәбәтләрне ныгытуның, якларның хокуклары һәм җаваплылыгы балансл системасын формалаштыруның, территорияләрнең һәм үзәкнең үзара йогынтысы нәтиҗәле механизмын тудыруның мөһим кон-

ституцион инструмент булуы бүген федераль дәрәҗәдә танылды инде. Хәтта кайбер юридик коллизияләр булуга карамастан, ә алар хәл ителерлек, килешүләрнең эшләве, якларның бер-берсен аңлавын һәм килешеп яшәвен ныгытуы бәхәссез. Бары тик шулар базасында гына Россия Федерациясенең бөтенлеген ныгытучы хокукый җирлек формалаштырырга мөмкин.

Россия җәмгыятенең тулы канлы федерация төзү өчен бөтен мөмкинлекләре бар. Әмма демократик үзгәртеп коруларга күпчелек очракларда элеккеге вакытлардан мирас итеп алынган реформаларны өстән кушканча, төбәкләр белән киңәшмичә, кешеләрнең тормыш дәрәҗәләрен саклау гына түгел, аларны күтәрә төшү максатыннан социаль амортизаторларны кулланмыйча үткәрү тормоз булып торды.

Җәмгыятьтә килеп туган хәл үзәк һәм төбәкләрнең мөстәкыйльлеге эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген гарантияләүче анык һәм үтәлә торган, барысы өчен дә файдалы кагыйдәләр эшләүне катгый төстә таләп итә. Андый кагыйдәләр моделе гамәлгә кергән килешү - конституцион мөнәсәбәтләр тәҗрибәсенә дә шактый дәрәҗәдә салынган. Алар икътисадый, милли-мәдәни һәм башка тормыш үзенчәлекләрен искә алып Федерация субъектлары вәкаләтләрен конкретлаштыралар. Бу тәҗрибәне бары хупларга һәм үстерергә генә кирәк.

Әмма элеккечә үк Россия һәм Татарстан Шартнамәсе, аның бигрәк тә бюджетара мөнәсәбәтләрдә РФ Конституциясе һәм законнары нормаларына хокукый тәңгәл килүенә кагылышлы мәсьәләләрдә сәяси бәхәсләр тынмый әле. Турысын әйткәндә, бик үк аңлашылып бетми: моның артында килешү мөнәсәбәтләре тәҗрибәсенең дәрәҗәсен төшерергә омтылу ятамы, сәяси сукырлыкмы бу, әллә унитаризм чорына кайтуга омтылышның оста яшерелгән теләгеме? Чынлап уйлаганда, бу проблеманың мәгънәви һәм хокукый нигезе бөтенләй юк бит.

РФ Конституциясенең 11 нче маддәсенең өченче пункты нигезендә Россия Федерациясе һәм федерация субъектларының дәүләт хакимияте органнары арасында эш бүлешү һәм вәкаләтләр алмашу РФ Конституциясе, федератив һәм башка килешүләр белән башкарыла.

Безнең Шартнамә нигезендә федераль бюджет, федераль салымнар һәм җыемнар, төбәк үсешенең федераль фондлары Россия Федерациясе карамагында калдырыла (РФ Конституциясенең 71 нче маддәсе "з" пунктында да шундый ук норма каралган); республика бюджетын формалаштыру, республика салымнарын билгеләү һәм аларны җыю Татарстан Республикасы карамагында. РФ Салым кодексының 12 нче маддәсе нигезендә, бирелдә каралганнан тыш, төбәк һәм җирле салымнар, җыемнар билгеләнә алмый. Әмма бу положениене РФ Конституциясе нормалары белән бергә кулланырга кирәк. 72 нче маддәнең "И" пункты буенча РФда салымнар һәм җыемнар билгеләүнең гомуми принципларын РФ һәм аның субъектлары бергәләп хәл итәләр. 73 нче һәм 76 нчы маддәләр нигезендә субъектлар бу мәсьәләләр буенча хокукый көйләүне, шул исәптән законнар һәм башка хокукый норматив актлар кабул итүне гамәлгә ашыралар.

Шуның белән бергә, Россиянең федераль салымнар һәм җыемнарны билгеләүгә хокукы аның субъектларының илдә салымнар һәм җыемнарның гомуми принциплары кысаларында үз салымнарын һәм җыемнарын билгеләү буенча конституцион хокукларын чикләми. Федерация субъектларының бу хокукын РФның Конституция суды да раслады (1996 елның 4 апрелендәге П-N 9 карары). Моннан тыш федераль салымнарның бер өлешен республика бюджетына бирү дә федераль законнарга каршы килми ("Россия Федерациясендә салым системасы нигезләре турында" Законның 19 нчы маддәсе). Бу положение РФның 2000 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кергән Бюджет кодексында да чагылыш тапты (7, 48, 50, 52, 56 маддәләр).

Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасы арасында бюджет мөнәсәбәтләре турындагы хөкүмәтара килешүдә РФ Конституциясенең 78 нче маддәсенең икенче пункты нигезендә республикабыз территориясендә федераль структураларны, программаларны һәм чараларны финанслау буенча РФ хөкүмәтенең үз вәкаләтләренең бер өлешен ТР хөкүмәтенә тапшыруы ачык билгеләнгән. Салымнарның килешүдә каралган өлеше шуларны финанслауга җибәрелә. Әлеге килешү Шартнамәдә каралган вәкаләтләр алмашуны гамәлгә ашыруның бер механизмы булып тора.

Россия бердәмлеге белән генә түгел, аерым өлешләренең бер-беренә охшамавы белән дә көчле. Аның көче шунда да! Безнең барыбызга да шушы үзенчәлеккә һәм тарихи өстенлеккә таянырга кирәк. Федераль үзәк һәм федерация субъектлары арасындагы мөнәсәбәтләрне шулай урнаштырырга кирәк ки, аларны гамәлгә ашыру сәяси, икътисадый һәм социаль яктан барысына да отышлы булсын. Федераль үзәкне артык вазыйфаларыннан бушатырга, аларны акчалары белән бергә төбәкләргә тапшырырга кирәк. Ул чагында үзәк үзенең көчен илнең бөтенлеген, куркынычсызлыгын тәэмин итүче мөһим стратегик вазыйфаларны гамәлгә ашыруга туплый алачак. Моннан тыш, хакимият системасы социаль идарә мәсьәләләре турыдан-туры Федерация субъектлары хакимияте органнары компетенциясендә булырлык итеп корылырга тиеш. Төбәкләрдәге сәяси һәм икътисадый тотрыклылык аларның мөстәкыйльлегенә бәйле. Ә бу исә үз чиратында дәүләт тотрыклылыгының мөһим шарты булып тора.

1998 елның август вакыйгалары моның ачык мисалы. Федераль хакимият финанс базары җимерелүеннән каушап калды, һәр нәрсәнең асты-өскә килүеннән бары тик субъект җитәкчеләре генә коткара алды, алар оператив чаралар күрделәр. Бу сабак мондый хәлләрнең кабатланмавы өчен җәмгыятькә ныклы гарантия кирәк булуын күрсәтте. Язмышны хәл итүче карарларны Федерация субъектлары белән килештермичә кабул итәргә ярамый.

Үзара ярдәм итешү тибындагы мондый модельнең законнар нигезендә формалаша башлавы бик мөһим. Татарстан - Россия Шартнамәсе, 1999 елда тагын биш елга озайтылган 12 хөкүмәтара килешүдән торган пакет бу процесска һөҗүмчәнлек характеры бирде.

Россия Федерациясендә тормыш эшчәнлеге, менталитет, халыкларның тарихи үсеше буенча бер-берсеннән нык аерылучы уннарча милләтләр, этник төркемнәр яши. Шунлыктан үзәк һәм федерация субъектлары арасындагы үзара ярдәмләшү алымнарын асимметрик төзү нигезендә генә яңа федераль дәүләтчелекнең барлыкка килүе гадәти күренеш буларак күздә тотыла. Бу инде de facto да. Шуның

ДӘҮЛӘТ ЯЗМЫШЫ - ХАЛЫК ЯЗМЫШЫ

белән бергә, мөнәсәбәтләрнең асимметриялеге аерым сәясәтчеләрнең субъектив теләгеннән чыгып кына формалашмый. Бу объектив хәлләр нәтиҗәсендә туа. Шунлыктан мөнәсәбәтләрдәге яңа принципларны җимерергә, тарихи процессны кирегә борырга омтылу яңа сәяси проблемаларга китерергә, Россияне федератив дәүләт буларак көчсезләндерергә мөмкин. "Россия сәяси һәм социаль-икътисадый тетрәнүләр, катаклизмнар, радикаль үзгәрешләр лимитын бетерде... Базар икътисадының һәм демократиянең универсаль принципларын Россиянең реаль тормышы белән органик бәяләп кенә без лаеклы киләчәккә өметләнә алабыз" (В. Путин. "Независимая газета", 30.12.99).

Россия - Татарстан Шартнамәсен гамәлгә ашыру тәҗрибәсе якларның мөнәсәбәтләрендәге сәяси тотрыклылыкны гына чагылдырып калмый, төбәк мәнфәгатьләрен үстерүнең тулаем Россия өчен яңа һәм актуаль булган икътисадый инструмент барлыкка килүен дә күрсәтә. Чыннан да, дистә еллар буе үзәктән төбәкләрне дотацияләү (аерым бәяләмәләргә караганда 79 дан 59 га кадәр) кебек ялгыш система башкаларга салыну гадәтен тудырды, аларның үсеш дәрәҗәсен бер адымга да тигезли алмады.

Дәүләтне кирәгеннән артык үзәкләштерүнең күпгасырлык традициясе булган Россия, байлыгы булуга карамастан, халык тормышын чәчәк атуга китермәде, бүгенге шартларда ул кайчанга караганда да демократик үсеш нигезләрен саклауга мохтаҗ. Дәүләт төзелешендә бу федерализмны югарыдан түгел, түбәннән формалаштыруны аңлата. Хәзергә Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы белән Шартнамәсе бу процесстагы күп булмаган активларның берсе.

Тупланган тәҗрибә Россиянең дәүләт төзелеше нигезенә гомуми мәнфәгатьләр хакына прагматик карашны һәм хакимият мөнәсәбәтләре субъектлары иреген үзе теләп чикләүне берләштергән принцип салынырга тиешлеген күрсәтә. Шуның белән бергә, биредә реформалар үткәрүдә дәүләтнең ролен һәм әһәмиятен йомшарту турында сүз бармый. Бүгенге чорда кризистан котылу дәүләтнең көйләүче ролен көчәйтүдән башка була алмавына нык ышанам.

Россиянең федератив дәүләт төзелеше бербөтенгә көч белән түгел, ә файда исәбенә (социаль-икътисадый һәм милли-сәяси) цементланырга тиеш. Безгә сайлаучылары алдында җаваплы, аларның көндәлек ихтыяҗларына максималь якынайтылган хакимият кирәк. Менә шуның өчен дә төрле дәрәҗәдәге хакимиятләрнең үзара бәйләнешенең яңа стиле федератив дәүләтчелекне ныгытуның мөһим факторына әверелергә тиеш. Биредә сүз үзәкнең төбәкләр белән даими диалогы, хезмәттәшлекнең төрле формалары, кабул ителә торган карарларны килештерү механизмы турында бара.

Россия тарихи яктан күпмилләтле дәүләт буларак формалашты. Нәкъ менә шуның өчен дә һәр халык тарафыннан гасырлар буе тупланган кыйммәтләрне саклау һәм ишәйтү, төбәкләр һәм тулаем федерация күләмендә интеграция процессларын көчәйтү мөһим.

Гомумдәүләт күләмендә үткәрелә торган демократик этносәяхәт бүгенге шартларда бигрәк тә мөһим. Хәзергә ул бары дәүләт концепциясе кысаларында гына билгеләнгән, гамәлдә Россиянең бөеклегенә, тарихи миссиясенә җавап бирми. Мин бу хакта очраклы төстә генә әйтмим. СССР билгеле дәрәҗәдә аның язмышы өчен җаваплы кешеләрнең милли мәсьәләләрне хәл итмәүнең илне кая алып баруын аңламаулары сәбәпле дә таркалды. Шул ук вакытта "милли мәсьәлә иске режимнан мирас итеп алынган рәвештә тулысынча һәм ахырга кадәр хәл ителде" дигән нәтиҗә ясалды. Әмма милли мәктәпләрнең, милли мәдәният учреждениеләренең, туган телдә белем бирүнең торышы берәүне дә кызыксындырмады. Аларны бетерүгә юл тотылды. Милли телләр бетәргә тиеш дип саналды. Һәм алар бетә барды. Дәүләт бердәмлегенең мөһим факторы булган халыкларның үзенчәлеге югала барды. Һәм менә шуның нәтиҗәсе: туган телен белмәүче, милли мәдәният белән кызыксынмаучы берничә буын барлыкка килде. Милли мәсьәлә менә шул рәвешле гамәлгә ашырылды.

Кызганыч ки, бүген дә, яңа гасыр бусагасында торганда, күпмилләтле Россия тормышындагы катлаулы милли проблемаларны хәл итүне гадиләштерергә омтылучылар да бар. Милли республикалар үзенчәлеген искә алмыйча күп кенә карарлар кабул ителә.

Россия - күпмилләтле ил. Шунлыктан Россиянең куркынычсызлыгын тәэмин итүче, аның барлык халыкларының милли горурлыгын һәм кыйммәтләрен саклау, үстерү сәясәте үткәрү федераль хакимиятнең бурычы булып тора. Шунсыз - җәмгыятьтә милләтара килешеп яшәүне һәм гражданлык килешүен ныгыта бару мөмкин түгел.

Берәүне дә автономия төзү хокукыннан мәхрүм итәргә ярамый. Этнос буларак саклану, үсеш өчен һәр халыкка сәяси, мәдәни-икътисадый киңлекне үзләштерү мөмкинлеге тудырырга кирәк. Дәүләт - республикалар рәвешендәге югарырак формалар да (Татарстан, Башкортстан, Саха-Якутия) яки башка төрләрнең дә булуы мөмкин.

Россия дәүләтенең бөтенлеген һәм бердәмлеген тәэмин итү, федерациянең состав өлеше булган халыкларның мәнфәгатьләрен искә алу өчен аларның вәкиллекләрен федераль органнарда беркетү зарурлыгына нык ышанам. Бүгенге көнгә бу мәнфәгатьләр гомумфедераль дәрәҗәдә якланмаган әле. Федерация Советы әгъзалары конкрет этник төркемнәр мәнфәгатен түгел, ә төбәкләрнекен яклыйлар. Шунлыктан РФ Президенты каршында яки Федераль Җыелышның Милләтләр палатасы сыйфатында милли мәнфәгатьләрне кайгыртучы махсус вәкиллекле орган оештыру чын мәгънәсендә зарур булыр иде.

Бергә яшәүнең отышлы булуын аңлаучы субъектларның мәнфәгатьләр берлеге Федерацияне саклау өчен бердәнбер гарантия булып тора. Җәмгыятьтәге процесслар күрсәткәнчә, бүген барыбызга да Россия федерализмы конституциячел характеристикаларын үзгәртү, тагын да үстерү, шул исәптән якларның бергәләп эш итүләре, мәнфәгатьләрен килештерү принципларында формалашкан конструктив хезмәттәшлек, төрле дәрәҗәдәге хакимият органнары мөнәсәбәтләрендәге ышаныч дәрәҗәсе җәмгыять яшәешенең демократик алымнарын сүздә генә түгел, гамәлдә дә гәүдәләндерүче бердәм хакимият системасы төзү өчен бик күп көч куярга кирәк.

Без шундый Россия Федерациясе ягында!

БЕЗНЕҢ ХАЛЫК - кайсына лаек?

(26 март - Россия Федерациясе Президентын сайлаулар көне)

26 март көн якынлашкан саен Россия Федерациясе президенты посты өчен көрәш тә кискенләшә бара. Татарстан халкы Россия хакимен беренче тапкыр сайлауларда катнашмаса да, соңрак, ике арада Шартнамә төзелгәннән соң, мондый процесслардан читтә кала алмый башлады. Менә быелгы сайлаулар да республикабызда зур резонанс тудырды. Һәм һәрвакыттагыча татарстанлылар үз җитәкчеләренең позициясенә битараф түгел.

Тиздән узачак сайлауларда Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиевнең Россия Президенты вазыйфаларын башкаручы Владимир Путин кандидатурасын яклап чыгуы төрле сораулар, бәхәсләр тудырды. Янәсе, ничек инде, әле узган елгы Дума сайлауларында гына Путин яклы "Бердәмлек" хәрәкәтенә оппозициядә торган һәм булачак ил башы ролендә бары тик Евгений Примаковны гына күргән Минтимер Шәрипович кинәт кенә башка лагерьга күчте? Президентыбыз инициативасы белән оешкан "Бөтен Россия" хәрәкәтенең президент сайлауларында Владимир Владимировичны якларга ниятләнүе дә күпләргә аңлашылмый. Һәм, ниһаять, "Ватан - Бөтен Россия" идеологиясен, Евгений Примаков фигурасын үзенә бик тә якын күргән "Татарстан - яңа гасыр" хәрәкәтенең шушы агымга кушылуы кайберәүләрдә гаҗәпләнү тудырмый калдырмагандыр.

Боларга аңлатма бирүе һич кыенлык тудырмый. Сәяси вәзгыять даими үзгәреп тора. Бу үзгәрешләрне вакытында тоя һәм аларга дөрес җавап бирә белү - сәясәтче өчен иң мөһиме. Мәгълүм булганча, Дәүләт Думасына 19 декабрьдә узган сайлаулар һәм Борис Ельцинның үз постыннан вакытыннан алда баш тартып, варисы буларак Премьер-министр Владимир Путинны игълан итүе Россиядәге сәяси хәлне кискен үзгәртте. Россиядәге иң зур кәнәфине күпләр дәгъва итсә дә, реаль көчкә ия булган бердәнбер кандидат булып нәкъ менә Путин гына калды. Ә инде сайлауларның срогыннан алда, март азагында узачагы билгеле булгач, аналитиклар Владимир Владимировичның җиңүгә мөмкинлекләре тагын да артуын фаразладылар. Әле кайчан гына теше-тырнагы белән ил җитәкчелегенә Путинны утыртуга каршы булган сәясәтчеләр тиз арада аны якларга кереште.

Чынлап та, мондый шартларда агымга каршы бару мәгънәсезлек булыр иде. Россия Федерациясендә беренчеләрдән булып Путинны яклау буенча республика штабы Татарстанда оешуы, сайлаулар буенча Владимир Владимировичның Татарстандагы вәкаләтле вәкиле буларак Президент аппараты җитәкчесе Әгъзам Гобәйдуллинның билгеләнүе, республикабызда Россия Президенты вазыйфаларын башкаручы кандидатурасын яклап 35 мең имза җыелуы - болар барысы да Борис Ельцин варисының Татарстан сайлаучылары арасында киң яклау табачагына ишарәли.

Ә инде "Бөтен Россия" хәрәкәтенең Президент сайлауларында Владимир Путинны якларга җыенуының сәбәбенә килсәк, Минтимер Шәрипович моны бик нигезле аңлатты. Республикабызда киң яклау тапкан әлеге хәрәкәт Думада Россия коммунистлар партиясенең күпчелек

урынны яулап алуына юл куймас өчен оештырылган иде, һәм бу максат үтәлде. "Бөтен Россия" һәм "Ватан" хәрәкәтләре блогы лидеры Евгений Примаков үзенең кандидатурасын 26 мартта узачак сайлауларга куюдан баш тарткач, билгеле, коммунистик идеологиягә каршы көрәш фонында оешкан бу блок Геннадий Зюгановны президентлыкка үткәрмәс өчен Владимир Путинны якларга тиеш була.

Шулай итеп, Евгений Максимович Дума сайлаулары вакытында үзе яклы булган сәясәтчеләр, аеруча төбәк җитәкчеләренең хәлен күпкә җиңеләйтте: аларны хәзер беркем дә үз кыйблаларына тугры булмауда гаепли алмый. Нәкъ менә алар март сайлауларында Россиянең республика һәм өлкәләрендә Владимир Путинның уңышын тәэмин итәчәкләр.

Дөрес, татарстанлылар арасында, бигрәк тә милләтебезнең киләчәге өчен җан атып яшәүче ватандашларыбыз арасында Путин фигурасын өнәмәүчеләр дә күп. Моңа беренче чиратта Чечня җирендә алып барылган зур канкоеш

сәбәпче дисәк, ялгышмабыздыр. Владимир Путин соңгы чечен кампаниясенең башында торды. Кавказда һәлак булган меңнәрчә кешенең җаны аны каргыйдыр. Мондый сәясәтне тагын да дәвам итү бик куркыныч. Кызганычка каршы, Путинның кайбер белдерүләреннән күренгәнчә, киләчәктә милли республикаларның Конституцияләрен яңадан карау, хәтта аларны губерналаштыру сәясәте дә тормышка ашырыла башларга мөмкин. Россиядәге төрле милләт халыклары моның белән килешә алмый, әлбәттә.

Ләкин Президент вазыйфаларын башкаручының бүгенге реаль көндәшләре арасында Россиядәге республикаларның бәйсезлеге өчен җан атучы берәү дә юк бит. Владимир Путинның бердәнбер көчле көндәше булган Геннадий Зюганов чечен кардәшләребезгә каршы сугыш сәясәтен беренчеләрдән булып яклап чыкмадымы әллә?! Властька коммунистлар лидеры килгән очракта Чечня җирендә булган трагедиянең Россиянең башка төбәкләрендә кабатланмавына кем ышандыра ала?! Нәкъ менә коммунистик режим чорында бер чечен халкы гына түгел, ингушлар, кырым татарлары һәм башка кайбер милләт халыклары үз туган илләреннән сөрелеп, кырылуга дучар ителмәдеме әллә!?

Чечен сугышы кебек афәтләрне тудырган бөекимпериячел сәясәткә каршы фикерләрен белдерүче кешеләр дә юк түгел президентлыкка кандидатлар арасында. Әйтик, Григорий Явлинский. Ләкин шунысын да онытмаска кирәк, күпчелек халкын шовинистик рух биләп алган бүгенге Россиядә (Кавказдагы кырылышка карата булган мөнәсәбәтне генә күрегез!) кечкенә милләтләрнең хокукларын яклаучы чын федератив мөнәсәбәтләр урнаштыра алырдай җитәкче сайлана алуына өмет итүе кыен.

Шуңа күрә дә республикабыз җитәкчелеге хәзергә Татарстанга карата лояльлек күрсәтүче һәм сайлауларда җиңеп чыгу өчен бөтен мөмкинлекләре булган Владимир Путинны яклау юлына басарга мәҗбүр.

Владимир Владимировичның "Татар-информ" мәгълүмат агентлыгы хәбәрчесенә түбәндәге сүзләрне әйтүе дә булган кадәр суверенитетыбызны саклап калуга өмет тудыра. "Татарстан белән федераль үзәк арасында, шулай ук Россия Федерациясенең күп кенә башка субъектлары арасында кул куелган Шартнамә дәүләтебезнең тотрыклы торышына ышанырга нигез бирә", - диде Владимир Владимирович. Ул бу мөнәсәбәтләрнең камилләштерелә барачагына ышаныч белдерде: "Милли республикалар Россия Федерациясе составында милли үсеш өчен барлык мөмкинлекләр булуын белеп торсыннар".

Шуны гына телисе кала, республикабыз җитәкчелеге, Владимир Путинның, әгәр ул Президент булып сайлана калса, киләчәктә республикабыз мәнфәгатьләренең истә тотылачагына, Татарстанның сәяси һәм икътисадый хокуклары сакланачагы һәм якланачагына гарантия алсын иде. Ә моңа ирешү өчен ул 26 мартта узачак сайлауларда аның кандидатурасын якларга тиеш.

Тиздән - сайлаулар. Анда катнашу яки катнашмау, теге яисә бу кандидатны сайлау - һәркемнең шәхси эше. Ләкин шуны онытмыйк, бу сайлауларда безнең шәхси язмышыбыз гына түгел, шактый дәрәҗәдә Татарстаныбызның да, милләтебезнең дә киләчәге хәл ителә. Шуңа да бу сәяси акциягә һәр татарстанлы җитди карарга, сайлау участокларына кандидатларга карата үз мөнәсәбәтен һәрьяклап үлчәп, уйлап, хәл итеп бетереп барсын иде.

В. ЗАҺИТОВ.

ЧИСТАЙ варианты

М. Шәймиев, В. Козлов, А. Губкин.

Сайлауларда халык ышанычын яуламаган кешенең хакимият җитәкчесе булырга хакы юк. Татарстанда бу - язылмаган закон. Президент әйтә икән, язылмаган законнар да катгый үтәлә. Чистай варианты - моның ачык мисалы.

Республика Дәүләт Советына булып узган соңгы сайлаулар вакытында хакимият башлыгы яклау таптамаган берләнбер округ буларак 62 нче Чистай административ-территориаль округы танылды. 17 ел буе Чистай шәһәре һәм районын җитәкләгән Абрек Хәйруллин бу юлы сайлаучыларның ышанычын яулый алмады. Соңгы елларда бу төбәктә торак төзелешенә, юллар төзекләндерүгә, промышленностьны җанландыруга зур көч куелса да, халыкны социаль яклауга, күрәсең, тиешле игътибар бирелеп җиткерелмәгәндер. Авыл хуҗалыгын үстерүдә дә барлык мөмкинлекләр эшкә җигелмәгән. Кыскасы, халык үз җитәкчесенә ышаныч күрсәтми икән, бу инде тикмәгә генә түгел. Үзе дә моны яхшы аңлап, А. Хәйруллин Татарстан Республикасы Президентына отставкага китәргә теләге турында гариза бирде. М. Шәймиев аны эшеннән азат итү турындагы Указга кичекмәстән кул куйды.

Яңа җитәкчене тәкъдим итәргә Татарстан Президенты Чистайга үзе барды. Шәһәр һәм район активы җыелышында ул җирле Совет депутатларын, предприятие, оешма һәм хуҗалык җитәкчеләрен хакимият башлыгы вазыйфаларын башкаручы Вячеслав Козлов белән таныштырды.

Вячеслав Михайлович Козлов 1956 елның 7 февралендә Татарстанның Чистай районы, Яңа Чишмә авылында туган. Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, галим-агроном белгечлеге алган. Хезмәт юлын, армиядән кайтып Чистай совхоз-техникумын тәмамлаганнан соң, Чистай районының XX партсъезд исемендәге колхозында бригадир ярдәмчесе булып башлый. 1982 елдан Яңа Чишмә районында XX партсъезд исемендәге колхоз рәисе урынбасары, "Закамский" совхозы директоры, халык депутатларының район Советы рәисе урынбасары булып эшли. 1992 елдан - Яңа Чишмә районы хакимияте башлыгының беренче урынбасары, 1998 елдан - хакимият башлыгы.

Татарстан Президенты бу кандидатураның тикмәгә генә тәкъдим ителмәвен белдерде. Чистай һәм Яңа Чишмә районнары кайчандыр бер район булган, аларны күп кенә уртак сыйфатлар, халыкның бер төрле менталитеты берләштерә. Күпчелекне рус халкы тәшкил итүче төбәктә шушы милләт кешесен җитәкче итеп кую да үзен акларга тиеш. Соңгы елларда Татарстанда җитәкче постларның күпчелегенә титул милләте вәкилләрен билгеләп кую белән бәйле дәгъваларның, бу мәсьәләдә хәтта Мәскәүдән ризасызлык белдерүләрнең көчәюе фонында бу - бигрәк тә актуаль.

Яңа эшкә билгеләнүе сәбәпле, Вячеслав Козловны Яңа Чишмә районы хакимияте башлыгы вазыйфаларыннан азат итәргә туры килде. Шуңа күрә Президент Яңа Чишмә районына яңа хакимият башлыгы билгеләп куйды. Ул - шушы төбәк кешесе, моңа кадәр озак еллар хуҗалык җитәкчесе булып эшләгән Александр Губкин.

Александр Семенович Губкин 1954 елның 1 мартында Татарстанның Чистай районы, Яңа Чишмә авылында туган. Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, галим-агроном белгечлеге алган. Хезмәт юлын, институтны тәмамлаганнан соң, 1976 елда Чистай районының XX партсъезд исемендәге колхозында агроном булып башлый. 1982 елдан - Яңа Чишмә районының "Кызыл Октябрь" тәҗрибә-җитештерү хуҗалыгы директоры.

"Чистай варианты" - халык ышанычын яулый алмаган, аның гозеренә, уй-фикерләренә колак салмаган җитәкчеләргә кисәтү ул. Шул ук вакытта бу ысул - республикабызның шәһәр һәм районнарында, авылларында хакимияткә халык мәнфәгатьләрен яклардай җитәкчеләрне, чын халык вәкилләрен сайлап куюның иң ышанычлы һәм уңайлы юлы түгел.

Татарстанда җирле хакимиятне формалаштыру системасын, һичшиксез, камилләштерәсе бар әле. Яңа эшли башлаган Дәүләт Советы бу хакта уйланмый калмас дип ышанасы килә.

Васил ЗАҺИТОВ.

М. Козловский фотосы.

Татарстан авыл хуҗалыгы:
кичә, бүген, иртәгә
(15 - 35 битләр)



Сабырың сынса, түкәнсә,
Җитмәсә әгәр акыл, -
Яшәү көчен алыр өчен
Кирәк ул Туган авыл.

Ак карлары - сафлык нуры,
Аклыкның рухы - давыл.
Җир сулышын тояр өчен
Бик кирәк Туган авыл!

Кайтыр җирең булмаганда,
Авылсыз калсаң, авыр...
Яшәешнең чыганагы,
Җаны ул - Туган авыл!

Авыл - ил тоткасы



Марат Готоф улы ӘХМӘТОВ - Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры.

Үзенең мәшәкатьләре, корылык дигән тетрәндергеч хәсрәтләре, тырышлык аша килгән уңышлары белән тагын бер авыл хуҗалыгы елы узып китте. Озакламый яңа гасырга - өч меңенче елга аяк басабыз. Ул безгәниләр вәгъдә итә? Киләчәктә җөмһүриятебезнең авыл хуҗалыгы нindирәк юл белән үсәр, элеккеге данын кайтара алырмы? Без шундыйрак уйлар белән Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры М. Г. ӘХМӘТОВка мөрәҗәгать иттек.

А. Титов һәм Н. Туганов фотолары.

- Хөрмәтле Марат әфәнде, Сезнең республика күләмендә авыл хуҗалыгы дигән зур йөккә җигелүегезгә тиздән бер ел була. Ничегрәк соң?

- Йөк чыннан да авыр. Россиянең күп кенә төбәкләрендә авыл арбасы сазга батып ята. Чәчелми калган басуларның гектары елдан-ел арта, хәзер ул 30 миллион гектарга җитә. Әгәр туктатылмаса, бу процессның чын фаҗигага әйләнүе дә ихтимал.

Шөкер, Татарстанның авыл хуҗалыгына мондый афәт янамый. Без уңдырышлы җирләребезне саклап кала алдык. Крестьян хуҗалыгы исән-имин генә яшәп ята. Җитештерү һәм хәзерләүләр өлкәсендә тотрыклылык сизелә. Мин моңа конкрет мисаллар китерә алам.

- Әйдәгез, ел йомгакларына әйләнеп кайтыйк әле. Шартлар бер булганда да, нәтиҗәләр төрле иде. Узган ел Сезгә ни сабак бирде, нинди кимчелекләрне ачты?

- Узган елның язы, аның озакка сузылып килүе, җәйнең корылыгы һәр кешегә мәгълүм. Табигать көйсезлеге авыл хуҗалыгында үзен аеруча сиздерә. Чөнки уңыш ачык һавада формалаша. Үсемлекләргә аның йогынтысы зур. Әмма без уңышсызлыкларыбызны, үзебезнең тиешлесен эшләп бетермәвебезне гел табигатькә генә сылтап калдыра башласак, ерак китә алмабыз. Кайчан да бер ул безнең якадан эләктерәчәк. Яхшы җитәкче беркайчан да сәбәп эзләп маташмый, игенчелек технологиясен җиренә җиткереп башкарырга омтыла - шуның белән ота да.

> “Базар икътисады шартларында авыл хуҗалыгы предприятиеләре нәтиҗәлерәк эшли башлыйлар, яңа чор җитәкчеләре - компетентлы һәм җаваплы профессионаллар формалаша. Кыскасы, җирнең чын хуҗаларына әверелү процессы бара”.
>
> **М. Ш. ШӘЙМИЕВ.**

Кем әйтер Нурлат районында табигать икенче төрле дип. Киресенчә, көньяк район буларак, андагы җилләр кайнаррак та булды әле. Ә уңышны һәр гектардан уртача 30 центнер җыеп алдылар. Бер үк шартларда яшәүче күршеләре - аксубайлылар 13 центнер белән канәгатьләнде. Бу - гафу ителмәслек сүлпәнлек нәтиҗәсе. Районга яңа хаким билгеләнде. Киләчәктә уңай үзгәрешләргә өметләнәбез. Яки алыйк төньяк төбәкне - Балтач районын. Үсемлекләрнең формалашу чорында монда да өтеп алды. Әмма балтачлылар, башка еллардагы тәҗрибәне кулланып, үзләрен табигать көйсезлегенә каршы куя алдылар. Уртача уңыш - 27,2 центнер. Элек безне сөендереп килгән Минзәлә районы - 12,5, Тәтеш, Мамадыш районнары 16,5 әр центнер белән чикләнде.

Җиргә карашны тамырдан үзгәртергә кирәк безгә. Булдыксыз җитәкчеләр эш башында утырырга тиеш түгел. Әлбәттә, эш башындагы һәркем үткәндәгеләрдән үзенә сабак алырга, нәтиҗә ясарга бурычлы.

Былтыргы игенчелек елының ачы сабагы шул: без матди хәлебезнең мөшкеллеген, техниканың эшкә сәләтсезлеген тагын да ныграк аңладык. Язгы кыр эшләренә, тулаем урып-җыюга ниндидер канәгатьләнү белән, формаль караштa торганбыз. Басуга чыгып эшли башлагач, ике техниканың берсе туктап калды. Димәк, урыннарда мәсьәләгә җавапсыз караганнар, әйдә, ярарский чире белән авырганнар. Әйтик, колхозда дүрт “Дон” комбайны бар, ди. Шуның берсе машина-трактор паркында “законлы” рәвештә ватык тора. Басуга чыгарылган өченең бере тагын эшләми. Димәк, уракта катнашырга тиешле техниканың яртысы гамәлдә түгел. Төзекләндерү сыйфатын күтәргәндә без уракны кыскарак тота алыр идек. Бу исә тулаем җыемга да уңай йогынты ясый. Югалтуларны киметүнең бик мөһим буыны бу.

- Җитәкчелек факторына киңрәк тукталыйк әле.

- Товар җитештерүчеләр үзләренә лидер билгелиләр, аңа өметләнәләр, язмышларын ышанып тапшыралар. Җитәкче менә шул ышанычны аклый аламы - бу бик мөһим. Монысына инде эшнең соңгы нәтиҗәләренә карап бәя бирергә кирәк. Әлеге мәсьәләдә узган ел безгә шулай ук нык сабак бирде. Шуны истә тотып, кышкы чорда үзебезнең Агробизнес институтында 600 җитәкчене кабат укытып чыгардык. Аларны үзара очраштырдык, тәҗрибә уртаклаштырдык. Иң мөһиме: яңача фикерләүче, стандарт булмаган белгеч, җитәкчеләр белән күрештереп, аларның акыллы фикерләрен тыңлаттык, катып калган кагыйдәләрдән арынырга булыштык. Тыңлаучыларыбызның тормышка карашы, мөнәсәбәте үзгәрде, дияр идем мин.

Уйлап карасаң, җитәкченең статусы да ике төрле бит. Күпчелек районнарда ул бер төрлерәк булса, нефть һәм сәнәгать белән шөгыльләнүче районнарда бөтенләй башка. Әйтик, нефть районнарында авыл хуҗалыгы җитәкчеләренең генә түгел, товар җитештерүчеләрнең дә кызыксынуы үзенчәлекле. Чөнки башка тармакта эшләүчеләр аларның күз алдында хезмәт хакын 4-5 мәртәбә күбрәк ала. Ә безнекеләр башкалардан кимме әллә?! Хезмәтенә күрә әҗере дә булырга тиеш бит инде! Бу сабак түгелмени? Уйландырырлык сабак бу! Авыл кешесе үзенә дигәнен алырга тиеш!

Фикерне йомгаклап шуны әйтәсе килә: әгәр без уракны 10 сентябрьгә төгәлли алсак, терлекләргә кышка җитәрлек күләмдә концентрат азыклы булыр идек. Кимендә 250-300 мең тонна өстәмә ашлык дигән сүз. Уракта соңга калу - товар җитештерүчеләрнең фаҗигасы ул. Узган еллар корылык һәм бәяләрнең төрлечә уйнавы белән дә истә калды. Бер сүз белән әйткәндә, безгә заманча уйлый торган, юкны бар итүче җитәкчеләр кирәк.

- Техниканың шөрепләре коелды. Машина-трактор паркын яңартуда лизинг системасына күчәргә кирәкмиме?

- Без шушы система белән эшлибез хәзер. Моны тормыш үзе таләп итә. Бигрәк тә авыл хуҗалыгында “тере” акча мәсьәләсе зур проблема ул. Президентыбыз Минтимер Шәрипович Шәймиев, Премьер-министрыбыз

Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов авыл хуҗалыгына даими игътибар күрсәтәләр. Дөрес әйтәсез, техника нык тузды, аны яңарту сорала. Без менә шушы юнәлештә эшлибез. Республиканың машина-трактор паркын яңартуга быелгы бюджеттан 620 миллион сум акча каралды. Бу инде узган елгыга караганда 2,5 мәртәбә күбрәк дигән сүз.

Язгы кыр эшләре башланганчы Волгоградтан 1000 данә чылбырлы трактор алынырга тиеш. Бүгенге көнгә шуның 500 данәсе кайтарылды. Алар, җир мәйданына һәм сатылган продукция күләменә карап, лизинг системасы буенча хуҗалыкларга биреләчәк. Россия лизингы буенча 200 данә көпчәкле трактор һәм үзебезнең лизинг компаниясе счетлары әйләнеше чыганаклары ярдәмендә тагын шулкадәр үк өстәмә тракторлар алырга ниятлибез. Димәк, җөмһүриятебездәге һәр хуҗалыкка кимендә 1-2 трактор тиячәк дигән сүз. Әлбәттә инде, болар гына техникага булган ихтыяҗны канәгатьләндерә алмый. Шулай да бу - зур өстәмә.

Президентыбыз һәм хөкүмәтебез күрсәтмәләре нигезендә 100 данә "Кейс" комбайннары алуга контракт төзелде. Алар механикалаштырылган отрядларда һәм машина-трактор станцияләрендә файдаланылачак. Өстәмә рәвештә Ростов-Дон шәһәреннән "Дон" маркалы тагын 200 комбайн кайтарылачак. Запас частьлар алуга 80 миллион сум күләмендә акча билгеләнде. Шунысын да искәртеп китәргә кирәктер, күп санда яңа техника сатып алуыбыз нәтиҗәсендә ремонт өчен бюджеттан акча бүлеп бирү беркадәр чикләнәчәк. Димәк ки, запас частьлар булдыруда эчке мөмкинлекләрдән файдалану сорала. Мәсәлән, Зәй районы җитәкчелеге моның өчен 2 миллион сум күләмендә акча юнәтә алган. Сарман, Кукмара, Мамадыш районнары да шундый ук юлны сайлаганнар. Нәтиҗәдә бу районнарда техниканы язгы кыр эшләренә әзерләү уңышлы гына бара.

Ягулык-майлау материалларына бәяләрнең туктаусыз артып торуын истә тотып, без 2000 елда бу максатларга 1 миллиард 700 миллион сум күләмендә кредит кирәк булыр дип уйлыйбыз.

Җепнең очын тагын җитәкчеләргә китереп бәйлисе килә. Аларның күбесе бушлай алуга күнегеп китте. Хөкүмәт бирә тора, бирә тора - тегеләр үзләштерә бара. Инде икенче-өченче, хәтта бишенче елгы бурычларны түләр чак килеп җитте. Әлегә берәү дә әҗәтен кайтарырга ашыкмый. Хуҗалыкларның элеккеге бурычлары да хәттин ашкан. Бу өлкәдә уйланасы нәрсәләр бар әле.

- Туфракның җелеге суырылды. Ашламасыз гына уңышка өметләнү - тумаган тайга атланып йөрү кебегрәк килеп чыга.

- Бу очракта ашламаның чагыштырмача аз кулланылуын хөкүмәт җитешсезлеге дип кенә кабул итмәскә кирәктер. Күмәк товар җитештерүчеләрнең үз акчаларына сатып алган ашлама бәясенең яртысы болай да дәүләт бюджетыннан каплана. Ул шулай булырга тиеш тә. Әмма тулаем бюджетка гына салынып ятарга ярамый. Андый юл белән уңышка өметләнә алмыйсың.

Әгәр без кышкы чорда терлекчелекне азык белән тәэмин итүдә кыенлыклар кичерәбез икән, бу да бит шул ук ашламага килеп тоташа. Әнә, бүген һәр гектарга 150 килограмм исәбеннән тәэсир итү көче куәтле дип саналган ашламаларны кертүче хуҗалыклар уңышны бермә-бер күбрәк алалар. Ашлама - туфракка бер сум салып, өч сум алу дигән сүз ул. Егерме-утыз килограмм белән ерак китеп булмый шул.

- Ә яз җитте, Марат әфәнде!

- Игенче шуны сизеп, дәррәү кузгалды. Урып-җыю төгәлләнү белән "Сельхозтехника" берләшмәләренә 1200 комбайн китергән идек. Аларны сафка бастыру төгәлләнеп килә. Хуҗалыкларның үзләрендә дә эш әйбәт кенә бара. Авыл хуҗалыгында каникул булырга тиеш түгел. Бу урында шунысын да әйтергә тиешмен: узган елгы сабаклардан чыгып, без быел әлеге максатлар өчен үзәкләштерелгән бюджеттан шактый сумма бүлеп бирдек.

Техниканы төзекләндерүдә уңышлы гына эшләүче районнар бар. Мәсәлән, Баулы районы хуҗалыклары 1 февральгә үк инде тагылма машиналар төзекләндерүне тулысынча төгәлләделәр. Бу эш Түбән Кама, Кукмара, Актаныш районнарында да тәмамлану алдында тора. Ә менә Мөслим, Югары Ослан, Чистай районнарында тагылма машиналарны ремонтлау нибары 21-28 процент кына. Моннан тиешле нәтиҗәне ясасыннар.

- Чит илләрдә йөреп кайттыгыз. Республика өчен анда нәрсә дә булса эшли алдыгызмы соң?

- Сәеррәк сорау инде бу. Анда, чит илдә диюем, Татарстаннан министр килгән икән дип, капчыкка инвестиция тутырып көтмиләр бит. Тиктомалга берни эшләнми. Матурлап әйтсәк: бушның браты күптән үлгән инде. Аннан соң без үзебез дә гуманитар ярдәмгә ышанып яши алмыйбыз. Иң элек башкаларга үзебезне ышанычлы партнер буларак күрсәтергә тиешбез. Шул чакта гына тигез шартларда хезмәттәшлек итәргә мөмкин.

Әйе, Канада хөкүмәте белән ике арада килешүебез бар анысы. Сәфәребез шуңа таянып үткәрелде. Яңадан бер килешүгә кул куелды - уртак предприятие төзү, республикага инвестиция кертү буенча. Ачыграк итеп әйтсәк, терлек азыгы җитештерү, терлекләрне генетик яктан яхшырту һәм сөт җитештерүне арттыру юнәлешендә уртак предприятие булдыру. Әлбәттә инде, табышы да уртак. Менә шушы соңгысы безнең партнерларны бинһая кызыксындыра да. Алдан шапырыну кирәкмәстер. Уй-хыялларыбыз барып чыгар төсле. Бездәге хыяллар аларның көндәлек тормышында яшәп ята. Канадада бер сыердан уртача 8000 килограмм сөт савып алалар. Бездә ул 3000 нән дә кимрәк. Фәнгә, алдынгылар тәҗрибәсенә таянып эшләргә туры килә.

Максатыбыз - Россия базарына үтеп керү, аны яхшы сыйфатлы, мул продукция белән яулап алу. Крестьянның 500-550 сум айлык хезмәт хакы белән дә килешеп булмый. Без аны 1500-2000 сумга, аннан да күбрәккә җиткерергә тиешбез. Чит илдәге тормышны күргәч, Татарстанга шундыйрак уйлар белән кайттык.

- Уңышлар сезгә, Марат әфәнде!

- Рәхмәт.

Әңгәмәдәш - Госман ГОМӘР.

Җиләк-җимеш, яшелчә – барысы да күп бездә

Заманында җиләк-җимеш, яшелчә үстерү белән һәр колхоз-совхоз шөгыльләнә иде. Ләкин республикада Чаллы, Түбән Кама кебек яңа шәһәрләр төзелү, Казан, Зеленодольск кебек шәһәрләрдә халык артуы яшелчә, җиләк-җимеш үстерүче махсус хуҗалыклар оештыруны көн алдына куйды. 1966 елда 7 шәһәр яны хуҗалыгын берләштергән бакчачылык һәм яшелчәчелек тресты оештырылды.

Республикада яшелчә һәм җиләк-җимеш үстерүче хуҗалыклар ел саен артты. Бүген исә ул зур икътисадый көчкә ия булган тармакка әйләнде. Хәзер "Татплодоовощпром" концернына 16 районда урнашкан 11 яшелчә, 10 җиләк-җимеш хуҗалыгы һәм 3 питомник керә. Бер үк вакытта 7 күпләп-азлап сату оешмасы яшелчә әзерләү, саклау һәм сәүдә челтәренә җибәрү белән шөгыльләнә. Моңардан тыш концерн предприятиеләрендә елына 15 миллион данә банка яшелчә консервлары эшләнә. Тармакның Казанда, Чаллыда 50 дән артык үз кибете бар.

Хәзер яшелчә 2650 гектар, ә җиләк-җимеш бакчалары һәм питомниклар 2450 гектар мәйданны били.

Шунысы сөенечле, элекке елларда яшелчәне күпләп чит өлкәләрдән һәм илләрдән кайтарсак, хәзер бу продукциягә булган ихтыяҗның 80 проценты үзебездә җитештерелә.

Тугыз хуҗалык яшелчәне ачык грунтта үстерә. 1999 елда кәбестәнең һәр гектарыннан уртача 440 центнер уңыш алынды, ә "Идел" агрофирмасында ул 533 центнер, "Ворошиловский" совхозында - 520, "Нармонка" совхозында 500 центнер тәшкил итте.

"Майский" совхозында 49 гектар, "Весенний" совхозында 30 гектар яшелчә теплицаларда үстерелә. "Весенний" совхозы шампиньон гөмбәләре үстерү белән дә шөгыльләнә.

Татарстан җиләк-җимеш һәм яшелчә концерны ел саен Казан халкы өчен 15 мең тонна бәрәңге, 20 тонна яшелчә, шул исәптән 10 мең тонна кәбестә, 5 мең тонна кишер, 2 мең тонна аш чөгендере, 2 мең тонна башлы суган әзерли һәм сата.

Яшелчә һәм җиләк-җимеш совхозлары өстәвенә быел 46 мең тонна ашлык, 24 мең тонна сөт, 2200 тонна ит җитештерделәр. Бу тармакта 9 меңнән артык кеше эшли.

Азык хуҗалыгының кайбер тармаклары базар мөнәсәбәтләренә җайлаша алмыйча, продукция җитештерүне киметкәндә, республикабызның яшелчә үстерүчеләре яңа технологияләр үзләштерә барып, халык өстәленә күп һәм арзан продукция озатуга ирешәләр.

РӘСЕМДӘ: Татарстан җиләк-җимеш һәм яшелчә концерны рәисе, Татарстан халык депутаты Раил Зиятдинов.

Бу шат йөзле кызлар һәм ханымнар "Майский" совхозының иң алдынгы яшелчә үстерүчеләр бригадасы. Алар һәр квадрат метрдан 34 килограмм кыяр һәм помидор үстерделәр һәм "Ока" автомашинасы белән бүләкләнделәр. Уртада цех агрономы Зөфәр Низамов.



Ж. АКЧУРИН һәм А. ТИТОВ фотолары.

Илшат ГАНИЕВ:

ЯШЕЛЧӘ ҮСТЕРҮ - ФИДАКАРЬЛӘР ЭШЕ

"Майский" яшелчәчелек совхозы - Татарстанның горурлыгы. Мәйданы ягыннан ул Мәскәү өлкәсендәге "Московский" хуҗалыгыннан кала Россиядә икенче урында тора. Ә яшелчә үстерүдә яңа технология кертү һәм һәр квадрат метрдан алынган уңыш буенча Россиядә аңа тиңнәр юк.

Бүгенге икътисадый авырлыклар шартларында "Майский" совхозының яшелчә җитештерүне елдан-ел арттыра баруы барыннан да элек бу хуҗалык директоры Илшат Ганиевның тынгысызлыгына, базар шартларында эш итә белүенә, оста һәм таләпчән оештыручы булуына бәйле. Илшат Газимович әлеге совхозга Казан авыл хуҗалыгы институтының 4 курсында укыганда практикага килә һәм язмышын шушы хуҗалык белән бәйли. Биредә барлык баскычларны үтә: гади агроном, аннары цех башлыгы, баш агроном урынбасары һәм, ниһаять, 1989 елның гыйнварында 35 яшьлек Илшатны шушы олы хуҗалыкка җитәкче итеп сайлап куялар.

"Майский" совхозы директоры, Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, Татарстанның халык депутаты, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты Илшат Газим улы ГАНИЕВ бүгенге шартларда халыкны яшелчә белән тәэмин итүдә хуҗалыкның эш тәҗрибәсе белән уртаклаша.

Дөресен әйтим, туксанынчы еллар башында һәрнәрсәгә бәяләр котырынып үскәндә без шактый борчуга төшкән идек. Яшелчә, җиләк-җимешне халык алырмы? Шундый зур көч куеп төзелгән совхозыбыз таралмасмы? Ни әйтсәң дә, кешегә азык-төлектән, беренче чиратта, икмәк, сөт, ит кирәк бит. Россиянең үзендә, аннары күп кенә республикаларда һәм өлкәләрдә "Плодоовощпром" системасы таркалды, һәр хуҗалык үз көнен үзе күрә башлады. Шундый борчулы көннәрдә без, республиканың барлык яшелчә, җиләк-җимеш совхозлары директорлары бергә җыелдык. Шунда катгый карарга килдек: таркалмаска, бүленмәскә, "Татплодоовощпром" системасын саклап калырга. Яңа технология кертү исәбенә яшелчә җитештерүне арттырып, аның бәясен халык сатып алырлык дәрәҗәдә тотарга. Шулай авырлыкларны бергәләп җиңәргә булдык. Безнең бу карарны Президентыбыз М. Ш. Шәймиев кайнар яклады һәм һәрьяклап тармакка ярдәм итеп тора.

Хәзер ул көннәрдән соң 7-8 ел үткәч, ачыктан-ачык әйтә алабыз: дөрес юл сайлаганбыз. Нинди генә авырлыкларга карамастан, безнең совхозда яшелчә җитештерү күләме артты. Чагыштыру өчен берничә сан китерәм: әйтик, 1990 елда 11 мең 600 тонна яшелчә җитештерелсә, үткән ел бу күрсәткеч 15 мең 300 тоннага җитте. Без моңа тик яңа сортлар, яшелчә үстерүдә яңа технология кертү белән ирешә алдык. 1993 елны Израиль фирмалары белән килешү төзеп, помидор, кыяр үстерүдә өр-яңа технология кертүгә ирештек. Әлеге технология нигезендә һәр помидор, кыяр төбенә махсус торбачыклар аша сыек ашлама килә. Бу сыекчада яшелчә өчен кирәкле бөтен матдәләр бар. Аның составы махсус компьютерлар ярдәмендә контрольдә тора. Яңалык һәр гектардан уңышны кискен арттыру белән беррәттән, экологик чиста продукция җитештерергә мөмкинлек бирә. Әлеге ысул белән хәзер 18,5 гектарда помидор һәм кыяр үстерәбез. Барлык теплицалар исә 49 гектар тәшкил итә.

Теплицаларда яшелчә үстерүнең бер кыен ягы бар: ноябрь-февраль айларында көн кыска, яктылык җитми. Шунлыктан бездә помидор, кыяр февраль-март айларында гына өлгерә иде. Декабрьдә, гыйнварда уңыш алынмады диярлек. 1997 елны тагын бер яңалык кертелде: 2 гектар

мәйданда өстәмә яктылык кулланып, тамчылап тукландыру ысулы белән ноябрь-гыйнвар айларында да кыяр үстерә башладык. Без әлеге теплицалардан алынган кыярны Мәскәүгә һәм башка шәһәрләргә озатабыз. Мәскәүдә бу кыяр, Казандагыга караганда 2 тапкырга кыйммәтрәк. Хәзер әлеге ысул белән 3 гектар мәйданда кыяр үстерелә.

Тимирязев исемендәге авыл

Баш агроном Искәндәр Мозаффаров

хуҗалыгы академиясе галимнәре ярдәмендә помидор, кыяр һәм башка төр культураларның яңа сортларын кертү дә уңышны күтәрергә мөмкинлек бирә. Өстәвенә без хәзер чәчүлек орлыкларны үзебездә үстерәбез. Үстерелгән орлыкның 20 проценты үзебезнең ихтыяҗны капларга китсә, калганы сатыла.

Теплицаларда яшелчә үстерү өчен 1 гектарга 4 мең кубометр торф һәм пычкы чүбе кертә идек. Хәзер тамчылап тукландырыла торган теплицаларда җир кертү күләме

Яшелчәче Нина Крылова

А. ТИТОВ фотолары.

ун тапкырга кимеде. Туфрак урынына цеолит дигән тау токымы файдалана башладык. Аны Закарпатьедән вагонлап кайтарабыз. Кыяр, помидор үсентеләре шуңа утыртыла һәм даими рәвештә тамчылап тукландырыла. Бу минералны 10-15 ел файдаланырга мөмкин. Кайбер чит илләрдә туфрак урынына пыяла мамыгы кулланалар. Пыяла мамыгы һавага очарга мөмкин, сәламәтлеккә зыян китерә, аны ел саен алыштырырга да кирәк. Өстәвенә аны файдаланганнан соң кая куярга белмисең, чөнки ул череми. Шунлыктан без бу алымнан баш тарттык. Цеолит тозы куллану һәр квадрат метрдан уңышны 10 килограммга күтәрергә мөмкинлек бирде.

Кыяр, помидор һәм башка яшелчә үсентеләрендә төрле

Лаборатория мөдире Валентина Дербышева

корткычлар барлыкка килә. Без алар белән көрәштә химик юл түгел, ә бәлки биологик алым сайладык. Ике ел элек биологик лаборатория бинасы төзедек. Биредә яшелчә үсентеләрендәге корткычлар белән тукланучы 10 төрдәге бөҗәк үстерелә. Теге яки бу теплицада корткычлар барлыкка килсә, әлеге бөҗәкләр шунда таратыла.

49 гектар мәйдандагы теплицаларны җылыту өчен бик күп җылылык энергиясе кирәк. Аның бәясе елдан-ел арта. Бу исә яшелчәнең үзкыйммәтенә суга. Шуңа да җылылыкны саклауның төрле юлларын кулланабыз: гади пыяла органик пыяла белән алыштырыла, җылы тышка чыкмасын өчен махсус җайланмалар куела.

Менә шундый яңалыклар кертү безгә яшелчәнең һәр квадрат метрдан уңышын арттырга һәм үзкыйммәтен киметергә мөмкинлек бирде. Шунлыктан без яшелчәнең бәясен кискен күтәрмәдек, аны күпчелек халык сатып алырлык итеп калдыра алдык. Бездә былтыр 1 кг кыярның уртача бәясе 11 сум, ә помидорның 10 сум 40 тиен булды. Бу 1990-1991 еллардагы бәягә караганда 5 тапкыр артыграк. Инде чагыштырып карыйк: шул чорда ит 22 тапкыр, май - 22, тавык ите - 20, бензин 48 тапкырга арткан. Без рентабельлекне киметтек. Хәзер ул 20-24 процент. Ләкин иң мөһиме - бүген безнең яшелчәне халык ала. Бу бит сәламәтлек дигән сүз. Былтыр 15 мең 200 тонна яшелчә җитештереп, 176 миллион сумлык продукция сатуыбыз шул турыда сөйли бит. Моңардан тыш 24 төрдә 4 миллион банкадан артык яшелчә консервлары җитештерелде.

Соңгы ун елда совхоз коллективы төрле хәлләр кичерде. Ләкин без зур тетрәнүләргә юл куймадык. Биредә совхоз җитәкчелегенең һәм коллектив әгъзаларының бердәмлеге, оешканлыгы хәлиткеч роль уйнады, әлбәттә. Совхоз директоры урынбасары - баш агроном Искәндәр Мозаффаров, техник мәсьәләләр буенча директор урынбасары Илдус Дәүләтшин белән бергәләп егерме елдан артык эшлибез, киңәшәбез, мәсьәләләрне хәл итәбез. Бүген коллективта 1700 дән артык кеше эшли. Хезмәт хакы вакытында түләнә. Узган ел уртача хезмәт хакы 1770 сумга җитте. Шулай ук социаль яклауның башка алымнары кулланыла.

Халыкта бик гыйбрәтле мәкаль бар: аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар. Безнең республикада яшелчәчелек, җиләк-җимеш совхозлары сакланып калган һәм бүген бик күп продукция җитештерәләр икән инде, әлбәттә, бу хуҗалыкларны бер йодрыкка туплап торучы, һәр яклап ярдәм итүче, бик күп мәсьәләләрне Президентыбыз М. Ш. Шәймиев һәм хөкүмәт аша хәл итүче "Татплодоовощпром" концерны рәисе Раил Шаһеретдин улы Зиятдиновның искиткеч роле бар. Заманында "Плодоовощпром" системасын бетергән республикалар һәм өлкәләр ялгышларын аңладылар, аны кабат торгызалар. Февраль ахырында бездә Россиянең яшелчә үстерүче совхозлары җитәкчеләренең семинары булып үтте. 150 гә якын кунак бездә тупланган тәҗрибә белән җентекләп танышты. Бу олы сөйләшү безнең өчен дә бик файдалы булды.

Былтыр совхозыбыз оешуның 25 еллыгын билгеләп үттек. Бу тантанага Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев үзе килде. Эшебезгә зур бәя бирде. Шул вакытта алда торган бурычларыбызны да күрсәтте. Күз күне Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев җитәкчелегендәге делегация составында миңа Финляндиядә булырга туры килде. Анда петрушка, сельдерей, укроп кебек аш тәмләткечләре үстерүнең яңа технологиясе белән таныштык. Бу яңалыкны үзебезгә кертергә уйлыйбыз. Бу юнәлештә дә Президентыбыз зур ярдәм вәгъдә итә. Ул вакытта без халыкны мондый файдалы аш тәмләткечләре белән ел әйләнәсенә тәэмин итәчәкбез.

Марс Шәрип улы АЛИЕВ -

"Татптицепром" берләшмәсе генераль директоры, Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, "Халыклар дуслыгы" ордены кавалеры.

С. Исхаков фотосы.

Тәмле аша - озак яшә

- Мин ул гыйбрәтле мәкальтәкъбирне Әстерхан базарында сәүдә итүче нугай картыннан ишеткән идем. Бабай үз товарын мактап, яшел, саргылт, кызгылт, шәмәхә тәлгәшләрне түгәрәк үлчәвенә өя, үзе гел теге сүзләрне тәкърарлый: "Йөзем аша - озак яшә", - ди. Сез, Марс әфәнде, бу мәкальне чак кына үзгәрткәнсез икән.

- Кош ите элек-электән югары бәяләнгән. Икенче төрле әйтсәк, туклыклы, шифалы һәм татлы тәгамнәрдән саналган. Ашаудан калган теләсә нинди авыруга бары тик тавык шулпасы гына бирәләр. Бу инде тикмәгә түгел!..

- Кош-кортка ихласлыгыгыз аңлашыла. Сез бу өлкәгә нинди юллар белән килдегез?

- Авыл хуҗалыгына багышланган 36 елның берничә сәхифәсен ачу да җитәдер моның өчен. Үзем Буа районы егете. Казан ветеринария институтын тәмамлагач, Биектау районына юллама алдым. Хезмәт биографиямне терлек симертү совхозында гади зоотехник булып эшләүдән башладым. Шунда ук директор урынбасары вазыйфаларын башкардым. Районның Калинин исемендәге совхозында партком секретаре булу мине җитәкчелеккә, халык белән эшләргә өйрәтте, сәяси карашларымны ныгытты. Шуңадыр дип беләм, тиздән үземне җиде авылны берләштергән "Кызыл Байрак" колхозына рәис итеп сайладылар. Начар эшләмәдем, алты еллык тырышлыгым "Хезмәттәге батырлык өчен" медале белән бәяләнде. Аннары - "Урак һәм Чүкеч" колхозы. Бирәдә без, республикада беренчеләрдән булып, шәһәр тибындагы авыл бистәсен төзедек. Биш ел эчендә халыкның тормыш-көнкүреш шартлары нык яхшырды, хуҗалык икътисады ныгыды. "Халыклар дуслыгы" ордены шул чакларның ядкяре.



- Нигә биш кенә ел әле, Марс әфәнде?

- Үзгәртеп кору галәмәтләре. Ул күп нәрсәне тамырыннан корытты, җимерде. Әйтик, социалистик планлаштыру бөтенләй юкка чыкты. Нәтиҗәдә авыр һәм җиңел сәнәгать хуҗасызландырылды, таркалды. Авыл хуҗалыгы соңгы чиккә килеп терәлде. Хәер, болары аерым зур темалар... Үзгәртеп кору дип, һич тә районнан чыгып качмадым. Бүгенге көндә дә шунда яшим. Баштарак газ аппаратлары заводының Чебокса авылындагы ярдәмче хуҗалыгын җитәкләдем. Юллар салдык, газ-су керттек, терлекчелек биналары төзедек. Авыл малаен саладан аерырга кирәкми дә шул.

- Аердылар дисезме?

- Нишләп инде? Нәсел эше буенча берләшмәне җитәкли башлагач та офис дигәнебез генә үзгәрде. Проблемалар шул ук калды. Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азыктөлек министрының беренче урынбасары йөгген өч ел буе тартып барырга туры килде. Инде менә, юга-

рыда әйткәнемчә, җөе-җөйгә сүтелеп барган кошчылык тармагына күчерелдем.

- Баш кашыргамы?

- Беренче мәлдә анысы да булды. Әмма хәсрәтләнеп кенә эш үзгәрми бит. Җиң сызганып, тирләп-пешеп хезмәт итәргә кирәк. Берләшмәгә кергән 5-6 хуҗалык бөтенләй тавыксыз калган иде. Атаклы нәсел фабрикасы юкка чыгарылган. Заманында нинди шаулаган "Казан" кошчылык фабрикасы соңгы чиккә килеп терәлгән. "Атабай", Буа фабрикаларында тавык түгел, сыңар эшче дә калмаган. Хәер, болар хакында матбугатта язылды инде.

Кошчылыктагы кискен хәлләр Президентыбыз Минтимер Шәрипович Шәймиевкә дә мәгълүм булды. Премьер-министр Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов та борчуга төште. Аларның һәм хөкүмәтнең күргән конкрет чаралары нәтиҗәсендә кошчылык тармагын яңа рельска куярга мөмкин булды.

Бер ел дигәндә ит һәм йомырка җитештерү узган елга караганда шактый артты. Иң мөһиме: үсешкә ныклы база булдырылды. "Бөреле" совхозында нәсел эшен аякка бастырдык. Бройлер тавыклары үрчетәчәкбез.

- Тавыгы да булыр, фермасы да ачылыр. Азыгы кирәк бит аның.

- Иң теңкәгә тигәне шул инде. Әмма без кул кушырып утырмыйбыз, эзләнәбез, чарасына керешәбез. Свердлов өлкәсенә барып, анда катнаш азык җитештерү тәҗрибәсе белән танышып кайттык. Чыннан да мактанырлыклары бар икән. Елга 60 мең тонна ит, 1200 миллион данә йомырка җитештерәләр. Чөнки катнаш азык заводын берләшмәләрнең үзләрендә булдырганнар. Без дә шушы юлдан киттек. Татарстан икмәк продуктлары берләшмәсенең "Реал" базасындагы катнаш азык заводын үзебезгә сатып алдык. Арзанлы, әмма сыйфатлы мул азык җитештерә башладык. Нәтиҗәдә Казан тирәсендәге кошчылык фабрикалары гына да продукция бирүне 30 процентка

арттырдылар. Чөнки азыкның сыйфаты яхшырды. Тиешле микроэлементларны, балык онын һәм башка өстәмәләрне үзебез табабыз. Ә икмәк продуктлары берләшмәсен азыкның сыйфаты да, соңгы нәтиҗәләре дә кызыксындырмады.

- Димәк, арзанлы тавык ите ашыйсылар бар икән әле.

- Нишләп ашамаска? Файдалы диетик ит табыннарыбызда тулып торсын өчен тырышабыз ләбаса.

- Сәмәнең булса...

- Хәзинәдәгесенә исәп тотыйк. Мәскәүдә тавык итенең бәясе 40-45 сум торса, бездә аның килограммы 28-30 сумнан артмый. Бу бит әле дәүләттән бер тиен дотация алмыйча. Сүз дә юк, үзкыйммәтне төшерергә кирәк. Монысын әнә шул азык мәсьәләсе хәл кыла инде. Җылылык һәм электр энергиясе өчен дә чыгымнар гаять зур.

Сәмән дигәннән, ул яктан да

хәлебез рәтләнә шикелле. Узган ел 400 миллион сум табыш алсак, бу сан быелның ун аенда ук 800 миллион сумнан артып китте. Кабатлап әйтәм, Татарстан хөкүмәтенең кошчылыкны үстерү мәсьәләсендә дөрес сәясәт алып баруы киләчәккә якты өметләр уята.

- "Буш", "Билл ботлары"ннан котылыр көннәр булырмы икән?

- Иншалла, котылырбыз. Аларның сыйфаты һәркемгә билгеле бит. Чыкылдаган кояш астында көннәр буе ятып та исләнмәгәч, нинди ит инде ул?! Даруланган биомасса... Юк, "буш"ка ышанып булмый!

- Нишлибез соң?

- Үстерәбез, ныгытабыз. "Залесный" бистәсендә кошчылык фабрикалары өчен җиһазлар җитештерүче завод булдырдык. Бөртекле ашлык һәм үлән өчен җир мәйданнарын киңәйтәбез. Лаеш районындагы "Казан" совхозы безнең берләшмәгә бирелде. Аның 5000 баш мөгезле эре терлеге бар. Шундагы "25 лет Октября" совхозы да Лаеш кошчылык фабрикасына кушылды.

Авыл хуҗалыгы белгече буларак, мин сезгә бер мисал китерәм. Әйтик, республикада 700 мең баш дуңгыз исәпләнә. Әлеге тармакта елына 30 мең тонна ит җитештерелә. Кошчылык өчен бу сан "түгәрәк" кенә. Исәпләп карыйк: бер килограмм дуңгыз ите җитештерү өчен 10-12 азык берәмлеге сарыф ителә. Ә тавыкларга нибары 2,5-3 азык берәмлеге тотыла. Аерма - 3-4 мәртәбә. Шуның өстенә, тавыклар тиз өлгерә, диетик азык бирә. Элек без аларны 75-80 көндә үстерсәк, инде бу вакыт микъдары да кимелдә - 55-60 көнгә калдырылды. "Тәмле аша - озак яшә" дигән мәкаль безнең тармакка бик тә туры килә.

- Инде, Марс әфәнде, кешеләрнең ничегрәк эшләүләренә тукталсагыз икән.

- Әйтергә кирәк, кошчылыкта эшлекле, бердәм коллектив тупланып килә. Бу яктан Тукай кошчылык фабрикасы күпләргә үрнәк. Мең кешелек коллективка тәҗрибәле белгеч Геннадий Иванович Филатов җитәкчелек итә. Эшсез халык юк, көче-куәтенә, сәләтенә карап, һәркем мәгълүм бер вазыйфаны башкара.

Аларның айлык уртача хезмәт хакы 1200 сум. "Красный ключ" фабрикасында да эшсезлек проблемасы юк. Хуҗалары Нәфис Ихсанов шулай ук меңгә якын кеше белән оста җитәкчелек итә. Мин монда Чаллы фабрикасыннан Равил Минһаҗев, Чистайдан Әхәт Фәсахов исемнәрен дә атап китәр идем. Алар хезмәтләре белән дан алган кешеләр. Яңа гасырга шундый җитәкчеләр, тулы канлы коллективлар белән керүебез, уңышка булган ышанычыбызны тагын да ныгыта.

Әңгәмәдәш - Госман ГОМӘР.

Җидегән йолдыз





Буа районында кырлары ямьле Зөя елгасы буена җәелеп киткән "Коммуна" дигән күмәк хуҗалык бар. Җиде авылны берләштерә ул: Черки Килдураз, Үгез Куагы, Кабалан, Күзби, Иске Лощи, Бәбки, Өчмунча. Хуҗалыкның үзәге - Черки Килдураз авылы. Килдураз авылы борын-борыннан укымышлы авыл булган. Ә инде илленче-алтмышынчы елларда Килдураз районда Буадан кала икенче рухи, мәдәни үзәккә әйләнде. Илленче елларда райондагы өч урта мәктәпнең икесе Буада булса, өченчесе Килдуразда иде. Тирә-юньдәге егермеләп авылдан балалар бирегә урта мәктәп тәмамладылар, бирегә яңа тормышка юл алдылар. Килдураз республикабызга бик күп галимнәр, конструкторлар, табиблар, укытучылар, инженерлар, хуҗалыкның төрле тармакларына оста оештыручылар бирде.

"Коммуна" колхозының төрле чаклары булды. Аның районда гына түгел, бөтен Татарстанга яңгыраган көннәре дә, артка тәгәрәгән, киңәшмәләрдә әрләнгән-сүгелгән чоры да булды. Илленче еллар ахырында ул тирә-якта дан тотты, авылның уңган кешеләре турында мәшһүр язучыбыз Афзал Шамов ул вакыттагы "Совет әдәбияты" журналында "Зөя буенда" дигән бик матур очерк та бастырып чыгарды. Алтмышынчы-җитмешенче елларда хуҗалык шактый аксады. Сиксәненче еллар башында "Коммуна" яңадан күтәрелеп китте. Монда барыннан да элек җитәкчелеккә ике яшь, тынгысыз, алга карап фикер йөртүче егетләрнең килүе сәбәп булды. Колхоз рәисе булып һәр тиеннең кадерен белүче Вагыйз Сөнгатов сайланды, ә Җәүдәт Хөсәенов баш агроном, аннары партия оешмасы секретаре йөген тартты. Күрше Күл Черкене авылында туып-үскән Җәүдәт җиде ел буена әлеге хуҗалыкта кешеләр белән эшләүдә зур тәҗрибә туплагач, аны районда артта сөйрәлүче, Чувашия белән чиктәш "Марс" колхозына рәис итеп җибәрделәр. Бервакыт "Коммуна"да рәисләр еш алышына, хуҗалык яңадан артка тәгәри башлады.

Район хакимият башлыгы Габделхай Хәйруллов бик вакытлы һәм дөрес карарга килә: Җәүдәт Хөсәеновны үзе канат чыгарган, ныгыткан хуҗалыкка - "Коммуна" колхозына рәис итеп тәкъдим итә.

Менә сигезенче ел инде Җәүдәт Хөсәенов җиде авылны берләштергән "Коммуна" күмәк хуҗалыгын әйдәп, җитәкләп баручы. Буа районы алдынгылары слетында һәр елны диярлек булам. Һәм бернәрсәгә игътибар итәм: һәр елны кыйммәтле бүләкләрнең иң күбесен сәхнәдән шушы хуҗалык игенчеләре һәм терлекчеләре менеп ала. Башкача мөмкин дә түгел, чөнки игенчелектә дә, терлекчелектә дә коммуналылар районда алдынгылыкны тота. Хуҗалык соңгы биш елда бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 37,6 центнер, шикәр чөгендереннән 331 әр центнер уңыш үстерде. Узган ел корылык булды, шулай да бөртеклеләрдән 33,4 әр центнер ашлык җыеп алдылар, чөгендернең һәр гектарыннан уңыш 400 центнердан артып китте. Һәр сыердан елына савым 4500 килограмм тәшкил итә. Хәзер кайбер хуҗалыклар очын-очка ялгый алмый, үстергән ашлык, җитештергән ит-сөттән керем дәүләттән алган товар кредитын каплауга җитми. "Коммуна"да хәл башкача. Быел табыш 2 миллион 640 мең сум тәшкил иткән. Шуңа да бирегә хезмәт хакы вакытында түләнә, яңа объектлар төзелә, авылларга газ кертелә.

Бу хуҗалык 5105 гектар җир били, сөрү җирләре 4603 гектар. Мондый хуҗалыклар аз хәзер. Җиде авылны берләштерсә дә, модага ияреп хуҗалык ике-өчкә бүленмәде, киресенчә, бер йодрыкка берләшеп, бүгенге кыенлыкларны да кыю җиңә.

Уңышларның сере хуҗалык рәисе Җәүдәт Хөсәеновның һәр авыл, анда яшәүче кешеләр турында бердәй кайгыртуындадыр, мөгаен. Җиде авылның икесенә газ кергән, калганнары электр

Җәүдәт Хөсәенов:

- Әнә, Җидегән йолдызны күрәсеңме? Нинди якты яна. Мин дә безнең хуҗалыкка кергән җиде авылны шул Җидегән йолдызга охшатам.

ярдәмендә җылытыла. Авылларны район һәм хуҗалык үзәге белән асфальт юллар тоташтыра. Төзелеш үзәктә генә түгел, кече авылларда да алып барыла. Аларда мәктәпләр, клублар, терлекчелек биналары, мастерскойлар салына.

Хуҗалыкның һәр тармагы табыш бирә. Шулай да иң зур табыш бирүче тармак - шикәр чөгендере. Былтыр аны 260 гектарда үстергәннәр, 8830 тонна чөгендер сатканнар. Чөгендернең бер гектарыннан алынган табыш гектардан 161 центнер бодай үстерүгә тиң. Чөгендер тапшырган өчен шикәр заводыннан хуҗалык шактый шикәр комы алган. Бу чөгендер үстерүчеләргә бартер тәртибендә ягулык, техника, запас частьлар алырга мөмкинлек бирә. Кайбер хуҗалыклар ягулык алу өчен дәүләттән товар-кредит сорап йөргәндә, биредә инде язгы кыр эшләре өчен җитәрлек ягулык-майлау материаллары әзерләп тә куйганнар.

Җәүдәт Хөсәенов - тынгысыз, заман үзгәрешләрен тоеп, алга карап эшләүче җитәкче. Үз сүзен хакимияттә дә, төзүчеләр һәм ашлык кабул итүчеләргә дә, шикәр заводы җитәкчелегенә дә өздереп әйтә ала.

- Кумәк хуҗалыкны имәргә, аның исәбенә яшәргә теләүчеләр елдан-ел арта, - ди Җәүдәт борчылып, - күп кенә арадашчы оешмаларны бетерергә вакыт.

Уңышларның тагын бер сәбәбе шунда: Җәүдәт үзе кебек үк тынгысыз белгечләр туплый алган, аларга иҗади эшкә юл ачкан. Хуҗалыкның баш агрономы, Татарстанның атказанган агрономы Рөстәм Әюпов, баш зоотехник, Татарстанның атказанган зоотехнигы Фариз Җамалетдинов, мөгезле эре терлекчелек комплексы мөдире Заһир Мөхәммәтҗанов үз тармакларының оста оештыручылары.

Хуҗалыкның Өчмунча авылына барып чыксагыз, фермаларда, я булмаса ремонт мастерскоенда, җитез хәрәкәтле, чибәр ханымны очратырсыз. Шушы авылның комплекслы бригада бригадиры, Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре Флера Шәрәфетдинова ул. Өчмунча 75 йортлы авыл. Янәшәдәге Күзби авылы да шушы бригадага керә. Флера унҗиде ел инде бригадир вазыйфасын башкара. Бу бригада эшчәннәре терлек тә симертәләр, иген дә, чөгендер дә үстерәләр. Механизаторларның, шоферларның ниндиләре генә юк. Ләкин Флераны тыңлыйлар, аның белән киңәшләшәләр. Чөнки барысы да яхшы белә: Флера кумәк эш өчен янып йөри, кирәк чакта авылдашларына ярдәм итәргә әзер. Берничә ел элек Флера Шәрәфетдинованы Россия колхозчылары съездына вәкил итеп тә җибәргәннәр иде.

Кумәк хуҗалык белән мәктәп арасында да чын хезмәттәшлек урнашкан. Җәүдәт еш кына мәктәпне урап чыга, мәктәп директоры Зөбәйдә Гыйлаҗеваны да рәис булмәсендә еш очратырга мөмкин. Былтыр мәктәп укучылары хуҗалыкка 30 гектар чөгендер үстереп биргәннәр. Хуҗалык мәктәпне ит, сөт, икмәк белән бушлай тәэмин итә. Балалар бәрәңге, яшелчәне үзләре үстерәләр. Шуңа да мәктәп балалары өчен төшке аш бушлай.

Авылда кыш. Терлекчелектә киеренке көннәр, тиздән язгы кыр эшләре дә килеп җитәр. Техникасын әзерлисе, запас частьлар табасы бар. Рәиснең мәшәкатьләре күп. Ул кичне без Җәүдәт белән колхоз идарәсендә озак утырдык. Җәүдәт ел йомгаклары турында сөйләде, алга яңа планнар корды. Идарәдән чыкканда зәңгәр күктә бихисап йолдызлар балкыган иде. Кышкы авылда алар күк йөзендә аеруча яктырып яна кебек. Без Җәүдәт белән шул йолдызларга карап тордык.

- Әнә, Җидегән йолдызны күрәсеңме? Нинди якты яна, - ди Җәүдәт. - Мин дә хуҗалыкка кергән җиде авылны шул Җидегән йолдызга охшатам.

Җиде авыл: Черки Килдураз, Үгез Куагы, Кабалан, Күзби, Иске Лощи, Бәбки, Өчмунча бүген бер йодрыкка берләшеп, кумәк хуҗалыкка оешып, Буа районында, алай гына түгел, Татарстан авыл хуҗалыгы күгендә Җидегән йолдыздай якты яналар.

Киләчәктә дә сүнмәсен бу йолдызлар, аларның балкышы, аларның даны тагын да еракларга китсен.

Ә. МӨНИРОВ.

С. ИСХАКОВ фотолары.

Казан сөт комбинаты
директоры
Әхмәтгали ГАТАУЛЛИН



Казан *СӨТ КОМБИНАТЫНДА* яңарыш

Казан сөт комбинаты директоры Әхмәтгали Гатауллин безне ачык йөз белән каршылады. Кәефе күтәренке иде аның. Моңа сәбәбе дә бар икән, әле кичә генә Татарстан премьер-министр урынбасары - республиканың авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов белән Канаданың Квебек провинциясеннән кайтып төшкәннәр.

Квебекта бик зурлап, хәтта Татарстан флагын күтәреп каршы алганнар. Әлбәттә, сүз икътисадый бәйләнешләрне ныгыту турында барган.

- Казан кадәр Казанда сыр эшләнми. Ә сырга ихтыяҗ зур. Бу мәсьәләне хәл итү турында күптән сөйләшә идек, - ди Әхмәтгали Мөхәммәтдинович. - Ниһаять, Квебек провинциясендә килешүгә ирештек. Сыр эшләү өчен Канада технологиясен сатып алачакбыз.

- Димәк, Казанның үз сыры булачак?

- Әлбәттә. Сыр өр-яңа технология нигезендә эшләнәчәк һәм бик яхшы сыйфатлы булачак.

Әхмәтгали Гатауллинның Казан сөт комбинаты директоры камытын киюенә икенче ел гына әле. Ул шактый еллар Мамадыш районының "Родина" колхозын җитәкләде, аннары сигез ел "Мамадыш" май заводы директоры вазыйфасын башкарды. Бик күп яңалыклар кертте ул Мамадыш заводында: зур суыткычлар төзеде, яңа төр продукцияләр эшләп чыгара башлады. Мамадыш май заводы "Татарстан сөте" берләшмәсендә һәрчак алдынгылыкны тотты.

Бернічә ел элек Казан сөт комбинаты артка тәгәри башлады. Сөт эшкәртү күләме кимеде, шәһәрдә сөткә, эремчеккә, каймакка зур-зур чиратлар хасил булды. Җитәкчелекне алыштырырга туры килде. Зур корабка - зур диңгез, дигәндәй, тармакта олы тәҗрибә туплаган Әхмәтгали Гатауллинны әлеге комбинатка директор итеп чакырдылар. Мамадышта барысы да көйләнгән, җайланган булса да, Әхмәтгали Мөхәммәтдинович Президент тәкъдименә каршы килә алмады.

Казан сөт комбинаты үзенең зурлыгы белән дә, эшләп чыгара торган продукциянең төрләре белән дә республикада беренчелекне тота. 1932 елда нигез салынган бу завод ел саен диярлек куәтен арттыра бара. Туксанынчы еллар башында 4 яңа корпус төзелде. Хәзер завод тәүлегенә 500 тоннадан артык сөт эшкәртергә сәләтле.

Һәр көнне заводның йөздән артык машинасы Буа, Апас, Арча, Балтач, Питрәч ягына - барлыгы 15 районга чыгып китә. Кышкы чорда сөт кимегән. Шулай да һәр көнне 260-280 тонна сөт китерелә бирегә.

- Бигрәк тә сөт безгә Балтачтан күп килә, - ди директор. - Менә бүген кабул ителгән 240 тонна сөтнең 25 проценты - Балтачныкы.

Бүген комбинатта көн саен 4,5 тонна май, 80-90 тонна сөт, 50 тонна катык, кефир, төрле йогуртлар, 8-9 тонна эремчек, 11 тонна каймак, башка күп төр продукция эшләп чыгарыла. Барлыгы 101 исемдә продукция сәүдә челтәренә озатыла.

Бирегә килгәч тә, Әхмәтгали Мөхәммәтдинович яңа төр продукцияләр эшләп чыгаруга җиң сызганып керешә. Кыска гына вакытта 10 төрдәге сөт ашамлыгы чыгару үзләштерелгән. Хәзер бигрәк тә кеше организмы өчен кирәкле бактерияләр булган эрокон, тонус, биойогурт кебек ашамлыклар чыгаруга игътибар арткан. "Бифидук" һәм "Бәйрәм" дигән ризыклар Бөтенроссия конкурсында "Россиянең 100 иң яхшы товары" дигән дипломга лаек булган.

Менә без заводның лабораториясендә. Нәкъ бирeдә яңа төр продукция әзерләнә һәм тикшерелә. Лабораториягә утыз елдан артык биолог Людмила Ивановна Лукина җитәкчелек итә.

- Соңгы вакытта кешенең ашказаны һәм эчәкләре өчен файдалы бактерияләр булган сөт ашамлыкларына сорау артты, - ди Людмила Ивановна. - Без чыгара башлаган эрокон, биотонус, биойогурт һәм башка шундый ризыклар кеше организмына бик файдалы.

Сөт бүлү цехында 40 тан артык кеше эшли. Чистартылган, тиешле майлылыкка җиткерелгән сөт олы-олы мичкәләргә килә, ә аннары махсус аппаратлардан пленка савытларга тутырылып конвейерларга төшә. Пленкаларга салынган сөтне операторлар тартмаларга тутыра баралар. Кайбер көннәрдә 125 тонна сөт савытларга тутырылып, сәүдәгә җибәрелә. Бер операторның кулыннан сменага 5-6 тонна сөт үтә. Операторлар Фирая Шиһапова, Резидә Минһаҗева бирeдә ун елдан артык эшлиләр.

Татарстан азык-төлек эшкәртү промышленностеның атказанган хезмәткәре Әхмәтгали Гатауллин бирегә килгәч тә, комбинатта күп кенә матур үзгәрешләр булган. Ике пар казаны эшкә җибәрелгән, күп кенә цехларга ремонт үткәрелгән. Завод территориясендә минераль су барлыгы ачыкланган. Киләчәктә бирeдә минераль су чыгарырга да исәп тоталар. Сөт эшкәртү күләме дә арткан. 1998 елда тәүлегенә 264 тонна сөт эшкәртелсә, 1999 елда ул 307 тоннага җиткән. Комбинатның 40 тан артык кибете бар.

Ләкин комбинаттагы бу матур эшләр кемнәргәдер ошамый икән. Бөтен хикмәт тә шунда, моннан ике ел элек комбинатны "яңа байлар" үз кулларына төшерергә әзерләнгәннәр. Шул максатта акцияләр әзерләп куйганнар. Ләкин "Татарстан сөте"нең яңа генераль директоры Вәгыйз Минһаҗев һәм комбинат директоры Әхмәтгали Гатауллин моңа чик куйганнар. Комбинат акцияләренең бер өлеше дәүләт кулында, бер өлеше - коллектив әгъзаларыныкы. Казан сөт комбинаты кебек "майлы калҗаны" кулына эләктерә алмаган "яңа байлар" астыртын көрәш башлаганнар. Төрле тикшерүләр белән йөдәтәләр, матбугатта атакалар оештыралар.

Мамадышта ачыктан-ачык эшләргә өйрәнгән, итагатьле Әхмәтгали Гатауллинны бу астыртын уеннар бик борчый, әлбәттә. Әйе, дәүләт, халык мәнфәгатьләрен саклаучы принципиаль директорларга каршы бездә нинди генә әшәке алымнар кулланмыйлар, төрле алымнар белән үз юлларыннан алып аталар, куркыту, хәтта җинаять юлына басалар. Казан сөт комбинатында бүген халык һәм дәүләт мәнфәгатьләрен саклаучы җитәкчеләр эшли. Димәк, аларга хөкүмәт тә, хокук саклау органнары да даими ярдәм итәргә бурычлы.

М. АБДУЛОВ.

А. Титов һәм С. Исхаков фотолары.

Башка чыккан МАКСАБАШта

Университет китапханәсенең библиография бүлегендә кызыклы гына китап исеме күземә чалынды. Үземнең туган якка кагылышлы булганга күрә, 1890 елда ук чыккан бу китапны яздырып алып укырга булдым. Лаеш өязе земский идарәсе әгъзасы С. М. Палицын тарафыннан төзелгән "Олы Кибәхуҗа волостеның икътисадый хәле турында хисап" иде бу. Лаештан килгән чиновник безнең Теләче ягында ревизия ясаган: халык санын алган, кайсы авылда нинди кәсепһөнәр белән шөгыльләнүләрен һәм дәүләткә күпме салым түләүләрен ачыклаган. Аеруча кызыклысы шул, белгеч-агроном буларак, Палицын җирләрнең уңдырышлылыгын да өйрәнгән. Аның анализыннан күренгәнчә, Олы Кибәхуҗа волостеның гумуска бай туфраклы иң уңдырышлы җирләре - Макса елгасының түбәнге ягындагы һәм Мишә елгасы буйларындагы урыннар. Нәкъ шуңа күрә дә бу җирләрдә Теләче, Ачы, Белогорка, Аннинское һәм Екатериновка авылы урыслары иген игә. Ә менә уңдырышсыз җирләр төньяктарак, Макса елгасының башланган урыннарында - татарлар яши торган авыллар тирәсендә. Иң уңдырышсыз, көлсу туфраклы җир буларак Палицын әфәнде Максабаш авылы басуларын күрсәтә, биредә иген игү белән шөгыльләнүнең мәгънәсезлеген әйтә...

Бүген "Максабаш" - Теләче районының гына түгел, республиканың әйдәп баручы кумәк хуҗалыкларыннан. Дөрес тәрбия күрсәтсәң, иң уңдырышсыз саналган җир дә игенчене мул уңышы белән куандыра икән. Әнә, гаять уңайсыз һава шартлары белән истә калган узган елны да максабашлылар һәр гектардан 19 центнер уңыш җыеп алганнар.

Хәер, бүген аларның төп мактанычлары - игенчелек түгел, терлекчелек. Узган ел мөгезле эре терлекнең тәүлеклек үсешен 804 граммга, дуңгызларныкын 461 граммга җиткергәннәр. Нәтиҗәдә кечкенә генә бу хуҗалык бер ел эчендә 3 мең центнердан артык ит сата алган. Сөтчелек тармагы да уңышлы эшли: һәр сыердан бер елга уртача 6 мең килограмм чамасы сөт савып алынган.

Болары - саннар. Алар артында исә Максабаш уңганнарының көндәлек борчу-мәшәкатьләре, тырыш хезмәте.

Максабаш халкы гомер-гомергә ялкау булмады анысы. Шулай да бүгенгедәй матур итеп, башкаларны көнләштерерлек итеп яши белмәделәр. Чөнки гомерләре буе, эре "Чулпан" колхозының кечкенә генә бер бригадасы булып, колхоз үзәге Югары Кибәхуҗаны үстерүгә көч куйдылар. Шуңа да Максабашның балалары белем үзләштерергә, яшьҗилкенчәге күңел ачарга, өлкәннәре гозерләрен үтәргә дип колхоз үзәге белән ике арадагы биш чакрым юлны таптап яшәргә мәҗбүр булды. Тәмәке төтененнән корымланып беткән иске каравыл йортыннан башка бригаданың бер генә җәмәгать бинасы да, юньлебашлы амбар-фермалары да юк иде. Туксанынчы еллар башында Максабаш халкы "Чулпан"нан аерылып башка чыгарга карар кылды. Үзләренең бу кыю адымнарына бүген дә сөенеп туя алмыйлар.

Башка чыгу бер хәл, үз өстеңә зур җаваплылык алу да дигән сүз бит әле ул. Булган тиенеңне ашап бетермәскә, киләсе көнгә аны тагын арттыру юллары турында уйларга кирәк. Менә монысы инде хуҗалык җитәкчесенә бәйле.

Рәистән уңды Максабаш халкы. Ралиф Хәниф улы Низаметдинов - күрше Югары Кибәхуҗа авылы егете. Кышкы чатнама суыкта да, күзгә яңгыр һәм язгы ташуда да иртәнге сәгать биштә идарәдә белгечләр белән киңәшмәдән эшен башлап җибәрер. Яңа оешкан колхозда ныклы хезмәт дисциплинасы булдыруны әнә шулай үзеннән башлады.

Билгеле, башка чыгуның беренче көнендә үк муллыкка тиенеп булмый. Биредә башта табышлы тармак булган нәсел дуңгызчылыгын үстерүгә күп көч куйдылар. Нәтиҗәдә төзелеш эшләре башлап җибәрү мөмкинлеге туды. Әкренләп яңа социаль объектлар кора башладылар. Соңгы берничә ел эчендә генә дә кумәк хуҗалык көче белән мәһабәт мәктәп, балалар бакчасы, мәчет, китапханә, идарә биналары төзелде. Авылга асфальт, йортларга газ кертелде. Башка чыккан авылда башка чыккан гаиләләргә дә игътибар артты: дистәләрчә йорттан торган яшьләр урамы калкып чыкты. Хәер, яшьләргә генә түгел, йортынкаралтысын яңартырга теләгән теләсә кемгә хуҗалык идарәсе төзелеш материаллары, транспорты белән дә ярдәм итә. Шуңа да авыл көннән-көн үсә, матурлана бара.

Ферма каралтылары, амбаркеләтләр, техника саклау өчен җылытылган биналар төзү аеруча киң колач алды. Узган ел азагында максабашлыларның тәҗрибәсен өйрәнүгә махсус багышланган район семинарында катнашучыларга яңа гына сафка баскан сыер торакларын күрсәттеләр. Шаккатырлык, бүгенге көндә дә шундый олы төзелешләр алып бару мөмкин икән ич! Мондый торакта эшләве үзе бер рәхәт: бар нәрсә механикалаштырылган, җылы суына кадәр бар. Ә малларның көрлеген, чисталыгын күрсәң! Чит ил фермаларың бер якта торсын.

Хуҗалыкның уңышлары хакында сөйләгәндә рәискә игътибар итүебез юкка гына түгел. Бүгенге авыл хуҗалыгы тармагында төп фигура бит ул. Районның хакимият башлыгы Илдар Мөхәммәт улы Низамов сүзләре дә моны раслый. Аның фикеренчә, бүген күмәк хуҗалыкларның тотрыклылыгы басу-кырларының уңдырышлылыгы, халкының уңганлыгына гына түгел, ә беренче чиратта җитәкчесенең эшне дөрес оештыра алуына бәйле. Ралиф Низаметдинов - моның ачык мисалы. Лаеш техникумы биргән икътисадчы белеме аны алга карап эш итәргә, һәр тиенне санарга, сакчыл булырга өйрәткән. Шуңадыр Максабашта хәтта кирпечне дә урамда түгел, җил-яңгыр үтми торган ангарларда саклыйлар. Казан дәүләт университетында үзләштергән филолог белеме исә рәискә кеше күңеленә ачкыч табарга, кешелекле һәм игътибарлы булырга, тормыш һәм яшәеш закончалыкларын тирәнтен аңларга мөмкинлек бирә. Колхоз рәисе булып эшли башлагач та, кеше турында кайгыртуны ул үз эшенең нигез ташы итеп куйды. Вакытында аванс(!) һәм хезмәт хакы алу - бу күмәк хуҗалык өчен шактый еллардан бирле табигый хәл исәпләнә.

Бүгенге авылның хәле җитәкче шәхесенә барып тоташуын "Максабаш" рәисе үзе дә кире какмый. "Колхоз системасы үзен акламады, - ди ул. - Колхозчы күмәк милекнең чын хуҗасы була алмады. Уртак малның иясе юк, диләр бит. Колхозчы мондый шартларда үзен хуҗа итеп тоймый, көн үтсенгә яшәргә, урлашырга мәҗбүр. Хуҗалык җитәкчесе бүген әнә шул уртак малны берләштерүче, саклаучы һәм булдыра алган кадәр арттыручы вазыйфасын башкара".

Ралиф фикеренчә, әлегә авылда хуҗалык итүнең башка формалары, әйтик, фермерчылык өчен тиешле шартлар юк. Шуңа күрә күмәк хуҗалык мөмкинлекләрен файдаланырга кала. Монда инде барысы да үз эшенә бирелгән риясыз җитәкчеләргә бәйле.

Теләче районының Сабадан аерылып чыгып мөстәкыйль яши башлавы да әллә ни күптән түгел әле. Кыска гына вакыт эчендә район хезмәтчәннәре бөтен республикага мактанырлык зур эшләр башкарып өлгерделәр. Бу уңышлар - "Максабаш" кебек күмәк хуҗалыклар ирешкән югары күрсәткечләр нәтиҗәсе, авыл хуҗалыгына бөтен барлыгы белән бирелгән кешеләрнең тырышлык җимеше.

Юк, ялгышкан үткән гасыр чиновнигы Палицын әфәнде. Максабаш җирләрендә дә көн күреп, иген игеп, мал үстереп була икән. Һәм ничек кенә әле! Кеше коры ташлык өстендә дә гөл бакчасы үстерергә сәләтле. Моның өчен ихтыяр һәм теләк кирәк, Ралифлар кебек әйдәп йөрүче фидакарьләр булуы кирәк.

Васил ГАРИФУЛЛИН.

Теләче районы.

А. Титов фотолары.

"ВИРАЖ"

ЯУЛАГАН ҮРЛӘР...

Без юлсыз якта үстек. Апас, Буа, Кайбыч, Кама Тамагы халкы гомер-гомергә юлсызлыктан интекте. Көзге пычракта, кышкы зәһәр бураннарда район үзәгенә ун чакрым ераклыкта гына урнашкан авылдан барып җитү өчен дә икеөч сәгать вакыт уза торган иде. Юлда батып, туңып, өшеп яткан чакларны әйтәсе дә юк.

Ул юл булмаулар! Җанга тия, интектерә торган иде! Шуның аркасында күпме транспорт ватыла, машина йөртүчеләрнең күпме нервысы түгелә. Сөт-итнең табышын да арттырам димә. Туган ягын, туган авылын сагынып чит җирләрдән кайткан кунаклар, мосафирлар никадәр җәфа чиктеләр! Кыскасы, юлсыз тормышның яме дә, тәме дә юк. Безнең якларда кайчандыр кешечә юллар төзерләр дип ул вакытта беркемнең дә башына килмәгәндер шул! Хыял гына иде ул, хыял гына. Тик ни хикмәт, менә шушы зур хыял туксанынчы еллар башында тормышка аша башламасынмы. Ниһаять, безнең төбәктә дә менә дигән матур асфальт юллар төзелде, Казан - Ульяновск трассасы салынды, яхшы юллар авылларга кадәр керде. Ә бу юлларны төзүдә Буаның "Вираж" акционерлык җәмгыяте коллективының өлеше гаять зур. Бу оешманың үткәненә күз салсаң, гаять кызыклы мәгълүматларга тап буласың. Буа шәһәрендә урнашкан, кайчандыр ябылу алдында торган бер кечкенә генә юл төзү

А. Титов фотосы.

оешмасы кинәт кенә югарыга күтәрелеп китә. Сәбәбе нидә? Ул бик тә гади: оешмага яңа җитәкче булып Рәшит Рәкыйп улы Шәйхетдинов килә. Килү белән үк бер генә нәрсә эшли - коллективны акционерлык җәмгыяте итеп үзгәртеп оештыра, тармакны хосусыйлаштыру тәкъдиме белән чыга. Заманы өчен бик тә тәвәккәл адым була бу. Яшерен-батырын түгел, бу гамәлгә шикләнеп караучылар, хәтта каршылар да була. Тик ни генә булмасын, Рәшит Рәкыйповичка ышанган коллектив бу хәлиткеч адымны ясый һәм шуның белән ота. Бүгенге көндә "Вираж" шушы төбәкнең иң алдынгы, иң бай оешмаларыннан берсе. Хәзерге көндә исә оешманы Рәшит Рәкыйп улының бертуган энесе Рафаил Шәйхетдинов җитәкли. Үзе әйтмешли, түбәннән күтәрелгән ул. Гади слесарь булып эшләгән. Бүгенге көндә "Татспиртпром" берләшмәсен җитәкләгән абыйсының дәрәҗәсенә тап төшерә торганнардан түгел. Эшне әйбәт кенә җайга салган, эшчеләр арасында да абруе зур. Төп эш принципы - аз сөйләп, күп эшләү. Шуның өстенә бик таләпчән, яраткан эшенең төмен, ямен тоеп хезмәт итә...

- Әйе, безнең Идел буе халкы гомер-гомергә юлсызлыктан интеккән, - дип башлады ул сүзен. - Юл проблемасын без хәзер хәл итеп киләбез. Без иң элек ни белән алдырабыз соң?! Көчле матди-техник базабыз бар. Асфальт заводыбыз, шулай ук Алманиядән кайтарылган заманча юл төзү техникабыз бар. Шуңа күрә бездә җитештерүчәнлек тотрыклы...

Директор урынбасары Ю. Мартьяновның әйтүенә караганда, оешманың төп максатларыннан берсе булып кешеләргә яңа эш урыннары тудыру тора. Кешеләр эшсезлектән интеккән авыр заманда бу бик тә мөһим нәрсә бит. Трасса янында яңа кемпинглар (ял итү урыннары), ресторاннар, кафелар төзетә алу да моның ачык бер мисалы.

- Безнең төп максатыбыз, - ди Ю. Мартьянов, - юл төзү генә түгел, ә юлдагыларга, ягъни юлда арган-талганнарга ял итү мөмкинлекләре дә тудыру.



"Вираж" акционерлык җәмгыяте генераль директоры Рафаил Шәйхетдинов.

Буа районының Карлы авылы янындагы нарат урманында төзелгән "Орхидея" ял итү комплексы моның бер гүзәл үрнәге. Бу комплексны "Вираж" фәкать үз хисабына төзеткән. Бу гаҗәеп матур комплексның эчен чит ил белгечләре бизәгән, материалларын да, җиһазларын да чит илдән кайтарткаННар. Башкаладан читтә урнашкан Буа шәһәрендә шундый гаҗәеп, затлы комплексның калкып чыгуы шаккатыргыч! Бу комплекска 70 урынлы кунакханә, автосервис, ресторан, җәйге кафе, физиотерапия кабинетлары, бассейн-сауна керә. Куну, ял итү шактый ук кесәгә бәрсә дә, халык өзелеп тормый монда! "Орхидея"дә хәтта Казан, Ульяновск шәһәрләреннән килеп ял итәләр...

Шәһәр хакимияте бу тирәне шәһәр кешеләрен ял иттерү урыны итеп эшләү тәкъдиме белән чыкты. Комплексның бер өлешендә оешма хезмәткәрләрен дәвалау, ял иттерү максатыннан гаилә пансионатлары булдыру каралган.

Бүгенге көндә "Вираж" заказ буенча Буа, Югары Ослан, Апас, Тәтеш, Кайбыч районнарында яңа юллар сала, искеләрен төзәтә. 51 чакрымга сузылган Казан-Ульяновск юлы файдалануга 1993 елда тапшырылган, Казан - Ульяновск трассасы салынып беткәннән соң аның озынлыгы 105 чакрым тәшкил итәчәк. Шуңа күрә дә Югары Ослан районының Макулово авылы янында юл төзү участогы булдырылган.

"Вираж"ның асфальт заводлары турында да әйтеп китмичә булмый. Бүгенге көндә аның өч асфальт заводы бар. Бер завод тәүлегенә



1800 тонна асфальт җитештерә. Битум чыгару базасы да киңәйтелә. Анда елга 15000 тонна сыйфатлы битум җитештерелә. Затлы, катлаулы чит ил машиналарында эшләү өчен кадрлар әзерләү дә бик мөһим мәсьәлә булып тора. Машинистлар, лаборантлар, мастерлар Санкт-Петербург, Казан шәһәрләренә барып, белем алып кайталар. Алар белемнәрен Италия, Алманиянең "Вертген" фирмасында да күтәрәләр.

Эшчеләрнең көнкүрешен яхшырту өчен дә зур эшләр башкарыла монда. Юл төзү участокларында эш фронты киңәю белән, эшчеләрне вакытында тукландыру мәсьәләсе дә килеп туган. Ул да уңай хәл ителгән. Тиз арада 5 ашханә төзегәннәр. "Вираж" оешмасының конторасы янында гына менә дигән "Резедә" кафесын ачканнар. Бу кафега шәһәр кешеләре бик яратып йөри. Сыйфатлы, тәмле итеп пешерәләр монда. Бик күпләр шунда төрле кичәләр, юбилейларын үткәрәләр. Шулай ук бер сменага 700 килограмм икмәк ашамлыклары җитештерә торган ике мини-пекарня да файдалануга тапшырылган. Кибетләр, ашханәләр яңа пешкән икмәк белән вакытында тәэмин ителеп тора. "Вираж" оешмасы ачкан кибетләрнең дә инде саны бихисап. Буа районының Норлат авылындагы ярдәмчел хуҗалык та "Вираж" структурасына керә. Бу авыл таркалу хәленә җиткән була. Норлат - Шәйхетдиновларның туган авылы. Шәйхетдиновлар исә авылны саклап калалар. Бик кыска вакыт эчендә "Вираж" монда ике ындыр табагы, яшелчә саклау склады, сыер фермалары, тегермән, икмәк пекарнясы һәм башка объектлар төзетә. Норлат күзгә күренеп үзгәрә. Мәктәпкә ремонт үткәрелә, йортларга газ кертелә. Авылга кайтучыларның да саны күбәя. Авыл халкы Шәйхетдиновларга бик тә рәхмәтле. Инде хәзер ярдәмчел хуҗалыкның файдасын күрәләр. Аннан "Вираж"ның ашханәләренә яшелчә килеп тора. Оешма хезмәткәрләре Норлат хуҗалыгында җитештерелгән авыл хуҗалыгы продуктларын арзан бәягә алу мөмкинлегенә дә ия.

Шунысы бик мөһим: оешмада хезмәт хакын вакытында биреп барырга тырышалар. Бүгенге көндә биредә 660 тан артык кеше эшли. Эшчеләрне, хезмәткәрләрне торак белән тәэмин итү дә җайга салынган. Аерым йорт төзү өчен хезмәткәрләргә льготалы кредит формасында ссудалар алуда ярдәм итәләр. Нәтиҗәдә ел саен 10-12 шәхси йорт салына.

Бүгенге көндә "Вираж" яңа үрләр яулый, бөтен дөньяга танылa. 1995 елда "Вираж" "Бирмингем факелы" дип аталган халыкара бүләккә лаек булды. Ул һаман үсештә. Алда җитештерү объектларына газ кертү, яңа АЗСлар төзү, эш урыннарын тагын да арттыру мәсьәләсе тора. Рафаил Шәйхетдинов җитәкләгән "Вираж" акционерлык җәмгыятенең аларны да уңышлы хәл итәчәгенә ышаныч зур.

Хәбир ИБРАҺИМ.

Н. Стеганцев фотосы

Альберт ХӘСӘНОВ,
язучы.

“Хуш, авылым!” дияргә ашыкмыйк

(Авылларыбызның бүгенгесе һәм киләчәге турында уйланулар)

Е. Канаев фотосы.

Былтыр көз журналист юллары мине Ютазы районы Бәйрәкә авылына алып килде. Хуҗалык эшләре турында сөйләшү өчен түгел, ә бөтенләй башка максат белән барып чыктым. Көнбатыш Германиянең матур бер каласында, кан кардәшебез, якташыбыз, дөньякүләм танылган композитор Софья ханым Гобәйдуллина яшәп ята. Аһ итә музыка дөньясы аның талантына. Исемен даһилар Штраус, Шопен, Бах, Глинка, Скрябин белән бер рәттән куялар. Бу турыда үзебезнең татар гына белеп бетерми төсле. Хәер, күбебез хәтта бүген дә “Баламишкин”нан катлаулырак музыканы кабул итми. Үзе тырышса да, карыны кабул итми. Нәрсә ерак барып торасы, үзем соң? Үземне белә башлаганнан бирле гармун шыгырдатам. Ничә тальян башына җиттем. Софья ханымның әсәрләрен радиодан ишеткәнем бар, үзе Казанга килгәч, Зур концерт залында да тыңлап чыктым. Дөресен әйтим, алай аһ итмәдем төсле. Сай, болганчык инешләрдә генә чупырдап канәгатьләнү, зур диңгезләр уртасына кереп, колач салып йөзә белмәү үзенә бер милли чиребез, ахры, инде ул. Шушы чир бүгенге эстрадабызда үзен аеруча нык сиздерә. Аларда нинди генә арзан җырлар җырланмый да, нинди генә шакмакка такмак музыка яңгырамый. Ә халык канәгать. Эстрада концертлары укалы кәләпүшен кыңгырт салып, пилмән исе таратып кикергәләп утырган Гаптери агайлар, тешсез авызын ак мамык шәле белән каплап утырган Әсмабикә абыстайлар белән шыгрым тулы. Алар сәхнәгә кем чыгып селкенеп керсә дә кул чабалар.

Ә халкыбызның бер Софья ханым гына түгел, бик күп сокланырдай уллары һәм кызлары бар. Кирза итек балтырын кимерә-кимерә Тын океанны җиңгән Әсхәт Җиһаншинны кем генә белми? Атаклы Роальд Сәгдиев тә, хирург Ренат Акчуриныбыз да, Россия Кораллы Көчләренең горурлыгы, Америка сугыш чукмарларының котын алып торучы “Петр-1” атом-ракета крейсерларының баш конструкторы Наил Гаффаровыбыз да бар.

Бәйрәкә тарафларына мин, үлгәннәрнең каберен, исәннәрнең кадерен бел гыйбарәсен истә тотып барып чыктым. Софья ханым Гобәйдуллина чыгышы белән шушы авылдан бит. Ул суын эчкән чишмәләрне, ялан тәпи чапкан болыннарны, җиләк җыйган аланнарны күрү нияте белән килдем. Узган җәйне бирегә аның апасы, кияве белән кызы кайтып киткәннәр. Көтмәгән эш килеп чыгу, Америкада булуы аркасында Софья ханым үзе кайта алмаган. Әмма шунысы сөендерде, кайда гына яшәсәләр дә, бу кавем балалары үз нигезләрен, аларга яшәргә көч, дәрт, аһәң, моң, сагыш биргән җир-суларын, һавасын, ашыйсы һәр телем ризыгын хәләл көче белән табып яшәгән кан кардәшләрен онытмыйлар, алар алдында үзләрен бурычлы саныйлар.

Дөньяга шундый талант бүләк иткән Бәйрәкәгә көз көне барып чыктым. Һәр йорт каршында ике-өч оя казлар каңгылдаша, һәр ишек алдында үгезмә, танамы, дигәндәй, сугымлык мал печән күши. Урамнан әле тегеләйгә, әле болайга, бик җитди кыяфәттә, бахбаен, алашасын йөгәненнән җитәкләгән агайлар узып киткәли. Боларның шул рәвешчә авылдашларына байлыкларын күрсәтеп, раслап йөрүләре инде. Булса, “Жигули”е дә артык түгел. Авылда алары да җитәрлек. Әмма безнең татар ат асрарга, бахбай тирен иснәргә тырыша инде. Булмаса төшләрендә күрә. Кермәскә соң! Без бит егетләр. Әгәр төпкәрәк төшеп казынсаң, әле 232 нче елларда яшәгән, бөтен дөньяны дер селкеткән, алдынгы отрядлары хәтта Англиягә бәреп кергән, анда Кент каласын төзегән төркиләр патшасы Атилланың оныклары ләбаса! Чимкентка, Ташкентка да нигезне алар салганнар бит.

Бәйрәкәгә ут та, газ да күптән кергән. Бөек Октябрь революциясеннән, колхозлашу чорыннан кала,

авылларыбыз тормышында тагын ике зур вакыйга булды әле.

БЕРЕНЧЕСЕ - ЭЛЕКТРЛАШТЫРУ. Чыра яндырудан кәрәчингә күчкәч тә күрде халык күрмәгәнне. Ут-күз авылда нигездә кәрәчин түгелү аркасында чыга иде. Әбиләр, әнкәйләр, шул ут-күз чыгудан куркып, кәрәчин тутырган чиреклəрне кая гына яшермәсләр иде... Электр утлары балку авылларыбызның йөзен танымаслык үзгәртте. Анысы һәркемнең күз алдында.

ИКЕНЧЕСЕ - ГАЗ КЕРҮ. Монысы инде авылларыбыз үз тарихында кичергән бар вакыйгалардан да әһәмиятлерәк. Кышка утын хәстәрләү мәшәкате белән авыл халкы иртә җәй башыннан ук иза чигә башлый бит, җанашларым. Кышны өч ай гына дип китапларда гына язалар. Чынлыкта ул бездә унбер айга сузыла. Сырган чалбар, башка бүрек киеп Сабан туена төшкән еллар азмыни? Яшәгән, гомер иткән куышың дүрт почмаклы гына булса да, ике “КамАЗ” каен утынсыз кышны исән-имин чыгармын димә. Ул ике “КамАЗ” утынны каян алырга? Әйләнә-тирәдәге якынрак урманнарны авыл халкы авыр сугыш елларында ук кырып бетерде. Күп авыллар делянкаларны хәзер илле-ике йөз чакрым ераклыктагы урманнардан барып алалар. Авылда халыкның бар урта хәллесе, карт-корысы, ялгыз карчыклары бар. Ул ялгыз карчык, бичара, “КамАЗ”ын каян таба да, төяүчеләрен ничек яллый? Китерткән өчен түләргә акчасын каян алсын?

Өстән-өстән генә язганда да хәлләр шулай. Ә төпкәрәк китсәң, ерып чыгышлы түгел. Шөкер, шунысы куаныч, газ кермәгән авылларыбыз бармак белән генә санарлык калып бара бугай.

Безнең татар йорт-җир, каралтыкураны гөл итеп тота. Газ керү белән утын хәстәрләү мәшәкатьләреннән кулы бушады, җиңен сызганып, татлы йокысын онытып, йорт-җирен яңабаштан корырга, нигезен заманча бизәргә кереште.

Авыл турында сүз кузгатсаң, бер нәрсә нык борчый - эчүчелек. Бу зәхмәт авылларыбызда, ни кызганыч, көннән-көн котыра бара. Бу турыда күп тапкырлар уйланганым бар. Татар авылларына эчүчелекне, аракы дигән зәхмәтне Бөек Ватан сугышыннан исән калган геройлар алып кайттылар. Биш ел салкын окопларда аунап, күп тапкырлар җәрәхәт алып, һәр көн “Жуковский сто грамм”га күнегеп, алар авылга кайткач та шул көйне куа башладылар. Кумаска соң! Татар егетләре яуга киткәндә генә өерләре белән киттеләр. Ә сугыш кырыннан бик сирәкләре генә исән кайтты. Аларының дәрәҗәләре зур булды. Кайсы йортка керсәләр дә, якты йөз, ачык чырай, сырасы булмаса, әче бал, күмүшкә.

Авыл җирләрендә ирләрнең эчүләре әле бер хәл. Яшь кенә хатыннарның эчүе гарасат төсе алды. Анысына, минемчә, нәрсә сәбәпче? Безнең нечкә билләребездә алкоголизмга каршы иммунитет дигән нәрсә юк. Христиан дине тотучы халымнарда юк дисәң дә бар. Русьнең әлеге динне кабул итүенә мең елдан артык. Шул көннән алып санаганда да, алкогольне әз-әзләп капканда да, кеше организмында бу хәтәр продуктка каршы иммунитет туган. Ә ислам дине, бу нәрсәне кеше организмы өчен хәрәм дип раслап, мөселманнарны Октябрь революциясенә кадәр эчүчелектән тыеп, саклап килде. Яңа хакимият, нинди хәл ул, хатын-кызлар ирләр белән бер хокуклы, матуркайларыбызның тәмам башын катырып, аларны мәҗлес өстәлләре артына да ирләр белән бергә утырта башлады. Ә мәҗлес табыннарының кайсысы хәмерсез, исерткеч эчемлекләрсез була инде? Алай ирләр белән тигез хокуклы булгач, нечкә билләребез дә хәмерне ирләр белән чәкештереп җибәрә башладылар. Ә иммунитет юк. Моңарчы ислам динен тотып, әдәп-тәртип белән яшәгән җанда каян булсын ул? Әлеге шушы фикеремне тагын күп мисаллар белән раслап булыр иде дә, ярар инде...

Бер-бер йомышың төшеп, берәр авылга барып керсәң, рәис каршына бармыйча, тагын кая барасың? Элек җиңелрәк иде. Беразын арттырып сөйләсә дә, партком дигән шома егетләр бар иде авылда. Эшне аның белән йөртә идек. Хәзер алар юк шул. Авыл хәтле авыл идеологсыз калды. Мәчет тирәсендә чуалучыларның бармакка чорнарлык та гыйлемнәре юк: диамат, истмат тәгълиматын белмиләр, укымаганнар, ислам кануннарын таратырлык кодрәтләре юк. Хәтәр хәл бу. Чөнки “Природа не терпит пустоты”, дип кисәтә безне шул ук диалектик материализм. Әй-е, рәис каршына бармый, тагын кая барасың? Бәйрәкәнең калку бер җирен бизәгән ике катлы таш бинаның Уралның ак мәрмәр ташларыннан түшәгән баскычлардан “Бәйрәкә” күмәк хуҗалыгы рәисе Сирин Әхәтович Галиев кабинетына күтәреләм.

Бер эшкуар егет Уралның үзеннән үк “КамАЗ”га металл төяп китергән. Алып килгән металлын “Бәйрәкә” күмәк хуҗалыгына яхшы гына бәягә сыламакчы була. Аларның нәкъ менә сатулашкан вакытына туры килдем.

- Бәяне бик югары куйгансыз, ала алмыйм, - ди хуҗа. Эшкуар егет исә әле валидол каба, әле йөрәген тота.

- Ә сез биргән бәягә йөгемне бушатсам, үзебезгә кая ул майлы калҗа, ун тиен дә файда калмый... Җиде йөз чакрымнар машина куып килдем бит мин...

- Нишләтим соң, җаным? - ди хуҗа. Аның кулында белешмәләр. - Менә күрше генә Самарада шушы ук металлны шактый юньрәк бәягә тәкъдим итәләр. Үз “КамАЗ”ыбызны җибәреп, ягулык чыгымын исәпкә алсаң да, күп арзангарак төшәчәк.

Әлеге егет тагын йөрәген тота, тагын валидол эчә. Аны да аңларга була. Металлын кире Уралга төяп кайтсынмени?

- Мин аңлыйм сине, - ди Сирин Әхәтович. - Мине дә аңла. Кассабыздагы акча минеке түгел, дүрт йөз пенсионерныкы, өч йөз сиксән күмәк хуҗалыгы әгъзаларыныкы. Алар акчасы белән үзем теләгәнчә кылана алмыйм.

Ике арада барган бу дуэльне бик кызыксынып күзәттем. Ике сәгатьләр генә баргандыр ул. Ахырда килештеләр. Үзенә бик кирәкле металлны төяп капка төбенә килеп туктаган “КамАЗ”ны Сирин Әхәтовичның да кире борасы килмәгәндер. Тимер төяп килгән егет тә бәяне шактый төшерде.



А. Титов фотосы.

"Бәйрәкә" күмәк хуҗалыгы башлыгы Сирин Галиев колхозчыларына хезмәт хакын аена ике тапкыр түләп бара. Хуҗалыкның 7.800 гектар җире бар. Шуның 6.700 гектары чәчүлек җирләр. Хуҗалыкның 3847 баш мөгезле эре терлеге бар. Шулардан бер меңе савым сыерлар. Асраган һәр аяклы малдан мул продукт алу кирәген монда һәркем лозунгларсыз да аңлый. Бер сөтлебикәдән көненә ун литр савасың икән, димәк, бер сыерың көненә илле сум табыш китерә. Йөз башы - биш мең сум! Меңе - илле мең сум! Хуҗалыкта тәртип әнә шундый максатка корылган. Бик аңлаешлы арифметика!

Бәйрәкәлеләр 3.500 баш сарык та асрыйлар. Бу тармак шулай ук ярыйсы гына табыш китерә. Сирин Әхәтович, кайбер хуҗалык башлыклары төсле: - Аһ, узган ел корылык булды ләбаса! - дип бот чапмый. Уңышны ул һәр гектардан 24 әр центнер җыйган. Кыскасы, аягын терәп тормыш итеп ята. Бәйрәкәдә киң колач белән төзелеш алып бара, хуҗалыкның каралтыларын ныгыта. Мин булган көнне монда яңа ашханә ачтылар. Аның матурлыгын, югары зәвык белән бизәлүен сөйләп бирешле түгел. Керсәң, чыгасың килмәс.

Республикада күп хуҗалыклар бүген кутәрмәгә калганда "Бәйрәкә" күмәк хуҗалыгы ничек соң шулай иркен яши? Каян акча таба? Беренчедән, Сирин Галиев аек акыллы, зур тәҗрибә туплаган җитәкче. Счет төймәсен дә бик оста тарта. Базар мөнәсәбәтләренә дә тиз җайлашкан.

- Бу операциядән хуҗалыкка ун тиен файда, менә монысыннан бер сум, - дип уйната ул счет төймәләрен.

"Бәйрәкә" күмәк хуҗалыгының дүрт кибете бар. Икесе янәшәдәге Октябрьск каласында. Берсе авылда, берсе Ютазы район үзәге Уруссуда. Дүрт кибеттә унбишләп сатучы, ике белгеч. Кибетләрне халык сораган товарлар белән тәэмин итеп торырга да кирәк бит әле. Көнлек саучан сөтне Азнакайга илтеп, катык, эремчек, каймак, май ясатып алалар. Суйган малларны да шунда илтеп, колбаса, фаршлар ясатып кайтаралар.

- Һәр кибетебез көнгә 20-25 мең сум табыш бирә. Шулардан килгән акчага хезмәт хакы, салым түлибез, - дип сөйли Сирин Әхәтович. - Яңа техника алырга, төзелешкә дә кала әле.

Фермерлык та, арендаторлык та, күмәк хуҗалыклар да әйбәт көрәнеш. Дәртең, кодрәтең бар икән, барысын татып кара. Үземне исә шул нәрсә борчый - колхозларның язмышы. Башта авыл халкын, иген үстерүчеләрне кыйный-кыйный көчләп колхозларга керттек. Аннары, аларның ризалыгын да сорамый, колхозларны тарата башладык. Нинди бетмәс экспериментлар инде бу?

Җир белән эш итү, аннан уңыш алу нияте, адәм баласы кулына китмән алган көннән үк берләшүне таләп иткән. Җир өстендә ул никадәр генә уңдырышлы, никадәр генә җылы климатта булса да, бер ялгызың әллә ни майтара алмыйсың. Берләшми хәлең юк. Аның формалары байтак. Зур Совет Энциклопедиясенең 1975 елгы III нче басмасының 19 нчы томының 760 нчы битеннән "Парцеллярное хозяйство" дигән мәкаләне укып күп нәрсәне аңларга була. Ә менә коллективизация, ягъни иген игүчеләрне колхозларга берләштерү, минемчә, җирдән файдалану өлкәсендә кешелек ирешкән иң бөек казаныш. Коммунистлар да, әле хакимияткә килгәнче үк, унар-унбишәр ел патша казематларында ятып, ашыкмый, кабаланмый гына бу мәсьәләне һәрьяклап өйрәнгәннәр. Аларның беренче корылтайларыннан алып соңгысына кадәр авыл хуҗалыгы мәсьәләсе иң төп проблемаларның берсе итеп каралып, тикшеренеп килде. Үзләре торгызган бастионны үзләре үк җимерделәр дә. Чөнки җитештерелгән ашлыкның бөртегенә кадәр себереп алып, авыл кешесен бушка эшләтеп, күмәк хуҗалыктан күңелен биздерделәр. Өстәвенә кулыннан мыскал эш килмәгән бер тәлинкә яларны колхозга җитәкче итеп куйдылар. Бу исерекбаш әлеге хуҗалыкны тәмам тараткач, аны икенче колхозга рәис итеп күчерәләр иде. Хәтеремдә, Лениногорск районының Мичурин исемендәге колхозында бер исерекбашны рәис итеп кую өчен унике көн рәттән бардык. Ул вакыттагы райком секретаре Абдрахманов авыл халкын нинди юллар булса, шулар белән куркытты. Тәки сайлатты. Хәзер дә аптырыйм, ни өчен шулхәтле тырышкандыр? Ул шулай көчләп сайлаткан рәис Мичурин авылына мыскал да файда китермәде. Хуҗалыкны тәмам аяксыз калдырды.

Бу юлларны ни өчен язам, диегез әле? Әлеге сорауларымны "Бәйрәкә" күмәк хуҗалык башлыгы Сирин Әхәтович Галиевкә дә бирмәкчемен.

- Авылларыбыз нинди юнәлештәрәк үсәр икән? Иген үстерүчеләр, мал симертүчеләр үзләре ничек яшәргә телиләр? Фермер, арендатор, аерым хуҗалык булыпмы, әллә колхозга берләшепме?

- Бер болганмый су да тынмый, диләрме әле? - булды Сирин Әхәтовичның җавабы. - Болганып алырга кирәгие. Озак еллар йөзә торгач, корабларның да төпләренә төрле кабырчыклар ябыша. Кораб тизлеген, тигезлеген югалта. Алардан котылмасаң, вакытында кырып төшермәсәң, батуың да бар. Колхозчылар белән дә шулай булды. Алар хисабына рәхәт яшәүчеләр күбәйде. Үзләреннән әллә ни өлеш кертмичә дә. Мин күмәк хуҗалыкларны саклау ягында. Кәтүлек-чәчүлекләрнең кадерен белеп, саклап, фәнни казанышларга таянып киң мәйданнарда мул ашлык үстерергә, бер түбә астында меңнәрчә баш эре һәм вак терлекләр асрарга мөмкинлек бирә ул. Дөрес, уңган, тырыш кешеләр хезмәтенә тиешенчә түләнергә дә тиеш.

Шушында туып-үскән, хәзер инде өч бала атасы, бу хуҗалыкны уналтынчы елын җитәкләүче Сирин Галиевкә, алай түгел ләбаса, дип әйтергә тел әйләнми. Үзенең хаклыгын ул һәр сүзе белән раслый, һәр җөмләсе белән ышандыра.

Авылларыбыз Сирин Галиев кебек аек акыллы, дөньяга киң карашлы, үзенең хаклыгына нык ышанган остазлар җитәкләгәндә нигә аякка басмасыннар, гөрләп чәчәк атмасыннар икән? Бәйрәкәдән мин шундый уйлар белән киттем. Һәрхәлдә, "Хуш, авылым", дип әйтергә ашыкмыйк әле, кардәшләр.

Россиянең бик күп төбәкләрендә төзелеш туктап калганда, республикабызда ел саен дистәләрчә мәктәпләр, хастаханәләр, балалар бакчалары, мәдәният йортлары, бик күп торак йортлар сафка баса. Бу объектларның төп өлеше бюджет исәбенә төзелә һәм алар проектлаудан алып соңгы кадак какканга кадәр "Татглавинвестстрой" идарәсе күзәтүе астында башкарыла. 1996 елга кадәр Татарстан Министрлар Кабинеты каршындагы капиталь төзелеш идарәсе дип йөртелгән әлеге оешмага быел 40 ел тула.

Әлеге идарәгә соңгы ундүрт ел буена Татарстанның атказанган төзүчесе, "Почет билгесе" ордены кавалеры - **Рим Шәфыйк улы Халитов** җитәкчелек итә.

Мөнир ӘҺЛИУЛЛИН

Дала егете КАЛАДА

Ул көнне без "Татглавинвестстрой" идарәсе башлыгы Рим Шәфыйкович Халитовның иркен эш бүлмәсендә кичке сәгать алтыдан соң гына очраша алдык. Рим Шәфыйковичның күңеле күтәренке, кәефе яхшы иде. Шатланырлык та бит! Бүген бик мөһим объект - республика онкология үзәгенең дәвалау корпусы сафка басты. Моны ачуга Президент М. Ш. Шәймиев үзе килде. Җиде катлы бинадагы дәвалау бүлмәләре, палаталар, радиация ярдәмендә дәвалау блогы белән танышкач, төзүчеләргә рәхмәт әйтте.

- Молодцы, сүзегездә тордыгыз, - диде Президент, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры Илдус Шәйдуллин һәм "Главинвестстрой" начальнигы Рим Халитовның кулын кысып.

Яман шештән дәвалау үзәгенең бу корпусына нигез моннан 20 ел элек салынган иде. Шул елларда аны күп тапкырлар башладылар да... ташладылар. Ә дәвалау үзәгендә авыруларга урын җитми, хәтта коридорлар тулы. Узган елның 17 апрелендә бирегә Президент килде. Шунда табибларның үтенече хакында җентекләп сөйләштеләр. Ходай кешегә яман шеш бирмәсен, бирсә инде андый авыруларны юньле шартларда дәваларга кирәк ичмасам! Моны Президент та яхшы аңлый,йөрәк түреннән кичерә.

- Бүген 17 апрель, - ди Минтимер Шәрипович, - 26 декабрьдә дәвалау корпусын кабул итәргә киләм. Сметасын төзегез, тиешле акча бүленер.

Президент сүзе - закон. Бинаны сафка бастыру өчен бюджеттан 30 миллион сум акча бүленде. Дәвалау корпусындагы бөтен эшләрне оештыру "Татглавинвестстрой" идарәсе башлыгы Рим Халитовка йөкләнә. Рим Шәфыйкович, идарә хезмәткәрләре тиз арада тиешле документлар әзерлиләр, бирердәге эшләрне башкару Казандагы "Теплоэнергострой-2" һәм Чаллыдагы "Отделстрой-2" идарәләре төзүчеләренә тапшырыла. Бер үк вакытта палаталарга мебель, кровать, урын-җир кирәк-яраклары кайтартыла. Җәен дә, көзен дә тәүлек әйләнәсенә эш кайный. Рим Шәфыйкович атнасына берничә тапкыр үзе төзелештә була, штаб утырышларын алып бара.

- Президент 26 декабрьдә килергә вәгъдә итсә дә, тик 29 декабрьдә генә килә алды, - ди Рим Шәфыйкович. - Ул көнгә барысы да әзер иде. Илбашыбыз бик канәгать калды.

Без әлегә тик бер объект турында сүз алып бардык. Ә Рим Халитов йөрәге аша үткән, аның күңелендә бик күп борчылулар һәм сөенечләр калдырган андый объектлар йөзләрчә бит! Хикмәт шунда, бүгенге "Татглавинвестстрой" идарәсе 1996 елга кадәр Татарстан Министрлар Кабинеты каршындагы капиталь төзелеш (УКС) идарәсе дип йөртелде. Югарыдан да, түбәннән дә килгән барлык гозерләр шушы идарәгә, дөресрәге, идарә башлыгы Рим Халитов өстәлөнә килеп төшә. Идарә начальнигы Р. Ш. Халитов бер үк вакытта Татарстан төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры урынбасары да. Шуңа да аңа республика төзелеш комплексын үстерү, аны инвестицияләү һәм төзелеш оешмаларының эшчәнлеген координацияләү бурычлары йөкләнгән.

Рим Шәфыйкович ачык йөзле, җитез хәрәкәтле, төрле киңәшмәләрдә дә үз сүзен өздереп әйтә торган төзүче-инженер. Дала егете ул. Оренбург өлкәсенең Матвеевка районының Югары Яңа-Кәтләмәт авылында гади колхозчы Шәфыйк ага һәм Фатыйма апа гаиләсендә баһадирдай өч егет үсә: Марс, Рим, Илдар. Иң беренче булып олы уллары Марс Казанга юнәлә. Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, Аксубай районына эшкә китә. Гомере буе шушы районда. Марс Шәфыйкович берничә хуҗалыкка җитәкчелек итә, ун еллап район авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы була, аннары ун ел-

дан артык - КПСС райкомының беренче секретаре, район хакимияте башлыгы... Уртанчы уллары Рим мәктәпне тәмамлагач та институтка ашыкмый. Бер ел туган авылында тракторчы булып эшли. Бу һөнәргә аны мәктәптә өйрәтеп чыгаралар. Тик икенче елны гына аны ул вакыттагы авыл хуҗалыгы институтының дүртенче курсында укучы абыйсы Марс Казанга алып килә. Күп уйлана торгач, төзүче инженерлар институтын сайлыйлар. Математикадан, сызымнан гел "бишле"гә укучы Рим институтка, кем әйтмешли, җырлап кереп китә. Күп тә үтми аларга өченче энекәшләре Илдар килеп кушыла: ул Казан авиация институтында белем ала башлый. Алгарак китеп булса да әйтим, Илдар Халитов институтны тәмамлагач, эчке эшләр системасына китә. Бүген ул милиция полковнигы, гаять тә җаваплы вазыйфалар башкара.

Рим институтта белем дөньясына чума. Ләкин икенче курста аны хәрби хезмәткә алалар. Өч ел флотта хезмәт итә. Өч елдан соң, буыннары шактый ныгыган диңгезче тельняшкасындагы егет, яңадан институтның икенче курсына укырга кайтып төшә. Институтны 1971 елны тәмамлый Рим. Ә ул Чаллыда төзелеш гөрләгән вакыт. Рим да шунда юнәлә, башта гади мастер, прораб вазыйфаларын башкара. Тынгысыз егеткә игътибар итәләр, "Камгэсэнергострой" берләшмәсенең комсомол комитеты секретаре итеп сайлыйлар. Аннары тагын да җаваплырак эш тапшырыла - КамАЗдагы Бөтенсоюз комсомол төзелеше штабы начальнигы итеп билгеләнә.

- Шулай да ул еллардагы бер истәлекле вакыйганы сөйләгез әле, - дим.

- И, андый вакыйгалар күп булды инде, - уйлап карагыз, көненә илнең төрле почмакларыннан берәр мең егет һәм кыз эшкә килә иде, - ди Рим Шәфыйкович. - Һөнәрләре булганнарны төрле оешмаларга, һөнәрсезләрне уку комбинатларына җибәрә тордык.

Төзелештә берәр авыр хәл килеп туса да, җитәкче агайлар әлеге штабка мөрәҗәгать итәләр. Ремонт-инструментлар заводы КамАЗның беренче заводы. Аны файдалануга тапшырырга йөргәндә бик күңелсез хәл ачыклана: цех идәннәре дөрес җәелмәгән. Комиссия андый идәнгә станоклар куюдан баш тарта, идәнне сүтеп, яңадан җәергә кирәк. Ә аның мәйданы бер гектардан артык.

- Өмет яшьләрдә, - ди ул вакыттагы "Камгэсэнергострой"ның генераль директоры Николай Иванцов бу мәсьәләгә багышланган киңәшмәдә. - Әйдә, Рим, яшьләрдән махсус отряд тупла. Моны хәрби бурыч итеп кабул ит.

Төрле оешмаларга йөреп, Рим 500 таза, булдыклы егетләрне сайлап ала да махсус отряд оештыра. Аларны бер урынга туплый, заводта эшне өч сменада оештыра.

- Әле хәзер дә күңелем ышанмый, - ди Рим Шәфыйкович. - Шулкадәр мәйдандагы идәнне ничек сүтеп, яңасын ничек салганбыз. Ике ай срок биргәннәр иде, без аны ай ярымда төгәлләдек.

Күп тә үтми тынгысыз егетне КПСС өлкә комитетының нефть һәм химия промышленносте бүлегенә эшкә алалар. Биредә ул сигез ел буена нефть һәм газ үткәргечләр төзү мәсьәләләре белән шөгыльләнә. Ә 1984 елны Рим Халитов Министрлар Кабинеты каршындагы капиталь төзелеш идарәсе башлыгы итеп билгеләнә.

Әйткәнебезчә, бу идарә - бюджет исәбенә башкарыла торган төзелешләрнең кайнар ноктасы. Сиксәненче елларда ел саен дистәләрчә мәктәпләр, хастаханәләр, мәдәният сарайлары салынды, йөзләрчә мең квадрат метр мәйданда торак йортлар сафка басты. Рим Халитовка төрле елларда Министрлар Советы рәисләре Г. И. Усманов, М. Ш. Шәймиев, М. Г. Сабиров, Ф. Х. Мөхәммәтшин, Р. Н. Миңнеханов белән эшләргә туры килә. Дөресен әйтик, алар барысы да киң эрудицияле, таләпчән җитәкчеләр, республикада төзелешне киң колач белән алып бардылар. Төзелеш мәсьәләләрен яхшы белүче, тынгысыз Рим Шәфыйкович аларның һәрберсе белән уртак тел таба алган.

- Төзелешне алып бару партия хакимлек иткәндә җиңел идеме, әллә хәзер, базар мөнәсәбәтләренә күчкәчме? - дип сорыйм Рим Шәфыйковичтан.

- Һәр чорның үз уңай һәм кыен яклары бар инде, - ди Рим Шәфыйкович. - Хәзер акча җитешми, ә архитекторларга, төзүчеләргә иҗади эшләргә мөмкинлек күбрәк. Әйтсәң, кеше ышанмаслык хәл. Сиксәненче елларда объектка бер квадрат метр мрамор плитә җәю өчен дә Мәскәүдән рөхсәт алырга кирәк иде.

Чыннан да бүген проектчылар да, төзүчеләр дә берсеннән-берсе матур биналар салалар. Узган ел яңартылган Минзәлә театры бинасына күз салыгыз. Аны танырлык түгел. Казандагы төбәкара диагностика үзәге, Тукай районы үзәк хастаханәсе, Питрәч, Актаныштә, Алабуга районының Морты авылындагы хастаханәләрнең яңа корпусларына сокланмый мөмкин түгел.

Соңгы елларда "Татглавинвестстрой" идарәсенең эш күләме икеләтә диярлек артты. Хикмәт шунда, авыллардагы төзелешләрнең күбесен Татарстан Авыл хуҗалыгы министрлыгы алып барды. Ләкин соңгы елларда министрлыкның моңа мөмкинлеге юк. Республиканың 800 дән артык күмәк хуҗалыкларында төзелә башлаган социаль-мәдәният, көнкүреш объектларының язмышы "Татглавинвестстрой" идарәсе карамагына тапшырылды. Биредә хәзер шул объектлар барлана, аларның күбесендә яңадан эш кайный башлады.

Узган ел Татарстан Министрлар Кабинеты заказы нигезендә 650 миллион сум урынына 1080 миллион сумлык төзелеш эшләре башкарылган. 2000 нче елга бюджеттан төзелеш өчен акча узган елдагыдан 100 миллион сумга күбрәк билгеләнгән.

- Быел - Бөек җиңүнең 55 еллыгы. Хәзер сугыш һәм хезмәт ветераннарын социаль яклауга кагылышлы 12 объект төзелә, - ди Рим Шәфыйкович. - Данлы җиңү көненә аларны өлгертергә тиешбез.

Рим Шәфыйкович Халитовны тагын бер мәсьәлә борчый, ул да булса - төзелешнең сыйфаты. Нәрсә-нәрсә, Рим Шәфыйкович төзелештә эшне аннан-моннан башкарганны, сыйфат бозуны һич кабул итми. Мондый хәл белән очрашса, болай тыныч кына күренгән җитәкче, кем әйтмешли, "шартлый".

- Чын төзүче ул кирпечләрне бер-берсе өстенә салып торучы гына түгел, - ди Рим Шәфыйкович. - Төзүче хастаханә салганда табиб, мәктәп салганда укытучы, мәдәният йорты салганда тамашачы да, артист та булырга тиеш. Төзүче үзен шушы бинада эшләүче кеше кебек хис итсен. Шул вакытта гына ул биналарның якты да, уңайлы да, зәвыклы да булуы турында уйлаячак.

Оренбург өлкәсендә туып-үскән дала егете Рим Халитов бүген Татарстан авыллары һәм шәһәрләре тагын да матур булсын, балалар иркен һәм якты, җылы мәктәпләрдә белем алсыннар, кешеләр уңайлы йортларда яшәсеннәр, ял итсеннәр һәм дәвалансыннар өчен менә шулай бөтен көчен, тырышлыгын куя.

Хезмәт эчендә кайный торгач, 55 яше дә тулган. 55! Ике 5 ле! Киләчәктә дә кылган гамәлләрең, сәламәтлегең, гаилә бәхетең тик шулай "бишле"ләрдән генә торсын, Рим әфәнде!

С. ИСХАКОВ фотосы.

Т. АВДЕЕВА,
Казан икътисад, идарә итү һәм хокук институтының Чаллы филиалы доценты.

Салым сәясәте ник аксый?

Соңгы елларда икътисадчыларны, сәясәтчеләрне бер сорау борчый. Россиядә гадел салым системасы эшләнәме һәм ул дөрес кулланыламы? Югыйсә, күп кенә предприятие җитәкчеләре, чикләнгән җаваплылыкта эшләүче оешмалар, эшмәкәрләр салымнарның биниһая күп төрлелегеннән, шул сәбәпле җитештерелгән продукциядән алынган керемнең 90 процентка якыны дәүләт казнасына китеп барудан, товарны күпләп җитештерүдә беренчи кызыксындыру булмаудан зарланалар. Мондый караш урынсыз ук түгел. Россия базар икътисадына күчкәч, салым теориясе мәсьәләләрен нәтиҗәле куллану максатыннан, аларны ныклап өйрәнү, шулай ук салым системасын камилләштерү юлларын ачыклау ихтыяҗы килеп туды. Салым проблемалары һәрвакыт икътисадчылар һәм дәүләт эшлеклеләренең игътибар үзәгендә булды. Иң беренчеләрдән аның асылын А. Смит дигән галим өйрәнде. 1776 елда басылган “Халык байлыгының туплану сәбәпләрен өйрәнү” дигән китабында ул болай дип язды: “Демократик дәүләтләр үз мөмкинлекләреннән һәм көчләреннән чыгып, хөкүмәтне тотуда (асрауда) катнашырга тиешләр”. Әлеге хезмәтендә А. Смит дөрес оештырылган салым системасы канәгатьләндерергә тиешле дүрт шартны эшләде. Болар салым түләүченең кеременнән алына торган күләмнең чамасы-чамага туры килүе, аныклыгы һәм алдан билгеләнүе, салым җыю ысулының һәм вакытының уңайлыгы, аның югары дәрәҗәдә файдалы булуына бәйле.

Салым теориясен эшләүгә Россиянең Н. Тургенев, А. Тривус, В. Твердохлебов, И. Соколов кебек икътисадчы-галимнәре билгеле дәрәҗәдә үз өлешләрен керттеләр. Н. Тургенев салым белән эш иткәндә аеруча сак булырга чакырды. Аның фикеренчә, салым дигән нәрсә халык байлыгын киметүгә китерә һәм сәнәгатьнең үсешен тоткарлый. Ул тормыш ихтыяҗлары өчен кирәкле әйберләрнең салымнан азат булуын хуплый. “Әмма моның беркайчан да буласы юк”, - дип тә өсти автор.

А. Соколов салым сүзен дәүләт оешмаларында хезмәт итүче аерым кешеләрдән яки хуҗалыклардан үз чыгымнарын каплауны яки тиешлесең бирмичә генә икътисадый сәясәт бурычларын хәл кылуны мәҗбүри җыем белән башкарырга мөмкин дип саный.

Дөрес, кешелек җәмгыятендә салым җыю ерак гасырлардан ук килә. Әмма һаман да әле кешегә салым түләүдән дә авыррак нәрсә юк. Акланмаган җыемнар һәрвакыт киң катлау халыкның хәерчелегенә, хуҗалыкның бөлгенә, аерым очракларда, хәтта һәлакәткә һәм фаҗигаларга китерә. Түләү зур булганда шәхес иреге һәм аның абруе, иҗади хезмәте һәм тәэмин ителгән киләчәге турында сүз дә булуы мөмкин түгел. Көч җитмәслек салымнар күп кенә социаль низагларга, кан коюлы сугышларга, тулы бер яшәешнең җимерелүенә китерергә мөмкин. Моны берничек тә аклап булмый. Алар бары тик дәүләтнең үз хуҗалыгын зыянлы алып баруга, уйланмаган һәм акланмаган чыгымнар тотуга китерә, тулаем гражданнарның мәнфәгатьләренә төкереп каравы турында сөйли. Турыдан-туры салымга карамаганнары (акцизлар, өстәлгән салымнар) - социаль яктан иң гаделсезе. Андые барлык халыкка бер үк дәрәҗәдә өстәмә

йөк булып төшә, аз керемле кешеләргә аеруча көчле тәэсир итә. Товар сайлап алганда шәхси кеременең иң зур өлеше салым түләүгә китә. Югары керемле кешеләр алынган акчаның бер өлешен өстәмә салым булмаган урынга туплый, - шулай итеп, салым басымын (йөген) киметүгә ирешә.

Россиянең салым системасы нигезләре 1991 елда рәсми рәвештә расланды. Әмма икътисадый кризис нәтиҗәле (файдалы) салым системасы булдыруга нык комачаулый.

Хәзерге вакытта Россия салым системасында башлыча алдашу хөкем сөрә. Бу исә салым ярдәмендә стимуллаштыруны һәм тәртипкә салуны күздә тоткан гамәлләрне тормышка ашыруда тоткарлыклар тудыра. Ялган (фискаль) функциянең асылы дәүләт чыгымнарын каплау өчен төрле дәрәҗәдәге бюджетларга кирәкле акча керемен тәэмин итүдән гыйбарәт. Көйләү һәм стимуллаштыру максатларына аерым тармакларга инвестицияләр агымын идарә итү, капитал туплауны көчәйтү яки йомшарту, халык ихтыяҗлары өчен түләү сәләтен киңәйтү яки киметү юлы белән ирешелә. Салым системасын камилләштерү хөкүмәтнең сәясәтенә бәйле. Аны камилләштерү буенча Россия хөкүмәтендә һәм финанс органнарында төрле карашлар хөкем сөрә. Кайберәүләр салымга ныклы контроль булдырырга тәкъдим итә. Шуның ярдәмендә салымны тигез бүлергә, киләчәктә аның билгеләнешен (ставкаларын) киметергә мөмкин булыр дип исәпләнә. Икенче берәүләре гамәлдәге салым билгеләмәләрен һәм аны түләү тәртипләре сакланганда икътисадый кризистан чыгу мөмкин түгел, дигән фикерне алга сөрә. Алар фикеренчә, беренче чиратта, товар җитештерүчеләргә салымны бик нык киметергә яки билгеләнгәннәрне түбәнәйтергә, нәтиҗәле итеп бүлергә кирәк. Әлегә салым системасы икътисадый сәясәткә капма-каршы тора.

Әйләнеш салымын өстәлгән салым белән алыштыру нәтиҗәсендә төп авырлык әйләнеш тармагыннан җитештерү тармагына күчте. Бу исә, үз чиратында, әйләнештәге капиталның шактый өлешен читкә чыгаруга, урлашуга китерде. Капиталны җитештерү тармагыннан кысып чыгару инвестиция агымын тоткарлый, аның үсүенә мөмкинлек бирми, шуңа күрә барыннан да элек товар җитештерүчене һәм инвестицияләүне стимуллаштырырга кирәк. Моның өчен предприятиеләрнең төп һәм әйләнеш капиталын салымнардан азат итү сорала. Моны тузган җиһазларга җибәрелә торган акчаларга ташламалы билгеләмәләр формасында яки өстәлгән салымны киметеп (яки аны бөтенләй бетереп) эшләргә мөмкин. Предприятиедә икътисадый хәл салымны киметүдән алынган акчаны кая, ничек тотарга икәнлеген бик ачык күрсәтә. Әгәр предприятиедә җитештерү азая икән, ул чагында салымнарны киметү эшчеләргә хезмәт хакын күтәрергә яки товарларның бәясен арзанайтырга мөмкинлек бирә. Соңгысы исә базарда товарга булган сорауны стимуллаштырачак. Предприятиенең хәле яхшы икән, ул чагында салымнан калган табышны җитештерү тармагын үзгәртеп коруга һәм үстерүгә тотарга мөмкин булачак. Дөрес, салым сәясәте җитештерүне, эшкуарлыкны, инвестицияне үстерүгә китерә.

Көнбатыш икътисадчылары, салым җыю механизмын анализлап, процент ставкаларын билгеләгәндә аның оптималь дәрәҗәсе зур әһәмияткә ия булуын билгеләп үттеләр. Салым күләмен билгеле бер дәрәҗәдә генә күтәрергә мөмкин. Аны чамадан тыш күтәргәндә бюджетка керем кими. Шулай итеп, гамәлдәге салым системасын анализлау, аның камиллектән шактый ерак торуын күрсәтә. Беренчедән, ул эшкуарлар өчен уңай шартлар тудырмый, халык хуҗалыгын үзгәртеп коруны, җитештерүне арттыруны тоткарлый, икътисадның төп тармакларын инвестицияләүгә ярдәм итми. Икенчедән, ул социаль яклауга мохтаҗ булганнар өчен бюджетка тиешле акча керемен тәэмин итми. Бүген салым системасы үзенең төп вазыйфаларын үтәми. Карашыбызча, бездә әле акциз салымнарын көйләүдәге алга киткән илләр тәҗрибәсе искә алынмый. Гамәлдәге салым системасының төп кимчелеге шунда, халыктан алына торган җыемның нинди максатка тотылуы билгеле түгел.

Хәзер инструкцияләргә еш кына үзгәрешләр кертү кебек яраксыз тәҗрибә барлыкка килде. Бу хәл салым инспекторлары, предприятие бухгалтерлары эшен нык катлауландыра һәм, тулаем алганда, нәтиҗәлелекне киметә.

Салым системасы җитештерүне арттыру һәм продукция сату күләме берәмлегенә карата салымны киметергә мөмкинлек бирердәй итеп эшләнергә тиеш. Дәүләт бюджетына керем салымнар һәм салым билгеләмәләре исәбенә түгел, бәлки хуҗалык субъектлары табышы һәм гражданнарның кереме күтәрелү исәбенә артсын иде. Салым түләгәннән соң физик һәм юридик затларның акчасы киләчәктә тормышны яхшырту һәм эшне алып бару өчен дә калырлык булсын. Салым җыйганда түләүченең мөлкәте, аның кереме искә алынырга тиеш. Табыш чыганагы нинди булуга карамастан, салым күләмен билгеләүгә тигез караш саклансын. Бер объектка салым бер тапкыр гына һәм аның бер төре генә салынсын, ә җыем алу күләме икътисадый нигезләнгән булсын. Моңа ирешү өчен гайре табигый чаралар таләп ителми, бары тик күп гасырлар дәвамында галимнәр тарафыннан эшләнгән һәм салым сәясәтен билгеләүдә күпчелек илләр файдалана торган принципларны төгәл үтәргә генә кирәк.

420066

Өзелсәгез туган җирләрдән...

Көннәрнең язга авышуын хәбәр итеп, бакчаларда купшы песнәкләрнең таныш сызгырулары ишетелә башлады. “Фюйт-фюйт” дигән шушы гади генә авазлар да кышкы өнсезлектән соң күңелләрне нечкәртеп, җаннарны җылытып җибәрә, бу дөньяда яшәүнең һәр якты иртәнең кадерен белергә өнди. Аллага шөкер, шушы песнәк сызгырулары кебек кенә, яшендәй ялтырап кына үтеп китә торган бу кыска гомерләрдә тагын бер язны исән-имин каршыларга язган икән, дип сөенеп уйлый Кеше. Шуны искә төшергәне, сөенеч алуы өчен бәләкәй кошчыкка рәхмәтләр яусын! Туган җирләрен сагынып тиздән кучмә кошлар да кайтырлар. Авыр кышларны, ерак араларны исән-имин генә кичә күрсеннәр.

Кыр казлары да исән-сау кайтырлар микән? Узган көздә аларга әллә ни булган кебек иде бит. Август эссесендә үк һавага күтәрелделәр дә, үзәк өзгеч тавышлары белән күкләрне айкап, авыл өстен әллә ничә урадылар, ул авыр минутларда баш өстеннән тургайлар да югалып торды. Җылы якларга китәргә җыенулары дисәң, кыр казларының болай иртә кузгалганнары юк иде бугай. Әллә артык эсселектән күлләре кибеп, табигать аларны көз азагына кадәр яңа җәйләү эзләргә мәҗбүр иттеме яки бер миһербансызы ояларын тузгыттымы?

Кыйгак-кыйгак каз кычкыра -
Каз шулай елый икән.
Кыр казының кайгылары
Кырларга сыймый икән.

Күп еллар элек чыккан бу җыр, радиодан бер-ике ишетелде дә, күңелләрдә үз урынын таба алмыйча, нигәдер онытылды. Инде кыр казлары үзләре дә килми, исемнәре җырларда гына калыр микәнни?

Якын-тирәдәге кыр-болыннарның һәр куагын һәм түмгәген, урманнарның һәр сукмагын яхшы белгән Карадуган игенчесе Сәүбән Шакирҗанов август азагы җиткән саен үз йортының капка төбендә утыра һәм, вакытсыз кыр казлары тавышын ишетеп, һавага карый. Кошлар артыннан талпынмый да, сагышын да сиздерми ул: талпыныр чаклары узган, сагышлары эчкә йотылган.

Туган җирләрен калдырып, оҗмах йә бер мәҗара эзләп читкә китүчеләргә дә кызыкмый ул. Элек, яшьрәк чакта да кызыкмады, тормыш авырлыганнан сыгылыр көннәре күп булса да, качарга омтылмады, ә сәбәбен үзе дә әйтеп бирә алмас иде. Иң уңган игенче дип, аны бервакыт Көньякның шәп шифаханәсенә юллама белән бүләкләгәннәр иде. Шунда да, түзә алмыйча, бер атнадан әйләнеп кайтты. И-и, туган җирдән шифалырак ни бар соң? Әнә байтак еллар элек ике энесе бәхет эзләп китеп карады бит инде.

- Юк инде алар, беттеләр... Беткәннәрдер, - ди Сәүбән карт Илдус белән Ильяс хакында сорашкан авылдашларына. Әмма “бетүләренә” үзе дә ышанып җитми. Каберләрен барып күрмәгән ич. Каберләре билгеле микән соң, ичмаса...

Сәүбән - “Игенче” күмәк хуҗалыгында Шакирҗановлар нәселенең иң өлкәне хәзер. Әтисе Шәриф абыйны берничә ел элек җирләделәр, әнисе Шәмсия апаны балалар хәсрәте күптән гүр иясе иткән иде. Шәриф абый, олайса да, бик матур гына йөри иде дә, бертуган абыйсының Гыйлемхан атлы улы гөрләтеп яшәр чагында дөнья куйгач, хәсрәтеннән урын өстенә егылды һәм бүтән тора алмады. Авылда Сәүбәннең бер энесе белән өч улы куәтле тракторларда аның игенче һөнәрен дәвам иттерәләр, кызы балалар укыта. Әтиләре Шәриф мәрхүм совет чорында игенчелек белән күп шөгыльләнмәде, сугыштан соң озак еллар ферма мөдире булып эшләде. Ә Сәүбән малай чагыннан ук хәлсез ат янәшәсендә тырмага һәм сукага җигелде. Ул шушы җиргә бәйләнгән, ирекле күчмә кошлар артыннан еракларга омтыла да алмый. Бер дуамал уй белән каядыр китеп барса да, йә авыр язмышы, йә туган колхозы һәм андагы мәҗбүри эше, йә таянычсыз калган гаиләсе аны барыбер кире кайтарачак иде. Шулай булуы хәерлерәк тә килеп чыкты тагын. Теге чакта Илдус белән Ильясны да җибәрмәгән булса икән дә бит...

Байтак еллар элек ул энеләре торган Себер якларында йөреп кайткан иде. Ләкин бу очрашу өлкән туганга куаныч китермәде, киресенчә, энеләренең ничек яшәп ятуын күргәч, аның борчылуы гына артты. Халык әдәбенә нигезләнмәгән тәртипсез-ипсез тормыш, исереклек, ят кануннарга һәм үзгә мөнәсәбәтләргә корылган милләтсез гаилә - болар барысы да бәхет эзләп килгән саф күңелле, хәйлә-мәкер белмәгән авыл егетләрен рухи имгәтү, кеше исәбеннән чыгару өчен кем тарафыннандыр махсус эшләнә кебек иде. Сәүбән әле дә әйтә: “Әнә Ильясның сабакташы Фәргать ул чакта Кузбассны ташлап кайтып дөрес эшләде. Зәкәрия дә, аннан вакытында ычкынып, исән-сау калды. Ә читтәгеләр, Илдус белән Ильясның күп чордашлары, якты дөньяда юк инде”.

ӘЙТЕР СҮЗЕМ БАР...

...Очар кошларыбызның туган җирләргә кайтыр вакытлары җитә. Исән-саулармы алар, көтүләре ишле кайтырмы? Әнә Сабан туйларына кайткан яшьтәшләребезне елдан-ел азрак очратабыз. Беләсе иде, якташ кошларыбызны чит җирләргә нәрсә тарта икән? Ризыкмы, җылылыкмы, әллә... Юк-юк, болай уйлыйсы килми, югалтуларыбыз болай да бик күп ич, моңа кадәр санап-барлап кына карамаганбыз.

Дөньяда дусларыбызны, туганнарыбызны гына түгел, китәр кошларны да туган җирләрдән җибәрмәскә әмәл эзләтерлек гыйбрәтләр бар.

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ.
Балтач.

Уңай үзгәрешләр булырмы?

Белгәнегезчә, без базар икътисадының катлаулы чорын кичерәбез. Хезмәт җитештерүчәнлеге кими, товарларга һәм көнкүреш хезмәтенә бәяләр котырып үсә, бурычлар муеннан, акчаның кыйммәте юк. Гади халыкка бер дә җиңел түгел.

Бездән ерак түгел генә Удмуртиянең Троеглазово исемле кечкенә авылы урнашкан. Мин еш кына бу авыл тирәсендәге урман полосасына нарат күркәсе җыярга йөрим. Биредә тынлык хөкем сөрә, утарлар һәм хуҗалык тирәсендә 2 метр биеклегендә чүп үләннәре котырынып үскән, корылмалар ватык, ташландык хәлдә. Калдык-постык сыерлары басуда(!) күшәп йөри. Көтүчесе белән сөйләшәбез. "Бу авылда өч-дүрт ел терлек үрчеми, - ди. - Юньле эшче дә юк, көмешкә куып сата торганнары гына калды..." Гамьсезлек, җавапсызлык бу авылда гынамыни? Бу хакта еш уйланам мин. Уйларымны яраткан "Татарстан" журналы белән дә бүлешәсем килә.

Күп хуҗалыкларда хезмәт хакларын үз вакытында түли алмыйлар һәм эшчеләр урлашу юлына басарга мәҗбүр, чөнки аларга нәрсә хисабына да булса җан асрарга кирәк. Моннан авыл хуҗалыгы зур суммада зыян күрә. Шуңа күрә иң беренче чиратта бурычлардан котылырга - хезмәт хакларын түләп бетерергә кирәк.

Киләчәктә һәрбер район үзәгендә дә типовой проект белән балалар һәм яшьләр иҗат сарайлары төзисе иде. Үсмерләр, урам тәрбиясенә бирелеп, эчкечелек, хулиганлык, җинаятьчелек, наркомания юлына киткәнче, иҗат эше белән мавыгулары күпкә яхшы ич. Кайбер иптәшләр исә гаҗәпләнеп: "Хәзерге кризис чорында шулкадәр зур төзелешләрне ничек финансларга соң?" - диярләр. Һәркайда да теләктәшлек өмәләрен, ярминкәләрен, хезмәт декадаларын еш оештырырга һәм эшләп алынган акчаны шул төзелешләр фондына күчереп барырга кирәк. Бу өлкәдә яшьләрнең үзләреннән активлык күрсәтүләре сорала.

Озак сроклы төрмә хөкеменнән һәм хезмәт белән төзәтү колониясеннән азат ителгән иптәшләрне бер генә оешма да эшкә алырга теләми. Нәтиҗәдә алар яңадан җинаятьчелек юлына басалар. Бәлки, аларга зур торак пунктларда махсус предприятиеләр ачарга кирәктер? Җәмгыятькә дә, үзләренә дә файдалы эш булыр иде.

Киләчәктә һәрбер эшкә яраклы кеше ким дигәндә өч-дүрт һөнәр иясе булырга тиеш. Кыскартылуга эләккән очракта тиз арада җәмгыятькә файдалы эшчәнлеген туктатмыйча, икенче эшкә күчә алырлык булсын. Күп кенә фермаларда терлекче авырса, аның өчен алмаш табу да проблемага әйләнде. Ферманы ябып булмый ич, эшче көчләр белән үзләрен комплектлаштырырга кирәк. Хәзерге вакытта штат кыскарту модага керде. Яшьләргә бик кыен бит, җәмәгать. Җитәкчеләр аларны артык кашыкка санаса да, берәү дә белеп тумый. Нәтиҗәдә хулиганлык үсә. Эчкечелек чәчәк ата. Җинаятьләрнең күбесе исерек баштан эшләнүен дә онытмаска кирәк. Эчкечелек белән көрәш башланганчы җәмгыятьне хроник исереклектән дәвалау курсы үткәрү мөһим. Аннан соң спиртлы эчемлекне куллануны әкренләп киметә башлыйсың. Вакыт узган саен кибет киштәләреннән әлеге "агу"ны бөтенләй алып атасың. Эчкечелек чиреннән арына алмаучыларга шифаханәләрдә ачылган наркология бүлеге ярдәмгә килер.

Миннән, безнең илдә үзгәртеп коруларның инициаторы кем, дип сорасалар, мин һич икеләнмичә: "Н. С. Хрущев", -дип җавап бирер идем. 1953-64 еллардагы үзгәртеп корулар халыкка зыяннан башка берни бирмәде. Халыктан сорап та тормыйча авыл Советларын, күмәк хуҗалыкларны, районнарны, хәтта өлкәләрне берләштерделәр. Бөек Ватан сугышыннан соң Татарстанда 64 район булса, 1964 елга 17 гә калдырылды. Әмма аның ахыргы нәтиҗәләре буенча гына җавап бирүче булмады. Горбачевның үзгәртеп корулары да авантюристик эксперимент ролен уйнады.

Без авыр, катлаулы чорда яшибез. Бәяләр котырынып үсүгә кайчан чик куелыр? Кайчан эшсезлек бетәр?

Динар ЛАТЫЙПОВ.
Әгерҗе.





Милләттәшләребез сынатмыйлар

Татарстан Республикасының ӘЗӘРБАЙҖАНДАГЫ даими вәкиллеге каршында өч елдан артык инде хатын-кызлар клубы эшләп килә. Клуб өч йөздән артык хатын-кызны берләштерә. Алар бергәләшеп дискотекалар үткәрәләр, музейларга һәм театрларга экскурсияләр оештыралар. Клуб каршында инглиз һәм татар телен өйрәнү, дизайн, кием тегү һәм кисү, аэробика, зәвыклы итеп бизәнергә өйрәнү кебек һөнәрләр буенча түгәрәкләр эшли. Тормышта вак-төяк аңлашылмаучылыклар да булмый тормый, мондый вакытларда югары квалификацияле хокук белгече Филүсә Сабитова ярдәмгә килергә әзер тора.

Клубны техник фәннәр докторы, профессор, бик күп гыйльми хезмәтләр авторы Эльмира Ильязова җитәкли. Эльмира ханым шулай ук Ш. Мәрҗани исемендәге Хәйрия фонды президенты да. Күп вакыт таләп иткән оештыру эшләрендә аңа тормыш иптәше Татарстанның Әзәрбайҗандагы даими вәкиле Рафаэль Ильязов ярдәмгә килә.

Соңгы вакытларда Эльмира ханым тырышлыгы белән милли азыгыбыз пәрәмәч бәйрәме үткәрелде. Аш-су осталары арасындагы бәйгеләр вәкиллектә бик еш оештырыла.

Яңа дини оешма теркәлде

УЛЬЯНОВСК өлкә хакимиятенең хокук идарәсендә тагын бер дини оешма - мөселманнарның үзәк дини идарәсе рәсми рәвештә теркәлде. Җитәкчесе - Фатыйх хәзрәт Алиуллов. Ул Чынлы районы Яңа Тимерчән авылы мулласы гаиләсендә туып-үскән, Бохарадагы “Мир-араб” мәдрәсәсен тәмамлаган. Соңрак Казан гыйбадәтханәләрендә дини гыйлемен күтәргән.

Яңа дини оешма өлкәдәге өченче мөфтият булып кабул ителә. Фатыйх хәзрәт аның төп максаты итеп өлкәдәге барлык мәхәлләләрне дә берләштерүне саный. Өметләнергә нигез дә бар. Фатыйх хәзрәт Ульяновск шәһәрендә иң абруйлы имам булып санала. Пакь күңелле, беркем турында да аның авызыннан начар сүз ишетү мөмкин түгел. Аннары күпчелек дин әһелләрен бимазалаган акча мәсьәләсе Фатыйх хәзрәтне кызыксындырмый. Дин-исламыбызга хезмәт итүне ул яшь буынга иман иңдерү сыйфатында аңлый һәм шуның белән мәшгуль дә: көндез - мәктәп балаларын, кичләрен яшүсмерләрне укыта. Югары абруе да - шуннан.

Җыен

Халкыбызның гореф-гадәтләрен, традицияләрен кире кайтару - изге эш. Бу юнәлештә УДМУРТИЯ Республикасының Камбарка татар иҗтимагый үзәге рәисе Мирдәлиф Якупов күпләребезгә үрнәк булырлык эш алып бара. “Сабантуй” дисеңме, “Нәүрүз”, “Төпчекләр” көне, “Карга боткасы”, “Гаилә көне” - барысын да матур итеп оештыра. Дүрт ел рәттән узган “Җыен” да матур гына традициягә әверелеп бара. Бу бәйрәмгә Камбарка районы хакимият башлыгы, хакимиятнең башка әгъзалары, районның “Удмурт кенеш” җәмгыяте рәисе һәм Удмуртия мөфтие Габдулла хәзрәт һәм башка шәһәр, районнардан килгән кунаклар катнаштылар. Җыенда җирле татар халкының проблемалары турында да сөйләшү булды. Соңыннан “Җидегән чишмә” ансамбле халык күңеленә хуш килердәй концерт куйды (җитәкчесе Тәлгать Сәләхов). Бәйрәм милләтебезнең гимны - “Туган тел”не җырлау белән тәмамланды.

“Ләйсән”нең бирешергә исәбе юк

ТӨМӘН өлкәсенең Нефтеюганск шәһәре “Ләйсән” халык җыр ансамбле, җитәкчесе Зәрә Гыйниятуллинаның пенсиягә китүе сәбәпле, җитәкчесез калган иде. Ансамбль җырчыларының, әлбәттә, моның белән килешеп бетәселәре килмәде. Алар бар да җыелып Нефтеюганск хакимиятенең мәдәният бүлегенә барып, 20 ел буе тоташ җырлаган халык җыр ансамблен юкка чыгарасы килмәгәнлекләрен катгый рәвештә белдерделәр, яңа музыкаль җитәкче сорадылар. Мәдәният бүлеге бу сорауга каршы килмичә, бер сүзсез риза булды. Һәм, ниһаять, “Ләйсән” тагын үзенең моңлы, дәртле, шаян җырлары белән халыкны шатландырачак.

Ансамбльнең вакытлыча җитәкчесе итеп “Ләйсән” җырчылары үзләренең яраткан композиторы Венер Мөхәммәдиевне сорап алдылар. Ә “Тальян” методисты Наилә Смоленцева аңа ярдәм итәргә сүз бирде.

Хакимияткә галим килде

ТҮБӘН НОВГОРОД өлкәсе Сергач районы идарәсенә тарихта беренче мәртәбә татар кешесе килде - район хакимияте башлыгы Н. Мигунов үзенең урынбасары итеп Мостафин Шамил Хөсәеновичны билгеләде.

Шамил әфәнде өлкәдә танылган кеше. Ул үз вакытында Кызыл Октябрь районында комсомол райкомының беренче секретаре, колхоз рәисе, озак еллар район авыл хуҗалыгы идарәсе рәисе булып эшләгән, Россиянең атказанган авыл хуҗалыгы эшлеклесе, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты. Соңгы вакытта Сергач районара консультация пункты рәисе иде.

Шамил Мостафинның район идарәсенә килүе белән районда уңай үзгәрешләр башланыр дип өметләнәсе килә.

Оренбургта татар концертлары

ОРЕНБУРГТА “Алтын Урда татар һәм башкорт җырлары фестивале” узды. Бу фестивальдә җырчы һәм композитор, Россиянең атказанган артисты Таһир Абдршин да катнашты.

Чаллы шәһәр хакимиятенең “Чаллы” иҗат берләшмәсе “Чулман буйларында” исемле зур концерт программасы белән өлкәнең шәһәр-авылларында йөрде.

(“Татар-информ” агентлыгы материаллары буенча тупланды).

ГАСЫР - ВАКЫЙГАЛАРДА

Индус ТАҺИРОВ,
Татарстан Фәннәр академиясе
академигы.

Революция һәм татарлар



Революцияләр һәрвакыт яшәешнең бер этәргече булсалар да, шул ук вакытта халыкларга бик күп зыян да китерә киләләр. Алар, бер яктан, алга барырга комачаулык итүче искелек калдыкларын юкка чыгарсалар, икенче яктан, җәмгыятьне зур җимерүләргә дә дучар итәләр.

Ләкин шунысын да онытырга ярамый: революцияләр беркайчан да сәбәпсез булмыйлар. Аларның төп сәбәбе күпчелек халыкның искечә яши алмавына кайтып кала.

Россиядәге 1917 ел революцияләре дә шундый ук сәбәпкә бәйле. Халыкның күпчелек катлаулары илнең искечә яшәеше белән риза түгел иде. Гомум ризасызлыкны искиткеч уңышсыз алып барылган сугыш, ягъни Россиянең бөтендөнья сугышында Антанта ягында Германия һәм Австро-Венгриягә каршы алып барган сугышы аеруча көчәйтте. Бу сугыш көн саен миллионлаган сумнарны йотып, меңләгән кешене теге дөньяга алып китә торды. Халыкның икътисадый хәле көннән-көн начарая барды. Икътисадый җимереклек, эшсезлек, ачлык яшәешнең көндәлек күренешенә әверелде. Хәер, болары хакында артык сүз куертуның кирәге юктыр, чөнки бу хакта күп язылды. Ә менә ни өчен татарлар шушы революцияләрдә күпләп катнашкан, аларга ни җитмәгән? Егерменче гасыр башында яңарыш кичереп, яңача яшәү рәвешенә күчеп килүче милләт буларак татарлар искелек бусагасын атлап чыгу дәрәҗәсенә җиткәннәр. Милләтебезнең мәгарифе, мәдәнияте иске жандарм кысаларына җайланган системага сыймый, аларның яшәешенә яңа сулыш кирәк иде.

Сыйнфый яктан өлгергән милләт буларак, татарларның төрле катламнары Россиядәге сәяси партияләрнең йогынтысына ныклап билгән була. Шәһәр татарлары социал-демократларны да, социалист-революционерларны да, кадетларны да бик яхшы белгәннәр, шушы партияләрнең эшләрендә дә актив катнашканнар. Ул заманда кадет Садри Максудины, социал-демократ Хөсәен Ямашевны, эсерлар Галимҗан Ибраһимов, Гаяз Исхакыйларны белмәгән кеше бик аз булгандыр. Ә бу инде - татарларның сәяси яктан яңа, буржуаз ирекләргә өлгергәнлегенең бер күренеше. Әйе, татарлар нәкъ менә иреккә сусаган. Чыннан да, алар дистәләгән газета-журнал, ел саен йөзләгән китап чыгарырдай милләт булуларына да карамастан, бу эшчәнлек жандарм контроле астында булсын әле, дистәләгән милләтпәрвәргә исламчы мөһере сугылып, сөрген-каторгаларда иза чиксен әле! Моңа кайсы татар түзсен икән!

Татар халкының күпчелеге крестьяннардан торган, ә аларга үз илләрендә җир җитмәгән. Җирләре русларныкы белән чагыштырганда 1,5-2 мәртәбәгә азрак булган. Тик 3 процент татар крестьяны гына 12 дисәтинәдән артыграк җир биләгән. Шуңа күрә дә татар крестьяннары руслар белән бергә аграр хәрәкәттә катнаша килгәннәр. Әлбәттә, алар илләрен ташлап башка җирләргә дә китәргә, завод-фабрикаларга эшче сыйфатында урнашырга мәҗбүр булганнар. Татар эшчеләренең күбесе, руслар белән бер үк завод-фабрикаларда эшләгәнлектән һәм яшәү шартлары бердәй авыр булганлыктан, алар да көрәшкә кушылган.

Мондый шартларда татарның төрле катламнарында милли аң сыйнфый карашларга үрелеп барган һәм, әлбәттә, аңа комачаулыклар да тудырган. Әйтик, татар кадетларына татар идеясе бердәм һәм бүленмәс Россия идеясе белән бергә сеңгән. Эшче халкына пролетарийларның дөньякүләм бердәмлеге күп вакыт милли бердәмлектән өстенрәк күренгән. Әлбәттә, бу - татар эшчеләренең, татар кадетларының милли аңы түбән булганын аңлатмый. Сүз бу очракта шул аңның нинди юнәлештә үсүе хакында бара. Татарларның иң укымышлылары нигездә кадетлар яки социал-демократлар белән ныклы бәйләнештә булганлыктан, милли дәүләтчелек идеясенең кысалары тарая. Бу исә үз нәүбәтендә милли дәүләтне торгызу идеясенең бик авыр тернәкләнүенә сәбәп була. Кадет яки социал-демократ булган бик сирәк татар зыялысы гына миллилекне үзара бердәмлек рәвешендә күрә алган. Бик күп татар укымышлылары Россиядәге сәяси партияләр белән бергә эш алып баруны милли мәнфәгатьне алга сөрү дип караганнар.

Патша бәреп төшерелгәннән соң татарлар арасында таркалу көчәя: "Без хәзер көннән-көн аерылабыз, крестьяннар рус крестьяннары белән бергә бара. Эшчеләребез рус эшчеләреннән, әлбәттә, аерылмый, кайсыбыз социал-демократ булдык, кайсыбыз социалист-революционерларга язылды, беребез милләтче, икенчебез милләтне инкяр итә... Халык аерылды. Электән дә юк дәрәҗәсендәге аз көчләребез хәзер бөтенләй таркалды"[1], - дип ачынып язган Фуат Туктаров. Ә бит бу кеше - Гаяз Исхакыйның якташы һәм якын дусты - социализм чире белән чирләп, инде савыккан була. Ул да, дусты шикелле үк, миллилекне, милли бердәмлекне коллыктан котылуның бердәнбер юлы итеп күрә.

Мулланур Вахитов исә үзе чыгара торган "Кызыл Байрак" газета-

ГАСЫР - ВАКЫЙГАЛАРДА

сында “зур бәлаләрдән котылган мөселман галәменең” социалистик әләм астына кергәнлеге хәбәр итә. “Без үзебезнең кызыл байрагыбызны күтәрәмез дә, чиксез зур шатлык белән бөтен галәм пролетариатының изге теләкле гаскәре сафына кушыламыз”[2]. Капитализмга каршы көрәш, сыйнфыйлык Мөселман социалистлар комитеты тарафыннан беренче урынга куела. Шушы газета дөньякүләм сыйнфый көрәшне “капитализм өстенә күтәрелгән кара болытлар” һәм инде алар “тиздән күкне күкрәтәчәк яшеннәр яшеннәтәчәкләр”, дип яза. Ләкин башкача фикер йөртүчеләр дә булмый түгел. Инде исеме телгә алынган Фуат Туктаров 1917 елның 2 июлендә “Корылтай” газетасының баш мәкаләсендә татарлар алдында торган бурычларны ачыкларга тырыша. Аның фикеренчә, шушы бурычларның нигез ташы - нинди дә булса партиячелек принцибыннан баш тарту. Ул бигрәк тә большевикларны кискен тәнкыйтьли, аларны “әнә очыдай” бер партия дип атый. “Безнең дә үзебезгә күрә большевик дигән партиябез бар. Алар да бүген үк Русия татарлары арасында социализм кертмәкче булалар. Бездә дә үзенә күрә анархия, башбаштаклык башланып бара”. Шул ук вакытта автор татар байлары һәм алпавытларының милли эшләрдән читләшүен дә күрсәтеп үтә. Ул, революциянең теләсә нинди очракта да русларга файдалы булачагына басым ясап, татарның бер нәрсәсез калу ихтималын ассызыклый. “Без хаким милләт түгел, бездә байлык та, гыйлем дә, мәгариф тә, мәдәният та юк. Без зәгыйфь, сырхау, әлегә кадәр кол булып, изелеп яшәгән бер халык бит”, - дип яза ул. Газетасының бер санында Фуат Туктаров Россиядәге сәяси хәрәкәтне өч агымга, яки кадет, гомум социалистик юнәлеш һәм большевизмга бүлеп күрсәтә һәм аларга булган мөнәсәбәтен түбәндәгечә билгели: “Русиянең шул хәленә, шул өч агымына, тартышына без төрки-татарларның мөнәсәбәте ничек соң? Без, әлбәттә, кадетлар белән бергә бара алмыйбыз. Ая Суфиягә дип ясаган түр тәреләрен без күтәрешеп бара алмыйбыз инде, аңа безнең көчебез җитми, кулыбыз күтәрелми. Без, әлбәттә, большевиклар да була алмыйбыз. Бездә бу көннән үк социализм кертерлек кадәр гыйлем юк әле. Без әле социализм түгел, республика сүзен дә быел гына ишеттек, капитал дигән сүзне дә хәзер генә өйрәнергә тотынмакчы булабыз әле. Без әле социальный революцияне генә түгел, хәзер ясалып килә торган сәяси революцияне дә көчкә-көчкә генә аңлыйбыз. Аңа да хәзерләнеп куя алмаганбыз. Без большевиклар белән бергә бара алмыйбыз. Бара алмыйбыз гына түгел, хәтта арабызда большевик булган, йә большевик фикерен тарата торган халык безнең милләтебезгә, төркилегебезгә... зарар итәчәкләр”. Шул ук вакытта автор рус халкына дустанә мөнәсәбәтен вә шул ук вакытта үпкәсен дә белдерә: “Мөселманнар рус халкы белән әлегә кадәр бергә булдылар, мәмләкәтне бергә сакладылар, тик хөкүмәт үзе генә безне какмасын, безнең дә дөньяда барлыгыбызны, бар булырга, яшәргә теләгәнебезне онытмасын”[3].



Октябрь көннәре якынлашып канлы бәрелешләр булачагы ачыклангач, Бөтенроссия хәрби шурасы татар солдатларын анда катнашмаска өнди. “Менә шундый кара көннәргә ирешмәс өчен без Советлар белән армиянең тавышына колак салырга һәм большевиклар тарафыннан булачак выступлениегә бар көчебез белән каршы торырга тиешбез”[4], - дип язды “Безнең тавыш” газетасы. Ләкин татар солдатлары бу өндәүгә колак салмаганнар. Алар “төннәрен ач килеш, большевиклар белән сугыштылар, байтак кына авырлыкларга очрадылар”[5]. Дөрес, чуалышларда барлык халык катнашты, дип санау зур хата булыр иде. Нигездә Казан вакыйгалары юнкерлар белән солдатлар арасындагы бәрелеш кенә итеп күзалланырга тиеш. Аларга, хәтта элегрәк вакыттагы шикелле, тулы сәяси төс бирү дә бик урынлы булмас. 24 октябрь кичен Казан Советының солдатлар секциясе аның рәисе Н. Ершов тәкъдиме белән гарнизондагы 1989 елны хәрби хезмәткә чакырылган солдатларны өйләренә кайтарып җибәрү хакында карар кабул итә. Хәрби округ командованиесе моңа җавап итеп Ершовны һәм Казан большевиклар оешмасының җитәкчесе К. Грасисны кулга алу өчен юнкерлар җибәрә. Тик солдатлар Ершовны юнкерларга бирмиләр, коралланалар. Гарнизонда атышлар башлана. Тик шуннан соң гына вакыйгаларга акрынлап сәяси төс керә башлый. Шушы урында бер уйдырманы фаш итү урынлы булыр. 1934 елдан башлап тарих китапларына Казандагы кораллы восстание Петроградтан РСДРП(б) Үзәк Комитетыннан алынган күрсәтмә нигезендә башланды, дигән раслама кереп урнаша. Имештер, 23 октябрь кичендә Казан большевиклар оешмасының комитет утырышы булып, Үзәк Комитетның күрсәтмәсе укыла һәм шуның нигезендә кораллы восстаниегә күтәрелү турында карар

кабул ителә. Чынлыкта исә Петроградтан бернинди күрсәтмә дә килми, әйтеп үтелгән утырыш та булмый. Комитет әгъзалары өчен гарнизонда башланган вакыйгалар бөтенләе белән көтелмәгән хәл була. Юкка гына түгел. Вакыйгалардан соң 3 көн үткәч, 30 октябрь көнне РСДРП(б) комитеты утырышында аларга анализ ясала. Анда рәислек кылган А. Карпов, "соңгы көннәрдәге вакыйгалар Петроградтагы власть алмашынуы турындагы хәбәр алынганчы ук башланды һәм аларга комитет түгел, ә аның аерым әгъзалары җитәкчелек итте", дип белдерә. Вакыйгалардан соң нибары дүрт ел үткәч, аның тагын бер әгъзасы Иван Мохов үзенең истәлекләрендә: "Кабынып киткән бәрелеш комитет өчен көтелмәгән хәл булды", - дип яза.

- Әгәр дә инде большевиклар комитеты өчен дә башланып киткән вакыйгалар көтелмәгән хәл булгач, гади халык тарафыннан баштарак ул бер уен кебек кенә кабул ителә. Әле күпләр шул уеннан уймак чыгасын хәтта чамалый да алмыйлар. Газеталардагы материалларга караганда, шәһәр халкының күпчелеге атышларны читтән генә, спектакль карагандай күзәтеп тора. "Сугыш мәйданы" Академический слободада булганга күрә, шул тарафтан атылган туп вә шрапнельләрдән шәһәрнең урта өлеше генә зарарлана. Шәһәрнең мөселманнар тора торган ягына һичбер төрле хәвеф килми. Хәтта шәһәрнең бу өлешендәге "мөселманнар 25 октябрьдә атышның кызу вакытында Кабан күле буена җыелып туп атуларын тамаша кылып тордылар", - дип язды "Кояш" газетасы[6]. Тик шулай да инде башланган атышлар күпләргә курку сала. Моны шушы газетаның 29 октябрь санында гарнизон мулласы яки ахун Гатаулла Баһаветдиневның "24 октябрь төнендә" исемле мәкаләсеннән дә күрергә була. Мәкалә болай башлана: "Кич сәгать 7. Котлары очкан кешеләр төркеме узган-барган кешеләрне туктатып, яңа хәбәрләр сорашып урам чатларында якты фонарь төпләрендә торалар. Күп кешеләр, капкаларын ачып, акрын гына шәһәрдән читкә тынычлык эзләргә таялар. Кем кемгә, нәрсә өчен, кем өчен аталар?" Нәкъ шуларны ачыклау максаты белән автор Бишбалтага 95 нче полк составындагы меңгә якын кешесе булган татар ротасына таба юл тота. Трамвай йөрмәгәнлектән, ул карт татар арбачысын күндереп, дамба аша чыга. Ул 20 ләп юнкерның дамба башында каравыл торганлыгын күрә. Ләкин алар мулланы, рәсми кеше булганлыгын белгәч, тоткарлап тормыйлар, үткәреп җибәрәләр. Бишбалтадагы хәлне Гатаулла хәзрәт болай тасвирлый: "Кап-караңгы. Бишбалта белән шәһәр арасында снаряд шартлаштыргалады. Әйтерсең, шәһәргә Кавказ халкы килгән. Әйтерсең, Бишбалтада немецлар да, шәһәрдә аларның дошманнары". Бу инде - юнкерлар һәм солдатлар арасындагы бәрелешнең башланышын тасвирлау. Әлбәттә, ахун кешене кемнең кем белән сугышуы әллә ни кызыксындырмый. Ул бәрелешне русларның эчке эшләре һәм анда татарлар катнашырга тиеш түгел, дип уйлый. Бишбалтага татар солдатлары шуны аңламыйча әллә кемнәр коткысына иярмәсеннәр, дип куркып бара. Чыннан да, куркуы юкка гына булмый шул. Казармага барып керсә, ни күзе белән күрсен: "Мөселман ротасындагы солдатларның кайсы иптәшләренә булышырга киткән, ә офицерлар канцеляриядә математика мәсьәләсен хәл кылышып утыралар". Математик мәсьәлә шуннан гыйбарәт икән: шәһәр руслары берберсенә каршы атышалар, ә мөселман солдатларына нинди юл тотарга? Һәрберсен шул соаль аптырата. Ахун исә татар солдатларын, бистәгә чыгарып, андагы милләттәшләренең иминлеген тәэмин итү күпкә кулай булыр, дигән теләк белән дә килә казармага. Ләкин солдатлар мулла абзыйларының сүзенә әллә ни колак салмыйлар: имештер, алар татар бистәсенә китсәләр, рус солдатларының аларны юнкерларга сатылган, дип уйлаулары ихтимал. Алай гына да түгел, төнге сәгать 12 дә алар башка хәрби частьларга вәкилләр җибәрәләр һәм андагы татар солдатларының да юнкерларга каршы икәнлеген ачыклагач, рус солдатлары белән гомуми полклар составында революциягә кушылу турында карар кабул итәләр.

Татарларның Казандагы революцион вакыйгаларда катнашуын Бөтенроссия хәрби шурасы әгъзасы, солдат арасында кайнаган прапорщик Садри Вәлидов анализлый: "Без, татарларның да милли теләкләребез бик күп иде. Ләкин тарихлар буенча безнең каныбызга сеңеп килгән куркаклык, тарихи бер җебеклек безне шушы вакытларда украиннар артыннан барудан тыйды. Без һаман да үзебезнең теләкләребезне бар итәр өчен Иван Иванычларга йөгердек, аларның бусагаларын туздырдык. Билгеле, шуның аркасында безнең бер теләкләребез дә мәйданга килә алмады". Әлбәттә, бу сүзләрне язганда инде аңарда зур бер үкенеч туа. Ул да булса - татарның революция көннәрендә милли аңлашу рәвешендә үз юлын таба алмавы. Бу кешенең русларга карата бернинди дошманлыгы юк, ул аларга карата бернинди дәгъва белдерми, тик аларның һәммә сәяси партияләренең үз максатлары бар икәнлеген генә инкяр итә. Хәтта татарларның бик күбесе яклап чыккан "Барлык хакимиятне - Советларга!" дигән лозунгны күтәреп алуы да дөрес түгел, дип саный. Чөнки Советларның күпчелеге тик руслардан гына торган була. "Тик руслардан гына гыйбарәт булган советлар без - татар демократиясе өчен файдасы бик аз эш эшләр. Без, татарлар, хәзер үзебезгә генә ышанырга тиешбез, үз файдабызны тик үзебез генә үтәячәкбез. Шуңа күрә без хәзердән соң үз арабыздагы бөтен ызгышларны ташлап эшкә керешергә, солдатлар белән эшчеләр бергә кушылып, үзебезгә бер мөселман солдат, эшчеләр һәм крестьяннар шурасы төзергә һәм шул килеш мөхтар татар дөньясының бөтен хакимиятен шуңа тапшырырга тиешбез". Әгәр бу шулай эшләнмәсә, без "милләт каршында зур җинаять кылган булырбыз", дип саный автор. Аның бу фикеренә редколлегиядә каршы кешеләр булганлыктан, Садри Вәлидов мәкаләсен тик үз фикере генә дип белдерә. Шушы газетаның 8 ноябрь санында Садри Вәлидов "Нинди юл белән бардык, хәзер нинди юл тотарга тиешбез?" исемле мәкаләсен бастырып чыгара. Ул анда татар солдатларының большевиклар сүзен тыңлап, пычрак вә канлы вакыйгаларда катнашуларына әрнү белдерә.

Ләкин 26 октябрь көнне кич Дворяннар җыелышы бинасында Казан эшче, солдат һәм крестьян советларының уртак киңәйтелгән утырышы булып, анда яңа хакимият буларак революцион штаб төзелгән вакытта Ильяс Алкинның һәм Садри Вәлидинең ни дәрәҗәдә хаклы

икәнлеге ачык күренә. Татарлар революциядә актив катнашкан булсалар да, большевик җитәкчеләр шушы утырышта Казан хәрби округы коменданты итеп билгеләнгән Н. Ершов һәм К. Грасис 16 кешедән торган штабка үз инициативалары белән бер генә татарны да тәкъдим итмиләр. Тик Гатаулла Баһаветдинов ялваруы аркасында гына анда Ильяс Алкин, Мулланур Вахитов һәм Фуат Туктаров кертеләләр. Бу, һичшиксез, татарлар белән санашырга теләмәүнең бер күренеше була. Юкка гына түгел. Штабта Мулланур Вахитов һәм К. Грасис арасында зур конфликт чыга. Бу кеше, үзен әллә кемгә куеп, руспарның да бик күбесе белән бозылышып беткән була. Нәтиҗәдә, 3 ноябрь көнне Ревштаб вәкаләтләре совет кулына тапшырыла.

Бу - Казандагы Октябрь мизгелләре. Тик башка урыннарда да татарлар большевикларны яклыйлар. Хәтта Мәскәү һәм Петербургта да шул ук күренеш: татар солдатлары алар ягында була. Мәскәүдә Милли шура, "бер уч Мәскәү татары" вакыйгаларга үзгәреш кертә алмас, дип, аларны читтә калдырырга тырышса да, бу гамәл барып чыкмый. Петербургта хакимият советлар кулына күчеп, аларга каршы Керенский-Краснов фетнәсе купкач, җирле Милли шура татар солдатларын мәчет эченә кереп, фетнә үткәнне шунда гына үткәрергә өндәсә дә, солдатлар моңа: "Үлсәк үләбез, Керенскийны Питерга кертмибез", - дип җавап бирәләр.

Россиянең башка урыннарында да татарлар зур активлык күрсәтәләр. Сембер губернасының Сызрань шәһәрендә җирле советның рәисе итеп Шамил Усманов сайлана. Петроградтан советлар хакимиятенең җиңүе турындагы хәбәр килүгә үк шушы совет үзен вәкаләтле җирле хакимият дип игълан итә. Усманов Акчуриннарның Гурьев фабрикасында кызыл гвардия отряды төзи. Сызрань шәһәр башлыгын кулга алгач, җирле буржуазия Усмановтан аны азат итүен таләп итә. Усманов исә аларга "юк" дип җавап бирә. Ә Сембернең үзендә совет хакимияте тик 1918 елның апрелендә генә урнаша. Монда да татарларның өлеше шактый була. Татар большевиклары Гафуров һәм Гайнуллин җитәкчелегендә үткәрелгән бер митингта татар кызылгвардиячеләре советлар хакимиятен соңгы тамчы каннарына кадәр якларга ант итәләр һәм, чыннан да, шушы хакимият өчен үзләрен аямыйча көрәшәләр.

Әстерханда совет хакимиятен урнаштыру өчен көрәш кораллы төс ала. Монда 7 нче мөселман ротасы большевикларның төп терәгенә әверелә. Җирле шура җитәкчеләре Нәҗип Гасрый һәм Габдрахман Умеров солдатларны казакларга каршы чыкмаска өндәсәләр дә, алар казаклар һөҗүмен кире кагып, шәһәр Кремлен үз кулларына төшерәләр. Акрынлап алар янына башка революцион көчләр туплана. 1918 елның 16-17 гыйнварында монда татар һәм казахлардан торган кызыл гвардия отрядлары килеп кушыла. 15-23 гыйнвар көннәрендә казаклар зур югалтуларга дучар булалар. 25 гыйнвар көнне алар гомумән шәһәрдән качып китәләр. Соңрак татар ротасындагы солдатлар, Кызыл армия сафларына кушылып, гражданнар сугышы вакытында Әстерханны аклардан саклауга зур өлеш кертәләр.

Бу мәкаләдә татарларның революциядә катнашуларына караган бик күп башка фактларны китереп булыр иде. Аларның күбесе, шул исәптән хәрәкәттәге армиядәге хәлләрне тасмерләгәннәре дә, революциядә татар факторының шактый зур булуын раслый.

Ләкин татарлар тик большевикларны, революцияне генә яклаганнар, алар контрреволюция ягында булмаганнар, дип кенә карау мәсьәләне күпкә гадиләштерү, чынбарлыкны берьяклы гына күрсәтү булыр иде. Инде әйтеп үтелгәнчә, Казанда большевикларга каршы көчләр шактый була. Алар Ильяс һәм Җиһангир Алкиннар җитәкләгән Хәрби шура тирәсендә тупланалар һәм соңрак Идел-Урал Республикасын тормышка ашыру юнәлешендә шактый күп эш башкаралар.

Без шулай ук шактый күп җирдә Милли шура җитәкчеләренең революциягә каршы икәнлекләрен әйтеп үткән идек инде. Уфа, Оренбург, Әстерхан, Мәскәү, Петроград шәһәрләрендәге шуралар совет хакимияте урнашуга бигрәк тә тискәре караште булалар. Кадетлар партиясе вәкиле Садри Максуди, эсер Гаяз Исхакый, социал-демократ Ибраһим Әхтәмов һәм тагын шактый санда татар зыялылары Октябрь революциясен танымыйлар һәм Советларга каршы эш алып баралар. Бу мәкаләнең максаты татарларның революциядә катнашуына багышланган булганлыктан, мин аның ахырында бу эшнең нәрсәләр белән тәмамлануын тасвирлап үтәргә кирәк, дип саныйм.

Мөселман социалистлары комитеты рәисе Мулланур Вахитов совет хөкүмәте составына кертелеп, анда Эчке Россия мөселманнары комиссариатын җитәкли. Аның урынбасарлары итеп Галимҗан Ибраһимов һәм башкорт шурасы рәисе Шәриф Манатов билгеләнә. Мулланур Вахитов, Казанны аклар алгач, алар кулына эләгеп, билгесез шартларда үтерелә. Галимҗан Ибраһимов һәм Шәриф Манатов шәхес культы корбаннары булалар. Мулланур Вахитовтан соң аның урынына калган Мирсәет Солтангалиев совет хөкүмәтенә һәм большевикларга җанын, тәнен кызганмый хезмәт итүенә дә карамастан, шулай ук Сталин тарафыннан харап ителә.

Татарларның большевикларга һәм совет хакимиятенә баглаган өметләре нигездә акланмый. Дөрес, революция нәтиҗәсендә Татарстан автономияле республикасы барлыкка килә һәм соңрак, шуңа таянып, суверен дәүләт өчен көрәш җәелдерү мөмкинлеге туа.

Шулай да үткән тарих - нинди генә булмасын - ул безнең тарих. Без бүген милләтпәрвәрләребезнең кызыллар ягындамы, аклар ягындамы булуларына карап бәяләргә тиеш түгелбез. Чөнки аларның күбесе теләсә кайсы очракта да беренче урынга шәхси мәнфәгатьләрен түгел, ә милләт алдындагы бурычларны куя алганнар.

Революция - ул искиткеч катлаулы процесс. Ул аклы-каралы гына түгел. Анда салават күперенең барлык төсләре дә бар. Безнең аларны күреп һәм аңлап бетерә алганыбыз юк әле. Монысы - безнең киләчәк фәнни бурычларыбызның иң әһәмиятлеләреннән.

ИСКӘРМӘЛӘР

1. Корылтай, 1917, 2 июль.
2. Кызыл Байрак, 1917, 10 июнь.
3. Корылтай, 1917, 14 июль.
4. Безнең тавыш. 1917, 24 октябрь.
5. Безнең тавыш, 1917, 8 ноябрь.
6. Кояш, 1917, 29 октябрь.

Гаяз Исхакый

Флүн МУСИН,
академик.

Тартышуда гына табарсың үз хакыңны!

Г. Исхакый. 1906 ел.

Күз алдында узып баручы гасырга хәзер без инде кешелек аяк баса торган йөзьеллык һәм хәтта меңъеллык биеклегеннән торып карыйбыз. Бу биеклектән үткән тарихи дәвернең казанышлары да, югалтулары да ачыграк күренә. Яңа гасыр каланчасыннан караганда, бигрәк тә аерым шәхесләрнең тарихтагы роле һәм урыны тагын да аныграк булып күзаллана.

Узган йөзьеллыкка хәзер бер караш ташлаудан ук ул дәвердәге татар дөньясында иң олы шәхесләрнең, төп фигураларның берсе Гаяз Исхакый икәне ачыклана. XIX йөзнең соңгы елларында милләткә хезмәт итү юлына басып, ул тиз арада татарның милли идеологы һәм лидеры булып танылa. Бу хәл байтак дәрәҗәдә Исхакыйның милләт рухындагы һәм тәнендәге авыру ноктaларны тиз күреп алуы, аларга дөрес диагноз куюы һәм туган халкын төрле яклап савыктыру юлларын күрсәтүе белән бәйләнгән иде. Шул сәбәпле ул XIX гасыр ахырыннан татар дөньясында башланган милли үзаң үсү һәм яңарыш хәрәкәтенең әйдәп баручыларыннан берсенә әверелә. Исхакыйның мондый рольгә лаек булуы, икенче яктан, аның әлеге яңарышны тәэмин итүче факторларны шулай ук бик яшьли дөрес тотып алуы, шулар ярдәмендә татарны милләт буларак саклап калу һәм яшәтүдә бик актив һәм нәтиҗәле катнашуы белән дә бәйләнгән иде.

Мәгълүм ки, татар дөньясында милли яңарышны башлап җибәргән мәгърифәтчеләр бу процессны алып баруда мәгариф белән әдәбиятка күбрәк өмет багладылар һәм шушы өлкәләрдә актив эш җәелдерделәр. Мәгърифәтчеләрнең дәвамчысы булган Исхакый да үзенең милли мәгънәле эшчәнлеген шул ук мәгариф белән әдәбият өлкәләрендә башлап җибәрә.

Инде мәсьәләгә конкретрак килсәк, Г. Исхакый үзе “азатлык юлында беренче адым” дип исәпләгән мәгариф тармагындагы эшчәнлеген практик эштән, ягъни 1897 елда Яңа бистәдәге Әмирхан мәдрәсәсендә шәһәрдә беренчеләрдән булып җәдитчә укытудан башлый һәм аның бу башлангычы ул вакытта хәтта рус матбугатының да игътибарына лаек була. Мәсәлән, әлеге уңайдан “Казанский телеграф” газетасы 1898 елда болай яза: “Күптән түгел Яңа бистәдә татар балалары өчен Әмирхан мәдрәсәсе ачылды. Яңа мәдрәсә тиз арада җирле мөселманнарның игътибарын җәлеп итте, аңа беренче атнада ук җитмеш укучы җыелды. Бу хәл укытучы Гаяз Исхакый җәнапләренең грамотага өйрәтүдә яңа аваз алымын кертүе белән аңлатылса кирәк, юкса безнең мәдрәсәләрдә һаман да иске, тапталган хәреф алымы яшәвен дәвам итә. Исхакый җәнапләре бу башланган эшен киләчәктә тагын да киңәйтсен һәм бер нәрсә алдында да тукталып калмасын иде[1]”.

Казандагы Татарская учительская школаны тәмамлап 1902 елда Оренбургтагы танылган “Хөсәения” мәдрәсәсенә мөгаллим булып килгәч тә, Исхакый андагы искергән тәртипләргә каршы чыга, укыту системасын һәм шәкертләрнең яшәү рәвешен яңарту өчен тырыша. Мәдрәсәләрдә укыганда һәм укытканда күргән-кичергәннәре нигезендә Г. Исхакый мәгариф ярдәмендә халыкны агарту, “милли хәятебезне үзгәртү, яхшырту” бурычларын татар дөньясының игътибар үзәгенә куя. Моның өчен мәгариф системасының үзен яңарту һәм камилләштерү кирәклеген искәртеп, мөгаллим-әдип бу эшне беренче чиратта “мәктәп, мәдрәсәләремезне җәдитчә фәннәр укытылачак хәлгә китерү” рәвешендә күзаллый һәм аны “ул вакытның дәрдләрен (борчыган мәсьәләләрен) һәм аларны үзгәртү чараларын” колачлап яктырткан программ характердагы “Ике йөз елдан соң инкыйраз” дигән әсәрендә милләт язмышын хәл итүдә иң мөһим бурычлардан берсе сыйфатында алгы планга чыгара.

Татар мәгарифе, аны заман алга куйган бурычларны хәл итәрлек дәрәҗәдә яңарту һәм камилләштерү турында кайгыртуын дәвам итеп, Исхакый 1914 елдан бу мәсьәләләргә карашын тагын да конкретлаштыра, хәзер мәгарифне балаларга милли һәм дөньяви тәрбия бирү чарасы итеп карауга басым ясый башлый. Мәсәлән, “Мөгаллим вә мөгаллимәләребезнең бу көнгә вазыйфалары нәрсә?” дигән мәкаләсендә (1914) ул бу уңайдан: “Хәзерге заманыбызның мәдәни мәсьәләләренең иң төбе -

балаларыбызны, бер төрле тәрбия биреп, милли рухта җиткерү булганга, мәктәптән теләгебез мәгълүм бер юлга керми хәле бармый. Хәзерге мәктәпнең вазыйфасы безнең киләчәк буыныбызны аңлы, укымышлы бер татар ясап чыгарудыр"[2], - дип яза.

Яшь буынга мондый тәрбия бирүдә Исхакый мәктәп-мәдрәсәләрдә әдәбиятне укытуга аеруча зур өметләр баглый. Аерым алганда, "Тукай мәктәптә" исемле мәкаләсендә (1914) ул "милли әдәбият ашасыннан балага үз рухыбызны, милли рухыбызны сеңдерәбез, кабер ташына кадәр андан купмаслык иттереп аның күңеленә милли рухның иң кирәкләрен кадаклыйбыз, аны мәңгегә татар итеп куябыз"[3], - дип белдерә. Татар әдәбияты мондый вазыйфаны башкара алсын өчен исә ул яшь буын "күңеле омтылган бөтен мәсьәләләргә җавап табар дәрәҗәдә бай булырга тиеш"[4], дигән бурычны куя һәм үзенең әдәби иҗатында шушы бурычны тормышка ашырырга алына. Шул сәбәпле ул үз әсәрләренең тәрбияви әһәмияткә ия булуларына басым ясый.

Татар дөньясының ике гасыр арасындагы хәл-әхвәле турында мәгърифәтчел рухта фикер йөрткән беренче әсәрләре - "Тәгаллемдә - сәгадәт...", "Кәләпүшче кыз" һәм "Бай угылы" повестьларыннан соң Г. Исхакый аларда яктыртылган идеяләрне дәвам иткән һәм милләт язмышын шулай ук мәгърифәтчел планда хәл итүнең тулы бер программасын чагылдырган "Ике йөз елдан соң инкыйраз"ын төгәлли. Әмма алга таба әдип бу программасын күпмедер вакытка ничектер онытып тора һәм аның иҗатында башка төрлерәк мәсьәләләр яктыртыла башлый. Эш шунда: 1905 елдан илдә көчәеп киткән революцион вакыйгалар өермәсенә эләгә, ягъни ул әлеге вакыйгалар йогынтысында илдә барган азатлык хәрәкәтенә кушылып китә. Казандагы һәртөрле революцион чараларда катнашу белән бергә, ул туган ягы Чистайга барып өяз авылларында митинглар оештырып йөри. Мондый эшчәнлеге өчен Г. Исхакый хакимиятләр тарафыннан эзәрлекләнә башлый. Һәм моннан соң полициядән качып яшәргә мәҗбүр була. Болар барысы Исхакыйның иҗтимагый-сәяси карашларында да җитди генә үзгәрешләр тудыра, ягъни алар революционлаша. Ул әсәрлар, яки социалист-революционерлар позициясенә баса һәм яңа карашларын үзе оештырган "Таң йолдызы" газетасы битләрендә ачык чагылдыра. Моңа кадәр татар дөньясына гомуммилли позициядән торып караган Исхакый хәзер сыйнфый позициягә баса һәм милләтнең бер өлеше мәнфәгатьләрен кайгырта башлый. Көрәшче әдипнең дөньяга карашларындагы мондый үзгәреш "Таң йолдызы"ның 1906 ел, 18 маенда дөнья күргән беренче санында бирелгән һәм Исхакый үзе язган баш мәкаләдә ачык чагыла: "Мондый куркыныч, чуалчык вә бик мөһим бер вакытта бер дә эшче һәм үзе эшләп көн күрә торган авыл халкының файда вә сәгадәтләрен күзәтеп, аларны үзләренең дошманнары байлар, бюрократлар һәм болар җырын җырлый торган төрле вөҗдансыз, оятсыз партияләрнең аздыру агуларыннан саклап, үз мәсләкләре, үз сәгадәтләре өчен тырышырга вә шул караңгы төндә, кара урманда таң йолдызы булмакчы булабыз.

Газетабызның авыл халкы өчен лозунгысы "Бөтен җир, бөтен ирек-тер". Эшчеләр өчен "эшче халыкның файдасын саклый торган законнар, эш вакытының сигез сәгатькә калдырылуы, эш бәһасен арттырудыр". Күренә ки, бу мәкаләдә Исхакый игълан иткән лозунглар большевикларныкы белән бик авааздаш. Шулай сыйнфый карашлар белән рухланып, Исхакый һәм аның тарафдарлары, ягъни "таңчылар" хәзер гомуммилли позициядә торып калган һәм "Мөселман иттифакы" партиясенә кергән кичәге фикердәшләре белән көрәшә башлыйлар.

1905 елгы революция вакыйгалары тәэсирендә дөньяга карашларында хасил булган үзгәрешләр әдипнең иҗатында да чагыла. Хәзер ул күбрәк социаль азатлык өчен революцион көрәш идеяләре белән кызыксына һәм шуларны теге яки бу рәвештә яктырткан "Зиндан" повестен, "Алдым-бирдем", "Мөгаллим", "Тартышу" кебек пьесаларын яза. Әмма Исхакый бу әсәрләрендә чагылдырылган сыйнфый карашлар һәм революцион идеяләр "әсирлегендә" әллә ни озак калмый. Аннан соң шундый "әсирлек"тә булган вакытта да Исхакый үзенең үткәндәге мәгърифәтчел идеяләрен яктыртуны дәвам итә. Моны 1901 елда языла башлап беренче кисәге 1907 елда басылып чыккан "Тәләнче кызы" романында ачык күрергә мөмкин. Анда автор илдә революцион кузгалышлар вакытында да аң-белемле булып үз халкына хезмәт итү кебек мәгърифәтчел идеяне калкыта.

Ә менә 1909 елның язында Төркиягә китү Исхакыйның Россиядәге мәгълүм революция йогынтысында хасил булган карашларыннан арынуына һәм кабат милли-мәгърифәтчел позициягә кайтуына булыша. Мондый үзгәреш аның Истанбул шәһәрендә язылган "Тормышмы бу?" романында шактый ачык сизелә. Бирелә автор аерым шәхес яшәешенең максаты мәсьәләсен үзәккә куя һәм аны милләткә мөнәсәбәттән чыгып яктырта.

1909 елның көзендә Г. Исхакый яшерен рәвештә Төркиядән Петербургка кайта. Хакимиятләрдән качып яшәргә мәҗбүр булуы белән бергә аның матди хәле дә авырлаша. Чөнки язылган әсәрләрен бастырып чыгара алмый. Шунлыктан язудан гайрәте чиккән кебек, ул Петербургта язучылык эшен туктатып тора. Моның урынына рус әдәбияте һәм мәдәнияте белән нык-лап кызыксынып китә. Рус язучылары әсәрләрен күпләп укый, аларның һәртөрле җыелышларына йөри, конференцияләрдә катнаша, вольный университетларда үзен кызыксындырган фәннәр, бигрәк тә юриспруденция һәм фәлсәфә буенча лекцияләр тыңлый. Болар барысы аның рухи культурасы үсүгә булыша.

Шундый багаж белән Г. Исхакый 1910 елның язында яшерен рәвештә Финляндиягә килә һәм анда милләттәшләренең җылы мөнәсәбәте аны кабат иҗат эшенә дәртләндерә. Һәм ул кыска гына вакыт эчендә "Мулла бабай" романын, "Фамилия сәгадәте" исемле хикәяләр циклын яза. Алардан күренгәнчә, дөньяга карашларының киңәюе һәм тирәнәюе Г. Исхакыйны милли яшәешкә тагын да җентекләбрәк карауга этәрә.

1910 елның көзендә күтәренке күңел белән Г. Исхакый кабат Истанбулга килә һәм анда бер-бер артлы "Сөннәтче бабай" һәм "Кияү" повестьларын, "Шәкерт абый" дигән күләмле хикәясен яза. Бу әсәрләрендә әдип көндәлек тормыштагы гореф-гадәтләргә һәм традицияләргә мөнәсәбәт мәсьәләсен күтәрә.

1905 елгы революциядән соң Г. Исхакыйга иҗат эше белән еш

кына гадәти булмаган шартларда - я чит илгә качып киткәндә, я үз илендә полициядән яшеренеп яшәгәндә, я төрмә-сөргендә шөгыльләнергә туры килә. 1911 елның ахырында Төркиядән кайтып берничә ай Петербургта полициядән качып яшәгәч, аны хакимиятләр тагын кулга алалар һәм кабат Архангел губернасына, бу юлы инде сөрген губернасының тагын да ераграк өязенә - Мизин шәһәрчегенә сөрәләр. Әмма ул биредә дә бердәнбер күңел юанычы булып калган иҗат эшен дәвам итә һәм “Бер тоткарның саташуы” дигән әсәрен яза. 1913 елның апрелендә исә амнистиягә эләгеп, Исхакый иреккә чыгарыла. Казанда яшәргә рөхсәт бирелмәгәч, ул Петербургка кайта һәм анда кабат матбагачылык эшенә алына, “Ил” газетасын чыгара башлый. Яңа газетаның актив авторлары исәбенә Й. Акчура, М. Бигиев, З. Вәлиди, Ф. Туктаров кебек үткәндәге “Таң йолдызы”ның программасы белән килешеп бетмәгән шәхесләрнең дә керүе хәзер Исхакыйның иҗтимагый-сәяси карашларында яңадан җитди генә үзгәрешләр хасил булуы турында сөйли. Исхакый кабат гомуммилли демократик позициягә баса һәм фактик рәвештә үзе җитәкләгән “Ил”, “Сүз”, “Безнең ил” газеталарында милли характердагы мәсьәләләргә игътибарын арттыра. Хәзер аны бигрәк тә милләт яшәешенең мәдәни-рухи мәсьәләләре кызыксындыра. Әлеге газеталарда басылган мәкаләләрендә ул күбрәк милли тәрбия, мәктәп, туган тел, театр һәм башкалар турында сүз алып бара, күренекле шәхесләрнең язмышларына дикъкать итә. Аны аеруча Тукай язмышы кызыксындыра, аңа “Милли фаҗига” (“Ил”, 1914, 2 апрель) белән “Тукай мәхәббәте” (“Ил”, 1914, 2 сентябрь) дигән мәкаләләрен багышлый. Исхакый Тукайның вакытсыз үлемен милли фаҗига дип карый һәм аны совет дәверендәге кебек сыйнфый планда, ягъни иҗтимагый-социаль сәбәпләрдән (буржуаз дөнья корбаны итеп күрсәтүдән) бигрәк, милли-шәхси характердагы сәбәпләр белән бәйләп аңлата. Ачыграк әйтсәк, Исхакый шагыйрьнең күңел суыклыгын әлеге фаҗиганең мөһим сәбәпләреннән берсе итеп саный, ә монысын ахыр чиктә татар хәятенә кайтарып калдыра.

Үзе җитәкләгән газеталар битләрендә Исхакый тагын милләтнең рухи яшәешендә зур урын тотарга тиешле татар театры, мәгарифе һәм матбугаты торышына җитди игътибар бирә. Конкретрак әйтсәк, “Милли җитешсезлегемез” дигән мәкаләсендә (“Сүз”, 1915, 30 декабрь), мәсәлән, ул татар театрының матди хәле авыр булуына һәм бу хәлнең бездә әлеге төр сәнгатьнең гомум торышына тискәре йогынты ясавына дикъкать итә. Бу театр кешеләрен, ди Исхакый, “көндәлек тормышның чүп-чары изәдер, ватадыр, тормышның ыбырчыбыры аякка бәрелеп, күзгә сугылып, аларны чын хезмәттән, татар сәхнәсен тәрәккый иттерү, татар сәхнәсенең йөзен, күзен күрсәтү бурычыннан аерып, мәгъзур итәдер (чиклидер)”. Әйтергә кирәк: ул вакытта татар театрында Исхакый җитешсезлек дип караган әлеге хәл безнең заманга да күпмедер аваздаш булып кала кебек.

Театрныкы кебек ул вакыттагы татар матбугатының да торышын Исхакый беренче чиратта аның милләткә ничек хезмәт итүеннән чыгып бәяли. Мәсьәләгә шушы яссылыкта карап, ул хәтта “Йолдыз” газетасының 10 еллыгына багышланган “Йолдыз”ның юбилейсе” мәкаләсендә дә (“Сүз”, 1916, 20 гыйнвар), бәйрәм кәеф-сафасын читкә куеп, әлеге матбага эшчәнлегенә үтә тәнкыйтьчел бәя бирә. Эш шунда: милләт өчен җан атып яшәгән Исхакый үзләрен милләтчеләр дип исәпләгән башка кешеләрнең дә бу изге эштә шулай янып йөрүләрен тели. Шушы карашыннан чыгып, ул “Йолдыз” газетасын, дөресрәге, аның җитәкчелеген, рәсми хакимият белән килешеп яшәүдә, милләт мәнфәгатьләрен кайгырту нисбәтендә пассивлык күрсәтүдә һ.б. гаепләп чыга.

Татарны милләт буларак яшәтүдә һәм үстерүдә төп өметне аның яңа яшь көчләренә баглап, Исхакый үзенең “Яшь көчләрнең бурычы” дигән программ характердагы мәкаләсендә (“Сүз”, 1916, 14, 19, 23 август) милләтнең киләчәге турында кайгыртканда бу өлкәдәге иң мөһим бурычны яшь буынга милли тәрбия бирүдә күрә. Ә бу бурычны хәл итүне әдип беренче чиратта мәктәпләр эшчәнлеге белән, дөресрәге, аларның никадәр милли була алуы белән, бәйләп карый.

Милләт яшәешен һәм язмышын хәл итүдә яшь буынны милли рухта тәрбияләүгә өстенлекле урын биреп, Г. Исхакый алга таба үзенең әдәби иҗатында да әлеге мәсьәләне төрле яклап яктырта. Бер очракта, әйтик, “Мөгаллимә” пьесасында ул яшь буынга шундый тәрбия бирә алган мөгаллимәне пьедесталга бастыра. Икенче бер очракта исә, мәсәлән, “Ул әле өйләнмәгән иде” повестенда игътибарын шулай тәрбия бирүгә комачаулый торган күренешләргә юнәлтә, моңа гыйбрәтле мисал итеп катнаш гаиләне ала. Әсәрнең үзәк геройлары - татар егете Шәмси белән марҗа Анна корган гаиләдә балаларга татар тәрбиясе бирелә алмау аркасында соңгылары русլашып китәләр.

XX йөз башында татар дөньясының идеологына һәм лидерына әверелүе сәбәпле, Г. Исхакый төрле характердагы иҗат эшен һәрвакыт иҗтимагый-сәяси эшчәнлек белән тыгыз бәйләп алып бара. 1917 елгы Февраль революциясе аның бу эшчәнлегенә яңа бер рух өрә һәм ул җәмәгать тормышында тагын да активрак катнаша башлый. Г. Исхакыйның бу вакыттагы иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге күбрәк татар милләтенең алга барыр юлларын һәм гомумән киләчәк язмышын билгеләячәк чараларда - Россия мөселманнары корылтайларын үткәрүдә катнашудан, дөресрәге, башлап йөрүдән гыйбарәт була. Әлеге корылтайларның беренчесен оештыруда һәм үткәрүдә ул Мәскәү “Мөселман комитеты” рәисе сыйфатында катнаша. 1917 елның 1-11 маенда Мәскәүдә булган бу корылтайны ул әлеге комитет исеменнән котлый һәм анда төп доклад белән чыга. Үз докладында ул Россиядәге барлык мөселман халыкларыныкы булган бу корылтайның төп вазыйфасы итеп “бөтен Русиягә җәелгән утыз миллионлы мөселман халкының, бөтен Русиягә таралган егерме тугыз миллионлы төрек-татар углының киләчәктә барачак сәяси, икътисадый, иҗтимагый юлын[5]” ачыклауны саный һәм үзе шул юлны билгели дә. Аныңча, бу юл “төрле фикер, төрле мәсләкләргә аерылган мөселманнарны, һәммәсе өчен гам (гомуми) булган матдәләрдә бергә җыеп, бер байрак астында берләштереп, гам иттереп бер платформа[6]” ясаудан гыйбарәт. Милли-мәдәни мохтарият рәвешендә күзалланган бу платформаны тормышка ашыручы орган итеп Исха-

кый бөтен халык тарафыннан сайланган Милли шураны саный. Корылтай Г. Исхакый докладында күтәрелгән мәсьәләләрне хуплый һәм аның тарафыннан әзерләнгән резолюцияне үзенең төп карары төсендә кабул итә.

Резолюциянең 9 нчы пункты нигезендә Россия мөселманнарының икенче корылтае шул ук елның августына кадәр үткәрелергә тиеш була һәм ул июнь аенда Казанда уздырыла. Әмма илдә иҗтимагый-сәяси хәлнең үтә киеренке һәм катлаулы булуы аркасында, анда Урта Азия, Кавказ һәм Кырым вәкилләре катнаша алмый. Шунлыктан икенче корылтай Идел-Урал төбәге мөселманнарын, ягъни татарлар белән башкортларны күздә тотып эш итә. Бу канкардәш халыкларның иҗтимагый-сәяси киләчәген хәл итү өчен Уфада Милли мәҗлес үткәрү планлаштырыла һәм аны оештыру өчен вакытлы бюро сайлана. Аның составына Г. Исхакый да кертелә.

Әлеге Милли мәҗлес инде бөтенләй башка иҗтимагый-сәяси шартларда, илдә Октябрь революциясе булып, хакимият большевиклар кулына күчкәч үткәрелә. Ул Уфада 1917 елның 22 ноябреннән 1918 елның 11 гыйнварына кадәр эшли. Анда тикшерелгән күпсанлы мәсьәләләр арасында иң мөһиме итеп милли дәүләтчелекне ничек төзү мәсьәләсе карала. Һәм аңа карашлар да төрле була.

"Тупраксыз мохтарият" тарафдарлары Г. Исхакый, Һ. Максуди, Г. Терегулов, З. Кадыйри һәм башкалар татар-башкорт өчен генә түгел, бәлки Россиядәге бөтен төрки халыклар өчен уртак милли-мәдәни мохтарият (автономия) булдыруны яклап чыгалар. "Тупракчылар" И. Алкин, Г. Шәрәф, Ф. Сәйфи, С. Атнагуловлар исә Идел-Урал штатын төзү ягында булалар. Милли мәҗлес соңгы вариантны хуплый. Анда тагын дини, мәгариф, финанс мәсьәләләре белән шөгыльләнергә тиешле Милли идарә һәм Версаль солых конференциясенә барырга тиешле вәкилләр сайлана. Соңгылары арасында Г. Исхакый да була. Бераздан большевиклар бөтен милли оешмаларны, шул исәптән Милли мәҗлес белән Милли идарәне дә куып тараталар. Моннан соң большевиклар сәясәтеннән риза булмаган яки аларның эзәрлекләвеннән качарга теләгән милләттәшләре белән Г. Исхакый да мөһаҗирлеккә китеп бара. Шулай аның гомеренең мөһим бер чоры тәмамлана. Алда исә аны нәкъ менә милләтпәрвәр зат булганы өчен үтә авыр, катлаулы һәм хәтта фаҗигале төс алачак язмыш көтә.

Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге эшчәнлеге беренче чиратта чит илләргә таралган милләттәшләрен берләштерү белән бәйле. Шушы максатта ул "Идел-Урал комитеты"н һәм халыкара оешма "Прометей"нең татар бүлеген төзи. Болар хакында ул 1931 елда Иерусалимда үткәрелгән Бөтендөнья мөселман конгрессында чыгыш ясый һәм, анда хуплау алып, бөтенмөселман экзекутивы (зур советы) әгъзасы итеп сайлана. Яңа планнарын тормышка ашыруда Исхакый башлап Ерак Көнчыгыш илләрендә яшәүче милләттәшләрен берләштерүгә игътибар бирә. Чөнки әлеге илләрдә татар мөһаҗирләренең иң зур һәм хәлле өлеше яши. Аларның бу илләрдә төрле оешмалары да барлыкка килә. Мисал өчен Харбинда Россиядән Кытайга күчеп килгән 16 нчы татар полкы җирлегендә татар сугышчылары союзы оеша, татар яшьләре һәм хатын-кызлары оешмалары, татар мәхәлләсе, мәктәбе һәм китапханәсе эшли. Мукденда татарларның милли оешмасы, мөһаҗирләрнең үзара ярдәмләшү җәмгыяте, татар яшьләре түгәрәге, хатын-кызлар оешмасы, милли мәктәп, мәхәллә була. Токиода, әле генә саналган типтагы оешмалар белән беррәттән, "Яңа япон мөхбире" дигән газета да чыгарыла.

Әмма мондый оешмалар һәркайсы үзалдына гына яши, алар арасында бәйләнешләр булмый диярлек. Аларны берләштерү ихтыяҗы үзен торган саен ныграк сиздерә. Бу ихтыяҗны аеруча тирән аңлаучыларның берсе Г. Исхакый була. Ул әлеге максатта Ерак Көнчыгышка бару ниятенә килә. Әмма бу ниятен тормышка ашыру җитди каршылыкларга очрый һәм шактый вакытка сузыла. Нәтиҗәдә Г. Исхакыйның Ерак Көнчыгышка баруы мәсьәләсе бары 1933 елның сентябрь аенда гына хәл ителә. Польша хакимиятләренең матди ярдәме белән оештырылган бу сәяхәт бер үк вакытта поляк һәм немец разведкасының ныклы күзәтүе астына алына. Донесениеләрдә әдипкә "Шольц" дигән кушамат бирелә. Бу дәвамлы сәяхәт вакытында Япониядәге, Кытай, Монголия һәм Корeядәге милләттәшләре арасында булып, Г. Исхакый бик күп каршылыкларны җиңә-җиңә аларның корылтайларын уздыра һәм аларда "Идел-Урал комитеты"ның җирле үзәкләрен оештыра.

Гәрчә Ерак Көнчыгыштан, ике елдан артыкка сузылган командировкадан Европага арып-талып кайтса да, Исхакый ял турында уйламый, бәлки мөһаҗир милләттәшләрен берләштерү эшен дәвам итә. Шундый максат белән ул эмиграциядәге бөтен төрки-татарлар конгрессын үткәрүне планлаштыра һәм шуңа әзерлек эшләрен җәелдереп җибәрә. Бу конгресс 1938 елның 4-6 февралендә Варшавада Милли мәҗлеснең 20 еллыгына багышлап үткәрелә.

Төрле илләргә таралган милләттәшләрен берләштерү өчен корылтайлар үткәрү, милли үзәкләр төзү белән бергә, Г. Исхакый әлеге максатта мөһаҗирлектә татар матбугатын булдыруга зур игътибар бирә. Үзенең шәхси тырышлыгы белән Берлинда 1928-30 елларда "Милли юл", ә аннары 1939 елга кадәр "Яңа милли юл" исеме астында журнал чыгара. Гәрчә бу матбагаың төп бурычы һәм максаты татар милләтенең бүгенге хәле һәм киләчәге турында кайгырту булса да, Г. Исхакый анда басылган мәкаләләрендә Россиядә рус булмаган халыкларның большевиклар кул астындагы хәле һәм киләчәге хакында уйлана. Бу яктан аның "Русиянең киләчәге" дигән мәкаләсе ("Милли юл", 1929, 2-3 саннар) программ мәгънәгә ия. Башта СССРда ул еллардагы гомум хәлгә тукталып, ул большевикларның яңа матур һәм мул тормыш вәгъдә итүләре сүздә генә калуын күрсәтә. Аныңча, большевиклар утырткан, "вә халыкка бик мул, тәмле җимешләр бирергә тиеш булган бу социализм агачы, тирәюнендәге бөтен үсемлекләрне фида итеп корытып бетерү вә бөтен барлыкларны яндыру вә юк итү кебек зур фидакарьлекләр аркасында, әлегә чаклы җимеш бирмәдe". Большевиклар хакимиятенең вакытлы һәм узгынчы күренеш икәнен искәртеп һәм алардан соңгы Россиянең яшәү рәвеше нинди булырга тиешлеге турында уйланып, әдип аның халык

күңелендә хәтта "большевикның бураны эчендә сау калган, утта янмаган вә суга батмаган" биш кыйммәткә - милеккә, миллияткә, дингә, хөррияткә һәм халыкчанлыкка нигезләнергә тиешлеген әйтә. Алга таба Исхакый Россиянең киләчәгенә андагы иң көчле рус һәм украин дөньясындагы карашларны кыскача гына бәян итә. Мөһаҗирлектәге руслар арасында бу мәсьәләдә төрле фаразлар булса да, әдип асылда "бүленми торган берлек Русиясе" идеясе русның төрле катлауларын яки төркемнәрен бер-берсенә якынайтуын һәм берләштерүен күрсәтә. Әйтергә кирәк: бу мәсьәләдә тарих кабатлана, ягъни әлеге идея бүген дә Россиянең киләчәгенә рус дөньясындагы төрле караш тарафдарларын берләштерә.

Украиннар мәсьәләсенә мөрәҗәгать итеп, Исхакый башта бу халыкның руслар белән этник туганлыгы яки кардәшлеге турындагы карашны кире кага. Украиннарны ул "төрек-татар берлә слау (славян) халыкларының кушылуыннан килеп чыккан бер милләттер" дип карый, аларның "табигате, гореф-гадәте дә (халык әдәбияте, музыкасы, җыры вә бию-ләре) великорусларныкыннан артыграк төрек-татарга якынрак", ди. Моның өстенә, 1654 елда бөтен эчке эшләрендә мөстәкыйль булу шарты белән Мәскәүгә кушылып тиз арада алданганнарын аңлаган украиннар шул вакытлардан бирле Россиядән бәйсез булу юнәлешендә эш итеп киләләр. Г. Исхакый украиннарның шушы азатлык өчен күпгасырлык көрәш тарихын күз алдына бастыра. Шушы көрәш нәтиҗәсендә, дип тәмамлый мәкаләсен Исхакый, "Украина истикълялының (бәйсезлегенең) бөтен кирәкле нигезләре салынган, терәкләре корылган вә яңа дәүләтнең яшәве өчен бөтен хәзерлекләр эшләнгән хәлдәдер. Шуның өчен мөстәкыйль Украинаның рәсми яши башлавы бер вакыт вә заман мәсьәләсе генәдер. Большевикларның бу көн Украинага каршы иткән кысынкылыклары руслык ноктасыннан һичбер файда бирмәячәктер. Беренче форсатта мөстәкыйль Украина мәйданга чыгачактыр вә яшәячәктер!"

Безнең көннәр бу фаразның, чыннан да, нигезле һәм урынлы булуын раслады. СССР таркала башлау белән Украина тиз генә үзенең мөстәкыйльлеген игълан итте, бәйсез дәүләт булып яшәп китте, ягъни мөстәкыйль яшәүгә күптән әзер булуын күрсәтте.

Россиянең киләчәге турында шундый фаразлар белән беррәттән, Исхакый үзе чыгарган "Милли юл" һәм "Яңа милли юл" битләрендә, табигый, татар милли-азатлык хәрәкәтенең бүгенгесе һәм киләсе көне хакында да уйлана. Бу яктан мисал өчен "Яңа милли юл"ның 1939 елгы 135 санында (июль) аның "Безнең юлымыз" дигән баш мәкаләсе игътибарга лаеклы. Анда татарның азатлыгы мәсьәләсе үзалдына гына түгел, бәлки башка төрки халыкларныкы белән бергәлектә карала. Һәм бу канкардәш халыкларга үз максатларына ирешү өчен үзләренә аерым юл сайларга кирәклегенә басым ясала.

Октябрь революциясе нәтиҗәсендә дөньяга сибелгән татарны берләштерүгә, туган халкының милли азатлыгы өчен көрәшкә багышланган актив һәм фидакарь җәмәгать эшчәнлеге белән бергә, Исхакый мөһаҗирлектәге күпкырлы иҗатын да шул ук максатларга хезмәт иттерә. Безгә хәзергә аның эмиграциядәге әдәби иҗаты күбрәк билгеле. Бу эшчәнлеккә гомумирәк караш ташласак, без әдипнең үз игътибарын, бер яктан, әлеге максатка ирешергә комачаулаучы яки аңа зыян китерүче хәлләргә юнәлтүен күрербез. Шундый хәлләрнең иң күңелсезләреннән һәм зыянлыларыннан берсе итеп Исхакый татарлар арасында үз милләтеңнән качып руслашуның яки шуңарга омтылуның киң таралуын саный. "Җан Баевич" комедиясе белән "Көз" повестенда әдип моның ише гамәлләрнең милләт белән бергә андый кешеләрнең үзләренә дә зыян гына китерүен күрсәтә.

Икенче яктан, татарның хәзерге язмышын кайгыртканда Исхакый тарих тәҗрибәсен һәм сабакларын да искә алырга кирәклеген искәртә. "Өйгә таба" повестенда, мәсәлән, рус-төрек сугышларының берсен сурәтләү аша автор тарихи бер хакыйкатьне - Россиядә төрки халыкларның бердәмлеген булдырмас өчен гасырлар дәвамында аларны үзара ызгыштыру сәясәте алып барылуын чагылдыра.Әсәрдә патшага турылыклы хезмәт итәргә ант биргән татар полковнигы Тимергалиевнең, шул сугыш вакытында әлеге хакыйкатьне аңлагач, төрек канкардәшләренең башын кисәргә әзерләнгән рус балтасының сабы булырга теләмәве аның кул астындагы мөселман солдатларында да хуплау табуы һәм Тимергалиев җитәкләгән мөселман дивизиясенең төрекләр ягына чыгуы тасвирлана. "Олуг Мөхәммәд" пьесасында исә тарихи фактларга нигезләнеп, Казан ханлыгы турында моңа кадәр рәсми рәвештә таратып киленгән яла ягулы карашлар кире кагыла һәм бу дәүләтнең күрше басып алучылардан үз бәйсезлеген саклап калу өчен көрәшеп яшәве сурәтләнә. Моның белән әсәр татарларны берләштерүдә һәм милләт буларак яшәтүдә иң мөһим рухи көчне - милли горурлык хисен үстерүгә булыша.

"Тартышуда гына табарсың үз хакыңны!" - дип бөтен аңлы гомерен туган халкының иминлеге һәм бәхете өчен тартышуга, ягъни көрәшүгә багышлаган Исхакый шушы көрәшен вафатына берничә ай кала, 1954 елның 12 апрелендә Финляндиянең Тампере шәһәрендә яшәгән татар кызы Халидәгә язган тарихи мәгънәле хатында бүгенге һәм киләчәк буыннарга васыять итеп тә калдыра. Тарихка көрәшче әдипнең татар милләтенә мәгънәви васыяте булып кергән әлеге хатында Исхакый дөньяга сибелгән милләттәшләрен милли идея байрагы астында берләштерүне һәм шул юл белән татарның азатлык турындагы күпгасырлык хыялына ирешүне киләчәк буыннарның иң мөһим милли бурычы дип бәяли. Һәм татар дөньясы хәзерге шартларда шушы васыятьбурычны гамәлгә ашыру юнәлешендә эш алып бара. Бу тарихи процесста Исхакый шәхесе һәм мирасы туып килүче яңа XXI гасырда да безнең халыкка юл күрсәтүче һәм рух бирүче якты маяк булып калачак.

ИСКӘРМӘЛӘР:

1. Н. П. Из мусульманского мира. - Казанский телеграф. - 1898. - 15 янв.
2. Мәгърифәт. - 1997. - 27 авг.
3. Мәктәп - 1914. - 6 - 127 б.
4. Исхакый Г. Яшь көчләрнең бурычы. - Мирас. - 1992. - 5. - Б. 73.
5. Гомумрусия мөселманнарының беренче съезды. - Вакыт, 1917, 10 май.
6. Вакыт, 1917, 10 май.

Һәйкәл итик хәтерне!

Хөрмәтле туганнар! Мөхтәрәм җәмәгать!

Барыбыз да белгәнебезчә, моннан 447 ел элек канлы бәрелешләрдән соң Казан ханлыгы, дәүләт буларак яшәүдән туктап, рус дәүләтенә кушылды. Казан өчен аяусыз көрәш барганда һәр ике яктан да бик күп сугышчылар һәлак булды.

Казанны яулап алганда үлгән рус сугышчыларына 1823 елда һәйкәл куелган иде. Башкалабызны яклап шәһит киткән бабаларыбыз истәлегенә гади генә таш та куелмады. Ләкин халык хәтерендә аларның фидакарьлеге һәрвакыт кадерләп сакланып килде.

Ниһаять, шул хәтерне һәйкәл итеп сынландыру вакыты да житте. Бик күп халык вәкилләре һәм җәмәгать оешмаларының мөрәҗәгатьләрен искә алып, Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты 1552 елда Казанны саклаганда һәлак булган каһарманнар истәлегенә багышлап һәйкәл төзү турында 1999 елның 26 февралендә карар кабул итте.

Шушы карарны үтәү йөзеннән һәйкәлне төзү өчен махсус фонд оештырылды. Бүгенге көндә ул фонд рәсми рәвештә теркәлеп, үзенең эшен башлап җибәрде.

Булачак һәйкәлнең проектына конкурс игълан ителде. Берничә проект инде жюри тарафыннан карап тикшерелде дә.

Һәйкәл 2000 елда төзелеп бетәр, дип уйлыйбыз.

Төзелешне тизләтү өчен, әлбәттә инде, финанс чыгымнары кирәк. Һәйкәл халык хәтеренең символы булганга, аның чыгымнарын да җәмәгать белән күтәрербез дип өметләнәбез. Бу изге эштә һәрберебез дә хәлебездән килгәнчә катнашырбыз, оешмалар, предприятиеләр дә читтә калмаслар, дип уйлыйбыз.

Казанны яклап һәлак булучыларга һәйкәл кую мәсьәләсе күтәрелгәч, заманында төрле бәхәсләр дә булып алды. Бу турыда бүген дә берничә сүз әйтеп китәргә кирәктер.

Һәйкәлнең зарурлыгына шик белдерүчеләр бар. Берәүләр җиңелүебез хөрмәтенә һәйкәл төзү урынлы булырмы дисә, икенчеләр ул һәйкәл ике милләт арасында каршылык тудырмасмы, дип борчылалар.

Безнең уебызча, андый шикләнүләргә нигез юк. Төзеләчәк һәйкәл халык хәтере символы булып, аның янына килүчеләрне уйландырыр. Үткәнебез, бүгенгебез, киләчәгебез турында уйланып күпсанлы корбаннар бирмичә тату яшәүнең серенә төшенергә тырышырбыз. Һәр сугыш халык хәтерендә фаҗига булып саклана. Сугышны халыклар түгел, канга сусаган хакимнәр башлый. Халык ул сугышларда корбан гына була.

Килер заман, кешеләр төрле низагларны кан коеп сугышмыйча, акыл белән чишәргә өйрәнерләр. Дөнья белән идарә итәргә җыенучы тиран хакимнәрнең нәфесләренә чик куя белерләр. Бөтен халыкларны тигез итеп күргән Җир-анабыз берәү генә. Аны кан белән сугару зур гөнаһ икәнен кешеләр аңларлар.

Казансу елгасының бер ярында Казанны яклаучыларга һәйкәл торса, икенче ягында Казанны алганда үлгән рус сугышчыларына куелган һәйкәл бер-берсенә карашып сүзсез генә сөйләшерләр, аңлашырлар, татулыкка юл эзләрләр.

Безнең фонд рус сугышчылары истәлегенә салынган һәйкәлне төзекләндерүне дә күздә тота. Ул эшкә дә үз өлешләрен кертүчеләр булыр, дип уйлыйбыз.

Хәерле сәгатьтә эшкә тотыныйк, җәмәгать!

Туфан МИҢНУЛЛИН,
фонд рәисе, драматург,
Татарстан халык депутаты.

1552 елда Казанны яклаганда һәлак булганнарга һәйкәл кору Фонды:

ИНН 1654036144
Расчетный счет
N 40703810900000000103
в КИТБ “Казанский” г. Казань
БИК 049205806
к/с 30101810300000000806

Акчаны түбәндәге адрес белән дә кертеп тапшырырга мөмкин:

Казан шәһәре, Кремль урамы, 9 нчы йорт, 2 нче кат, 13 нче бүлмә.

Мәрхүм ата-аналарыбызны хөрмәт итик, истәлекләрен саклауга ярдәм кертик!

Ягъсуф ШӘФЫЙКОВ,
публицист.

Фикърәт ТАБЕЕВ

(Шул исемдәге китаптан өзекләр)

Үсеш баскычлары

Ул елны мин чак кына ВЛКСМның Бөгелмә өлкә комитеты секретаре булмый калдым. Илдә өлкә комитетларын ваклау башланган иде. Татарстанда Чистай, Бөгелмә һәм Казан өлкә комитетлары булдыру планлаштырылды. Шөкер, андый ахмак адымнан тиз ваз кичтеләр.

Әлеге елларда партиянең Татарстан өлкә комитеты секретаре булып партия төзелешенең зур оештыручысы, республика һәм союз күләмендә бик күп талантлы җитәкчеләр тәрбияләгән Семен Денисович Игнатьев эшли иде.

С. Д. Игнатьев партия карьерасын Бурятиядә беренче секретарь постында башлый. Аннары ул шактый вакыт Башкортстан Республикасы партия оешмасын җитәкли. Озак вакытлар ул ВКП(б) ҮКның оештыру бүлеге мөдире була. Сталинның соңгы елларында Семен Денисович бер үк вакытта Кремль коменданты вазыйфасын да үтәгән. Сталин бу куәтле фигура белән үз тирәлегеннән дәһшәтле Берияне читләштерергә омтылган.

Юлбашчы вафат булгач, Семен Денисович берара җәбергә эләгеп тора. Бераз вакыт узгач, Н. С. Хрущев шәфкать күрсәтә һәм 1953 елның салкын җәендә С. Д. Игнатьевны янә Башкортстанга өлкә комитетының беренче секретаре итеп җибәрә. Миңа мәгълүм булганча, аны күрше Башкортстанда яхшы кабул иткәннәр. Анда аның һәм уңай, һәм тискәре сыйфатларын яхшы белгәннәр. Миңа калса, С. Д. Игнатьев Башкортстанны үстерүгә гаять зур өлеш кертте.

1957 елда КПСС ҮК Семен Денисовичны Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре итеп җибәрде. Һәм безнең партия оешмасында да үз элгәрләреннән уңай якка аерылып торды. Гаҗәеп үзенчәлекле фигура иде ул. Әмма мин аның иң төп яхшы ягы кешеләрдәге талант чаткыларын, гадәттән тыш эшлекле, сәяси сыйфатларын күрә белүе иде, дип саныйм. Ул теләсә кайсы баскычтагы кадрларны югары профессиональ дәрәҗәдә сайлап ала белә иде. С. Д. Игнатьев куйган кадрлардан аның ышанычын акламаган кешене белмим, хәтерләмим һәм ишеткәнем булмады.

Уйлавымча, безнең бүгенге федераль, республика һәм өлкә башлыкларына, шулай ук башка җитәкчеләргә дә нәрсә җитми дисәгез - ул да булса теләсә кайсы дәрәҗәдәге җитәкчеләрне сайлап ала белмәү. Кызганыч, бүген кадрлар әзерләү һәм сайлап алу системасы тулысынча юкка чыкты. Беренче дәрәҗәдәге күп кенә затларның төп постларга кешеләр сайлап алу фәненә сәләте юк...

1957 елда мине өлкә комитетына фән, мәдәният һәм мәгариф бүлегенә мөдир итеп алдылар. Нәкъ шул

(Дәвамы. Башы 1 нче санда)

вакытта мәктәп мәгарифенә реформа башланды. КПСС өлкә комитетының идеология секретаре гаҗәеп җанлы зат, хәзер философия фәннәре докторы Камил Фатыхович Фасеев иде.

1958 елда аны Татарстан Югары Советы Президиумы рәисе, ә мине өлкә комитетының идеология секретаре итеп сайладылар. Мин ул постта ике ел эшләдем. Шул арада төрле дәрәҗәдәге күп җитәкчеләрне яңадан белдем, югарырак баскычтагы партия эше алымнарын һәрьяклап үзләштердем. Сүз дә юк, күп нәрсәне Семен Денисович Игнатьевтан кабул иттем. Мине шундый гүзәл шәхес, союз күләмендәге тиңдәшсез оештыручы кеше белән очраштырганы өчен язмышыма рәхмәтлемен.

Ә 1960 елда инде мине КПССның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре итеп сайладылар.

- Дистә еллар узгач, миннән еш кына сорыйлар: кем инициативасы белән сезне КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре постына тәкъдим иттеләр? Күпләр бу - Н. С. Хрущевның шәхси күрсәтмәсе белән эшләнгәндер, дип уйлыйлар.

Алай ук түгел бу. Мин моны төрле хәлләрнең кисешүе нәтиҗәсе дип саныйм. Н. С. Хрущев һәркайда яшьләрне күтәрә башлады. Ә Сталин мәктәбен үткән иске карашлы кешеләрне, киресенчә, "шудыра" торды. Сүз дә юк, минем кандидатура Никита Сергеевич белән килештерелгән булган. Аңа минем эшлеклелек сыйфатларымны телдән җиткергәннәр һәм алдына "объективка"мны китереп салганнар. Ә минем белән турыдан-туры КПСС ҮКның икенче секретаре Фрол Романович Козлов шөгыльләнде. Хөрмәтле һәм бик тә төпле кеше иде. Соңрак аның минем якташ булуы ачыкланды. Ул - Касыймнан, ә мин - Әзидән. Кызганычка каршы, аны аппарат ызгышында сытып аттылар. Ул чагында Фрол Романович ҮКда беренче булып совет икътисадын совнархозларга бүлгәләүгә, Хрущев волюнтаризмына каршы чыкты. Тиздән ул җитди авырып китте һәм вафат булды. Ир-егетне илтеп җиткерделәр, дип әйтергә мөмкин.

Совнархозларга мөнәсәбәттә Фрол Романович Козлов бик үк хаклы түгел иде. Совнархозлар илнең икътисады һәм гомумән җәмгыять үсешенә мәгълүм бер өлеш керттеләр. Сталинчыл консерватизмына карамастан, Н. С. Хрущев республика, край һәм өлкәләргә мәгълүм дәрәҗәдә икътисадый ирек бирү зарурлыгын аңлаган. Илленче еллар ахырындагы һәм алтмышынчы еллар башындагы совнархозлар бүгенге икътисадый реформаларның хәбәрчесе иде. Аларны төзү Хрущевның халык хуҗалыгы тармакларына үзәкләштерелгән җитәкчелектән китәргә омтылуы иде. Совнархозлар төзелгәнче вак-төяк мәсьәләләрне дә Мәскәү белән килештерергә туры килде. Совнархозлар дәверендә җирле сәнәгать, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү үсештә зур этәргеч алды. Әгәр хәтерегездә булса, совнархозларга хәтле, әйтик, безнең Татарстанда гына да бик күп төрледән-төрле артельләр, һөнәрчелек производстволары яшәп килә иде. Союз мәйданындагы куәтле, үскән предприятиеләр ярдәмендә технологик процессларны мәгълүм дәрәҗәдә тигезләү исәбенә артельләр һәм һөнәрчелек производстволары технологик яктан шактый ук хәлле предприятиеләргә әйләнделәр.

Әлбәттә, Н. С. Хрущев идарәсенең соңгы елларында совнархозлар үз вазыйфаларын үтәделәр, алга баруны тоткарлый башладылар. Җитештерүче көчләр һәм җитештерү мөнәсәбәтләре, тулаем безнең җәмгыять халык хуҗалыгы советларын алга таба реформалауга әле әзер түгелләр иде. Менә шуңа күрә алар бетерелде. Кем әйтмешли, һәрнәрсәнең үз вакыты.

Хрущев дәвере

- Фикърәт Әхмәтҗанович, КПССның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре постында эшләвегезне шартлы рәвештә ике өлешкә, дөресрәге, ике дәвергә: Хрущевныкына һәм Брежневныкына бүләргә мөмкин. Миңа калса, бу ике дәвердә булган вакыйгаларга бәйле рәвештә сезнең эшчәнлеккә билгеле бер бәя бирәсе иде.

Беренчедән, әйдәгез, ул көннәргә әйләнеп кайтыйк. Хәтеремдә: Сезне, яшь беренче секретарьны, республикада, аерым алганда Казанда, яхшы кабул иттеләр.

- Кабул иттеләр итүен... Әмма С. Д. Игнатьев кебек гаять зур сәяси шәхестән соң беренче вакытларда җиңелдән булмады. Күз алдына китерегез: оборона предприятиеләренең җитәкчеләре хуҗалыкчы зубрлар, ә алар артында тагын да белдеклерәк зубрлар - союз күләмендәге министрлар, шулай ук күп меңле коллективлар тора иде. Яшерәсем юк: тормышта менә шундый зубрлардан аяк өсте өйрәнергә туры килде. Алар алдында мин малай-шалай гына идем бит.

Ул вакытта ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Фәхретдинов иде.

Шулай менә, ул миннән ике яшькә өлкәнрәк иде. Партконференцияләрнең берсендә чәнчүле язу җибәрәләр: "Иптәш Табеев, яшь ягыннан кайсыгыз өлкәнрәк?" Мин зал алдында шаяртып котылырга мәҗбүр булдым: тәнәфес вакытында ачыкларбыз, янәсе.

- Гомумән, Хрущев белән еш очраша идегезме?

- Бик еш. Мин - рухым белән революционер. "Правда", "Известия" газеталарында мөһим темаларга зур-зур аналитик мәкаләләр белән чыга башладым. Мин ул чагында СССРда статистика күрсәткечләрен реформалау буенча бөтен бер хәрәкәтне җитәкләдем. "Вал"га каршы чыктым. Республикалар, край һәм өлкәләрнең реформатор җитәкчеләре мине якладылар. Үземә мөнәсәбәтенә карап мин Никита Сергеевичның матбугаттагы чыгышларымны игътибар белән өйрәнүен тойдым. Гомумән, Хрущев мине бик ярата иде. Мин моны белеп һәм даими тоеп тордым.

Үзенең карарларында Никита Сергеевич Хрущев кайчакта шулкадәр катгыйлык, мин әйтер идем, шулкадәр үҗәтлек күрсәтә иде ки, кайчагында хәйләгә дә барырга туры килә иде. Килеп туган хәлләр мәҗбүр итә иде. Шундый бер манзара булды. Н. С. Хрущев белән Воронежда авыл хуҗалыгы киңәшмәсендә утырабыз, һәм ул миңа мөрәҗәгать итә: "Иптәш Табеев, сезнең Татарстанда борчак яхшы үсә. Мин сезгә борчак белән солы чәчәргә тәкъдим итәм..."

Хрущев уенча, әгәр шулай катнаштырып чәчсәң, борчак ятмаячак, аны җыеп алу җиңел булачак. Ул вакытларда махсус техника юк бит. Ә бит татарлар гомер бакый борчакны чалгы белән чабып кулдан җыйганнар. Хрущевка әйтәм, янәсе, алар - ярәшми торган үсемлекләр. Ул миңа кычкыра гына бит: "Сезгә әйтелгән: "чәчәргә!" "Чәчегез - вәссәлам!" Кем әйтмешли, үҗәтләнде генә бит бабай. Кайсыдыр бер "акыллы баш" аңа безне борчак белән кәрешкә чәчәләр дип җиткергән.

Казанга кайткач, Министрлар Советы рәисе Абдразяковка сөйләп бирдем.

"Нишлибез? Безнең кукурузчы атабыз солыны борчак белән чәчәргә куша..." - Ул миңа җавап бирә: "Әйдәгез, болай итәбез: Казан тирәсендәге хуҗалыкларда кайда биш, кайда ун гектарда солы белән борчак чәчик, бераз ерактарак та урнаштырыйк. Мәскәүдән тикшерергә килсәләр, шунда алып барырбыз".

Шулай эшләдек тә. Ләкин солы белән борчак - берберсенә гомерлек дошманнар. Алар бер-берсен күрә алмыйлар.

Көзен КПСС ҮКның авыл хуҗалыгы бүлегенә шылтыратам да әйтәм:

- Юк-бар мәсьәлә белән Никита Сергеевичны борчу уңайсыз. Борчак-солы операциясен тикшерү өчен комиссия җибәрегез.

Тиздән республикага Хрущевның авыл хуҗалыгы буенча ярдәмчесе, ул чакта бөтен илгә мәгълүм академик Шевченко җитәкчелегендә ҮКдан бик җитди комиссия килеп төште дә тикшерергә кереште. Алар Н. С. Хрущев ниятенең чынлыкта һәлакәтле икәненә ышандылар һәм аңа аңлатма язып бирделәр.

Менә шулай итеп мин дипломатик юл белән Н. С. Хрущев басымыннан котылдым. Аның каравы без асылда куркыныч булган борчак-солы тәҗрибәсеннән күпме уңдырышлы җирне коткарып калдык.

- Фикрәт Әхмәтҗанович! Хәтердә: Сез Татарстанда Хрущевның кукуруз эпопеясен актив якладыгыз бит...

- Әй-йе! Мин моңа кызармыйм. Киресенчә, горурланам! Кукуруз - Татарстанның авыл хуҗалыгында бөтен бер революция ул. "Кырлар патшасы" республика шартларына һәм туфрагына бик яхшы җайлашты. Чөнки татарстанлылар бу эшкә, башка эшләрдәге кебек үк, бик җитди һәм төптән уйлап тотындылар.

Әнә карагыз, үзегез үк ышанырсыз: бүген дә Татарстанда кукуруз "экспанция"се җимешләрен җыялар. Җәй көннәрендә республикабызда булганда кукурузның шаулап үсүенә күңел сөенеп бетә алмый. Карап туйгысыз бит! Кубанлылар һәм украиннар көнләшерлек.

Бүген Татарстанны кукуруз игәргә кем мәҗбүр итә? Хрущев күптән вафат. Табеев Мәскәүдә яши. Хикмәт шунда: татарстанлылар бу культураның файдалы икәнен аңладылар.

1984 елның сентябрендә Н. С. Хрущев Татарстанга безнең кукурузны карарга килде. Мин аны Азнакайга алып бардым. Басуларыбызны күрсәттем. Никита Сергеевич канәгать калды.

- Фикрәт Әхмәтҗанович! Хрущев киткәннән соң, халыкта: Азнакайда әкәмәт эчеш оештырылган, юлбашчы үзен сәер тоткан, дигән имеш-мимешләр йөрде...

- Сафсата ул. Безнең күренекле якташыбыз әйткән: яман телләр пистолеттан куркынычрак. Ышанмасагыз - Азнакайдагы исән шаһитлардан сорагыз соң...

"Беренче" булып эшләгән еллар.

Автордан. Журналист, публицист тормышында җай килеп чыгу - икенче бәхет. КамАЗның 30 еллыгы алдыннан мин "Вечерние Челны" һәм "Вести КамАЗа" газеталарында Фикрәт Әхмәтҗанович Табеев турындагы китап кульязмасыннан өзек бастырган идем. Анда сүз дөньядагы иң зур автомобиль төзү комплексын Кама буенда урнаштыру сәбәпләре, КамАЗ төзелеше беренче көннәре турында бара.

Нәкъ икенче көнне үк Чаллы шәһәр хакимиятенең матбугат үзәгенә - мин нигездә шунда "көн күрәм" - телефон шылтырады. Яшь, көчле хатын-кыз тавышы яңгырады: "Ф. Ә. Табеевның бер көрәштәше, Азнакай районының "Авангард" колхозы рәисе белән очрашып сөйләшәсегез килмиме, заманында Н. С. Хрущев шул колхозга килгән иде бит. Газизулла Хикмәтулла улы Кәрамуллин ул. Мин аның килене Гөлфия Кәрамуллина булам. Хәзер әти Чаллыда бездә кунакта. Ул Ф. Ә. Табеев турындагы китабыгыздан өзекләрне кызыксынып укыды... - Шул көннәрнең бер төп герое белән "очрашасыгыз килмиме" дип бик йомшак әйтелгән. Мондый бәхеткә каләм тоткан теләсә кайсы зат көнләшер иде.

Кәрамуллиннарның яңа буыны Чаллының "Электротехника" дигән кайнап торган җирендә яши икән. Җыйнак кына дүрт бүлмәле фатирда Газизулла абыйның улы Илдар, килене Гөлфия, оныклары Марсель һәм Ләйсән яшәп яталар.

Менә Газизулла Хикмәтуллович үзе. Ул җитмеш өченче яшь белән барса да, гайрәтле, шат күңелле һәм тиз аралашучан булып чыкты. Гадәттәгечә "тел яздырганнан" соң, мин гаилә башлыгыннан туган ягы, үзе, якташлары һәм кичергәннәре турында сөйләвен үтенәм. Минем атаклы әңгәмәдәшем Азнакай районының Югары Стәрле авылында крестьян гаиләсендә туган икән. 1945-1948 елларда "Мелиорация" авыл хуҗалыгы артеленең (соңрак ул Мичурин исемен алган) комсомол

оешмасы секретаре булган. Илленче еллар башында бу тирәдә үзеге Тымытыкта булган яңа район төзелә. 1954-1956 елларда шул ук районда ВЛКСМ райкомының беренче секретаре булып, аннары КПСС райкомы аппаратында эшли. 1962 елның февралендә Тымытык районын бетереп Азнакай районына кушканнан соң аны "Авангард" колхозы рәисе итеп сайлыйлар. Бу колхозга Тымытык, Күктәкә һәм Әгер авыллары керә. Ул чагында Газизулла районда иң яшь хуҗалык җитәкчесе һәм бердәнбер югары белемле зат була.

Газизулла Кәрамуллин кабул итеп алган колхозның социаль һәм икътисадый хәле хөрти. Колхоз казнасы буш, иген уңышы, савым, артым түбән. Клублар, мәктәпләр, хастаханә, медпунктлар, җитештерү биналары тузган, ярым җимерек хәлдә. Халык, аеруча яшьләр, зур һәм тотрыклы эш хакы артыннан нефтьчеләргә китеп беткән. Әлбәттә, сорау килеп баскан: "Алга таба ничек яшәргә?"

1962 елның язында колхозга КПССның Татарстан өлкә комитетының икенче секретаре, авыл хуҗалыгы мәсьәләләре белән шөгыльләнүче Виктор Петрович Никонов килеп төшә. Ул хуҗалык эшләрен һәрьяклап тикшерә. Республиканың, илнең алдынгы хуҗалыклары тәҗрибәсен , әчке хуҗалык исәбен кертү колхозчыларны хезмәтнең ахыргы нәтиҗәләре белән мораль яктан гына түгел, ә матди кызыксындыру алымнарын да куллану мөмкинлекләрен ныклап өйрәнергә киңәш итә.



Ф. Табеев уллары Эльмир һәм Искәндәр белән.

Соңрак хуҗалыкка беренче секретарь Фикърәт Әхмәтҗанович Табеев та килеп йөри башлый. Ул шулай ук барлык эшләрнең төбенә төшә. Тиздән ул колхозга хуҗалык исәбен фәнни һәм гамәли яктан кертергә булышу өчен яшь икътисад фәннәре кандидаты Леонид Михайлович Рабиновичны җибәрә.

Хәлләрнең торышына җентекле анализ ясаганнан соң күп участокларны яшь кадрлар белән ныгыталар. Баш инженер урынына шәһәрдән А. Вәлиев кайта, Е. Сафинны баш агроном, В. Зиннуровны зоотехник һәм комсомол оешмасы секретаре итәләр. Икътисадчы итеп Тымытык МТСының элекке тәҗрибәле белгече Х. Рәшитованы чакыралар, Күктәкә бригадасы бригадиры итеп М. Сабировны билгелиләр.

1963 елдан хуҗалык итүнең икътисадый алымнарына тулысынча күчәләр, тулы күләменә хуҗалык исәбе кертелә. Зур оештыру эшләре башкарыла. Колхозчыларны хезмәтнең ахыргы нәтиҗәләре белән матди кызыксындыруга йөз тоту төп ачкыч була, әлбәттә.

Гамәлгә ашырылган чаралар комплексы "Авангард" колхозының эш нәтиҗәләрендә 1963 ел йомгакларында ук чагыла. Һәр гектардан 20центнер бөртек, 260шар центнер шикәр чөгендере, силос өчен 224 әр центнер кукуруз җыеп алалар. Колхоз дәүләткә 41770центнер ашлык тапшыра. Кергән акчаның гомуми суммасы 1.035.000 сум тәшкил итә. Ул вакытлар өчен бу күрелмәгән казаныш була. Мондый күрсәткечләргә колхоз әле беркайчан да ирешмәгән. Колхоз миллионерга әверелә. Колхозчыларның хезмәтенә түләү арта. Уртача эш хакы көнгә өч сум дүрт тиенгә җитә. Елмаерга ашыкмагыз! Бер кирпеч икмәк 16 тиен торган вакытлар өчен зур акча иде ул. Әле күптән түгел генә колхозчылар хезмәт көненә таякка эшләгәннәрен исәпкә алсак, манзара гомумән дә чагыштырмаслыкка әверелә.

Колхозда берничә йөз мең буш яткан акча пәйда була. Социаль-көнкүреш объектлары төзү, яшәү шартларын яхшырту турында уйлый башлыйлар.

1964 елда "Авангард"та тагын да зуррак уңышларга ирешәләр. Сөт терлекчелеге югары рентабельлегә әверелә. Көнлек савым кайчакларда 16-17 шәр килограммга җитә. Әлбәттә инде, үсемлекчелек барлык колхозчыларның горурлыгына әйләнә.

- Бу саннар белән нәрсә әйтәсем килә? - Әңгәмәдәшем Газизулла Хикмәтуллович игътибар белән минем күзләргә карый. - Н. С. Хрущевның безнең колхозга килүе очраклы булмады. Ул буш урынга килмәде. Башта нефтьчеләр белән очраша һәм берәр авыл хуҗалыгы предприятиесендә булырга тели. Фикърәт Әхмәтҗанович Табеев аны һәм озатып йөрүче кунакларны безнең хуҗалыкка алып килде дә инде...

Без беразга тынып калабыз. Бабасының хикәятенә оныклары игътибар белән колак салалар. Аларга, үзгәртеп корулы сиксәненче елларда туганнарга, болар барысы, һичшиксез, әкият булып күренә.

- Беләсез инде, безнең хуҗалыкта булганнан соң күп тә үтмәде, Никита Сергеевич Хрущев барлык постларыннан азат ителде. Шул вакытта кайбер матбугат органнарында һәм халыкта аның безнең колхозда булуы турында бик күп имеш-мимешләр, хөкүмәт һәм партия башлыгын ямьсез, тискәре кыяфәттә күрсәтүче төрле фикерләр пәйда булды. Чын мәгънәсендә чеп-чи гайбәт алар. Менә ни өчен, кем әйтмешли, исән чагымда ул көннең бөтен хакыйкатен төкми-чәчми сөйләп бирәсем килә.

Мәгълүм булганча, Никита Сергеевич 1964 елның 9 августында самолет белән Казанга килә. Икенче көнне иртән Бөгелмә аэропортына оча. Нефтьчеләр белән очраша. Шул арада аның махсус хөкүмәт поезды Бөгелмә тимер юл станциясенә килеп җитә. Аның вагоннарында хөкүмәтнең ике лимузины була.

Колхоз рәисе буларак мине Н. С. Хрущевның килүе турында алдан кисәтеп куйдылар. Алдагы көнне безнең хуҗалыкта партия өлкә комитетының икенче секретаре Виктор Петрович Никонов булды һәм кунакларны басуда каршы алырга кирәклеген әйтте.

1964 елның җәе һәм көзе яңгырлы булды. Арышны урып-җыю бик авыр бара иде. 10август көнендә дә яңгыр явып үтте. Без белгечләр төркеме белән колхозның "ГАЗ-21" машинасында кырга чыктык. Шундый урынны махсус сайладык ки, бер яктан куе агачлык кебек, киндер плантацияләре җәелеп китә, икенче яктан башакларын тутырып "Харьков-46" бодае басуы җәйрәп ята. Арырак яхшы эшкәртелгән бәрәңге плантацияләре китә.

Яшермим: дәүләт башлыгын каршылау өчен мондый "стратегик" урын сайлавыбыз очраклы түгел иде. Ул чакта киндерне Татарстанда беренче ел безнең колхоз гына

игә башлаган иде. Аның тарихы мондый. 1963 елны мин тоттым да Никита Сергеевичның туган авылына - Курск өлкәсенең Льгов районындагы Калиновка авылына сәфәр чыктым. Хәтерегездә булса, ул чагында анда хуҗалыкны алып бару тәҗрибәсе турында газеталарда күп язалар һәм радиодан сөйлиләр иде. Тикмәгә генә түгел.

Калиновкада мине колхоз рәисе бик җылы каршы алды. Башта ул колхозның искиткеч кунакханәсенә урнаштырды да әйтте:

- Сәфәрдән соң ял итегез. Иртәгә агроном белән зоотехник хуҗалыкны күрсәтерләр. Безнең тәҗрибәне теләгәнчә өйрәнегез. Тәнкыйть фикерләре булса, ихлас күңелдән тыңлаячакмын.

Калиновкадагы колхоз ул көннәрдә данның иң югары ноктасында иде. Һәр җәһәттән. Авылдашлары Хрущевка зур хөрмәт белән карыйлар. Мин анда Калиновканың Хрущев нәселен һәм бәләкәч Никитаны яхшы хәтерләүче бер картын да очраттым әле. Бу карт миңа Хрущевларның элекке утарын күрсәтте. Йорт җимерелгән, утар ташландык хәлдә иде.

Хрущевны барлык постларыннан бушаткач, мин уйлап куйдым: ник ул туган йортын һәм ата-бабасының утарын яңартмады икән? Бу тормышта сораулар күп була шул.

Калиновка карты мине заманында Никита Хрущев дүрт сыйныф тәгәлләгән чиркәү-мәхәллә мәктәбе урынына алып барды. Никита Сергеевич Калиновкадан шушы мәктәптән соң киткән.

Әлбәттә, Хрущев авылындагы колхоздан мин күп нәрсә кабул иттем. Анда үсемлекчелек искиткеч югары дәрәҗәдә иде. Бигрәк тә кукуруз таң калдырды. Киндер дә исне китәрде. Бу - бик файдалы техник культура. Без орлык сатып алдык һәм 1964 елның язында үзебезнең басуларга чәчтек. Ул шундый котырып үсеп китте ки, хәтта Хрущев авылында күргәнемнән дә яхшырак иде. Күрәсең, безнең климат килеште үзенә. Хәер, кешеләребез белеп эшләргә өйрәнгәннәр иде.

"Харьков-46" бодаеның да үзенә күрә бер тарихы бар. Каты сортлы бодай бу. Башта без аны бик аз - орлыклык кына таба алдык. Чәчтек. Ул күрелмәгән уңыш бирде - гектардан 46 центнер. Без дәүләт амбарларына бер бөртеген дә тапшырмадык, алга таба ишәйтергә карар кылдык. Икенче елны да бу каты бодайдан бик югары уңыш җыйдык. Бу юлы без аны үзебезгә файдалы бәя белән районыбыз колхозларына орлыкка сатып җибәрдек. Күргәнегезчә, безнең хуҗалыкта базар икътисады нигезләре алтмышынчы елларда ук салынган иде...

Әгер авылыннан ерак түгел басуда басып торабыз, димәк, һәм дәрәҗәле кунакларны көтәбез. Әгер белән Тымытык арасы алты чакрым. Сәгать унберләрдә ике иләмсез зур лимузин күренә һәм бездән ерак түгел генә туктап кала. Күрәм: беренче машинада шоферы янәшәсендә Фикрәт Әхмәтҗанович Табеев утыра. Икенче ишек ачылып китә һәм аннан Никита Сергеевичның башы күренә. Машинада килгәндә аңа һәммәсен дә алдан ук сөйләп биргәннәр, күрәсең.

- Иптәш Кәрамуллинның бирегә килүен үтенәм, - дип безнең тарафка мөрәҗәгать итә Н. С. Хрущев.

Мин Хрущев машинасы янына килдем, һәм ул миңа кереп утырырга тәкъдим итте. Машина, күз алдына китерәсез булыр, галәмәт зур. Утыргычлар өч рәт. Иң арткы утыргычта өч кеше утыра. Икесен таныдым. Берәвесе КПСС ҮКның авыл хуҗалыгы буенча секретаре Поляков, икенчесе РСФСР Министрлар Советы рәисе урынбасары Ефремов иде. Алар уртасында полковник утыра. Соңрак белдем: ул Н. С. Хрущевның каравыл башлыгы Литовченко булган икән.

Ефремов бер елдан артыграк элек, 1963 елның май ахырында, безнең колхозда булган иде инде. Аңа безнең хуҗалык ошап калган иде. Фикрәт Әхмәтҗанович Табеевның безнең хуҗалыкка бару тәкъдимен Ефремов җөпләгән, күрәсең.

Н. С. Хрущев киткәннән соң күп газеталар: Табеев аны һәм аның көрәштәшләрен Азнакай "Авангард"ына Татарстанның иң яхшы кукурузын күрсәтү өчен алып барды, дип яздылар. Бу бит хакыйкатьнең бер өлеше генә. Кабатлап әйтәм: бездә кукуруз гына түгел, һәммәсе дә: арыш, бодай, борчак, чөгендер яхшы үсә иде. Хрущев килгәнче безнең хуҗалыкта КПСС ҮК, СССР һәм РСФСР Министрлар Советлары хезмәткәрләре булып киткәннәр иде. Киткәндә алар бер генә сүзне кабатладылар: "Кубан". Мәсәлән, чөгендерне без Татарстанда беренчеләрдән булып игә башладык һәм аның файдасын шундук аңлап алдык. Бер яктан, ул - терлек азыгына саллы өстәмә. Икенче яктан, без чөгендерне Зәй шикәр заводына тапшырып шактый акча ала алдык. Ә кукурузның без районлаштырылган сортларын гына чәчкән идек. Ул яшь урман кебек үсте...

Басуда очрашканнан соң, без үзәк утарга, Тымытыкка юл алдык. Барганда Хрущев мине сораулар белән күмеп ташлады. Башта ук искәртергә тиешмен: Никита Сергеевич авыл хуҗалыгы җитештерүе һәм авыл тормышы мәсьәләләрен бөтен тулылыгы белән белә иде. Хәтерегездәдер, 1964 елның апрелендә аңа 70 яшь тулган иде. Ул чакта миңа, яшь кешегә, ул инде карт булып күренгән иде. Ләкин ул нык һәм ихтыярлы карт иде. Бу аның кул селтәүләрендә, әңгәмә коруында сизелеп тора иде. Юлда барганда ул мине "йөдәтеп бетерде": колхоз ни белән шөгыльләнә, нинди уңыш җыябыз, терлекләр күпме артым бирә. Колхозда җәмгысе күпме кеше яши, күпмесе эшли. Фикрәт Әхмәтҗанович Табеев та юнәлткеч сораулар биргәләп барды.

Н. С. Хрущевның түбәндәге сораулары бигрәк тә хәтергә кереп калды:

- Авылларда нинди милләт вәкилләре яши? - дип сорый дәүләт башлыгы.

- Татарлар, - дип җавап бирәм мин. - Йөз процент татарлар.

- Ә мәктәптә балаларны нинди телдә укытасыз? - дип төпченә Н. С. Хрущев.

- Тулысынча татар телендә, - дип җавап бирүне дәвам иттерәм.

- Искиткеч бит бу! - дип Никита Сергеевич баш бармагы белән һава яра. - Һәр халык үзенең телен, мәдәниятен һәм тарихын белергә тиеш...

Моның белән нәрсә әйтәсем килә? Хрущев заманында үзәк хакимиятләр милли республика һәм өлкәләрдә һәркайда милли мәктәпләрне ябып бетерделәр, дип һәрдаим тукып торалар. Ялган бу! Аларны Хрущев та, Табеев та түгел, ә урыннардагы ялагай түрә туганнарыбыз япты. Мин үз җилкәмдә татыган кеше: җирле түрәләр стихияле бәла-казадан да куркынычрак. Алар үзәк күрсәтмәсен шашынып үтәү һәм арттырып үтәү өчен маңгайларын бәреп ярырга әзерләр. Хәтергә төшерегез: сугыштан соң халыктан салым җыю җәһәтеннән Татарстанда ниләр генә кыланмадылар! Җирле түрәләрнең мәктәпләрне нинди хәлдә калдыруларын искә төшерү дә куркыныч. Татар мәктәпләренә йөреп аларны Хрущев



белән Табеев рус теленә күчерделәрме әллә? Моны үзебезнең хорәсән "туган" түрәләребез эшләде...

Үзәк утар ягына ашыкмый гына барабыз, димәк, әңгәмә корабыз. Көн болытлы булып әбәткә хәтле яңгыр явып узганга күрә, кешеләр ул көнне кырда эшләмәделәр. Күпләр колхоз идарәсе янындагы мәйданга җыелган. Хәтта Ык аръягыннан, Башкортстаннан да күршеләр килгән иде дәрәҗәле кунакларны күрергә. Без алдагы көнне зур чәк-чәк пешереп аны Хрущевка очрашу вакытында тапшырырга ниятләгән идек. Моны авыл аксакалы Сабир бабай һәм Гөлфия атлы кыз эшләргә тиешләр иде.

Җыелган кешеләргә якынлаша башлагач, сак башлыгы полковник Хрущевка мөрәҗәгать итә:

– Туктарга киңәш итмим...

Тукталыш графикта каралмаган булган, күрәсең. Юлбашчы һәм аны озатып йөрүче затлар тукталмыйча басулар тарафына китеп бардылар. Турысын әйтим: моңа бик тә үкендем мин. Әлегә хәтле үкенәм. Ихластыр менә, Хрущевның бу гамәлен бүгенге көнгә кадәр аңлый һәм үземә аңлата алмыйм. Халык янында ун минутка гына туктап алса, я, ни булас.

(Дәвамы бар)

Р. Галиев фотосы.

С. Исхаков фотолары.

Кардан ап-ак челтәр үргән
Кыш хәтта тәрәзәгә.
Сылу каеннар төренгән
Көмешсу пәрәвезгә.

Җил кагылса агачлардан
Коела энҗе - җәүһәр...
Февраль абзый черем итә
Яз кояшына кадәр.



А. Титов фотосы.

ТАТАРСТАН 80

Тормыш белән бергә үзгәргән

Бу елның декабрь аенда "Татарстан" журналының чыга башлавына 80 ел тула. Журналыбызның тарихы бай да, шул ук вакытта каршылыклы да. Ул дистәләрчә еллар буе республикабыз коммунистларының төп журналы булып торган. Ләкин, ни генә булмасын, безнең үз тарихыбыздан баш тартырга хакыбыз юк. Безнең журнал - илебез, халкыбыз, республикабыз узган сикәлтәле юлның бер көзгесе.

Олы юбилей уңаеннан укучыларыбыз игътибарына "Татарстан"ның үткәненә багышланган язмалар циклы тәкъдим итәбез.

Егерменче еллар башы - гражданнар сугышында җиңеп чыккан большевикларның илдә берпартиялелек урнаштыруы, идеологик максатларда вакытлы матбугатның коммунистик режимга хезмәт итәчәк системасы барлыкка килә башлау чоры. Татарстан автономияле республикасы төзелгән вакыт та ул. Республика коммунистларының үз вакытлы матбугатын, шул исәптән иҗтимагый-сәяси журналларын булдыру ихтыяҗы туа. Мондый журнал үзенең башлангыч чорында рус телендә "Вестник Татарского областного комитета РКП(б)" (1920-1921), "Спутник агитатора" (1921), "Коммунистический путь" (1921-1925), "Путь Ильича" (1925), "Причал" (1925), "Спутник партийного активиста" (1926-1927) дигән исемнәрдә нәшер ителә.

Татар телендә мондый төр иҗтимагый-сәяси басманың тарихын 1922 елда оештырылган "Безнең юл" журналына китереп терәү дөрес булыр. Ә 1926 елдан партия пропагандасы өлкәсендә "Безнең юл" үтәгән бурычлар яңа оештырылган "Җитәкче" журналына йөкләнә. 1932 елда аның исеме "Татарстан большевигы" дип үзгәртелә. 1935 елдан алып, ул "Татарстан коммунисты" дигән исем белән ике телдә чыга.

Исемнәрнең үзгәрүе гади "вывеска алыштыру" гына түгел, ә журналның эчтәлеге һәм төзелеше үзгәрүе белән бергә бара. Журналның югарыда исемнәре атап кителгән барлык вариантлары да иҗтимагый-сәяси эчтәлекле. Ләкин алар һәммәсе дә турыдан-туры партия басмалары гына түгел. "Путь Ильича" һәм "Причал" партия мәсьәләләрен яктыртучы теоретик журналдан да битәр, киң массаларга юнәлдерелгән популяр журналлар буларак танылалар.

Укучыларга гыйльми-сәяси, әдәби-иҗтимагый айлык журнал итеп тәкъдим ителгән "Безнең юл" үзенең беренче елларында ("Җитәкче" чыга башлаганчы) партия сүзен матур әдәбият белән берләштерүче басма була: һәм партия журналы, һәм әдәби журнал вазыйфаларын үти. Иҗтимагый-сәяси мәсьәләләргә игътибар зурдан булып, аларны яктырткан мәкаләләр журналның түр урынын - беренче өлешен билиләр. Ленинизм идеяләрен пропагандалау, партия тәгълиматын, карарларын, көн үзәгендәге бурычларны халык аңына җиткерү күздә тотыла. Партия журналына хас башка темалар: совет төзелеше, профсоюзлар тор-

мышы һ.б. да читтә калмый. (Әдәби әсәрләр нәшер итүе, әдәби-гыйльми тикшеренүләр алып баруы ягыннан "Безнең юл" "Казан утлары" журналының да нигез ташларын салучы басма буларак билгеле.)

"Вестник Татарского областного комитета РКП(б)"ны партия төзелеше журналы дип билгеләргә була. Аның иң мөһим бурычларыннан берсе буларак, журналның 1920 елда чыккан беренче санында билгеләп үтелгәнчә, "партия төзелеше һәм партияне сәламәтләндерү буенча дискуссия ачып җибәрү" игълан ителә. "Спутник агитатора"ның максаты 1921 елны чыккан беренче санында "агитация-пропаганда мәсьәләләрен яктырту" буларак билгеләнә. Анда методик характердагы язмалар күпчелекне тәшкил итә. 1921 елның бишенче-алтынчы берләштерелгән саннарыннан башлап "Коммунистический путь" булып үзгәргән журналның эчтәлеге тирәнәя бара: ул сәясәт һәм икътисад проблемалары, марксизм мәсьәләләре, агитация-пропаганда белән шөгыльләнүче киң тематикалы, чоры өчен бай эчтәлекле басмага әйләнә. Журналның үз йөзе, төзелеше, рубрикалар системасы барлыкка килә. Шуңа күрә бу исем астында чыккан чорны журнал тарихындагы мөһим этап буларак билгеләп узарга кирәк.

"Спутник партийного активиста", "Җитәкче" һәм "Татарстан большевигы" - партиянең эчке тормышын, аның оештыру һәм идеологик эшчәнлеге мәсьәләләрен яктыртучы, урыннардагы партия оешмаларына җитәкчелек итү, сәяси-тәрбияви эшләрне оештыру вазыйфаларын башкаручы органнар була.

1958 елдан нәшер ителә башлаган "Татарстан коммунисты" журналы үз элгәрләре тарафыннан тупланган тәҗрибә һәм традицияләрне эшкә җикте. Ул идеология, марксизм-ленинизм теориясе һәм практикасы кебек теоретик мәсьәләләрне генә түгел, республика тормышының төрле якларын яктыртучы киң тематикалы абруйлы журнал булып танылды. "Татарстан коммунисты" республикабыз халык хуҗалыгы үсешенең үзенчәлекле бер елъязмасына әверелде. Әйтик, анда Кама автомобиль заводы төзелешенең барлык мөһим этаплары киң чагылыш тапты. Журнал милли мәсьәләләрне яктыртудан да читтә калмады.

Авторлар буларак журналистлар гына түгел, партия һәм совет органнарында эшләүчеләр, юристлар һәм профсоюз активистлары чыгыш ясады, күренекле гыйлем ияләре үзләренең иң җитди мәкаләләрен биредә бастырды.

Дөрес, партия өлкә комитеты органы булу һәм башка барлык газета-журналлар кебек, идеологик кысалар эчендә яшәү журнал эчтәлегенең, тоткан кыйбласының берьяклы гына булуына китерде. Ләкин шундый шартларда да анда халыкны борчыган проблемаларны яктыртуга, полемика-бәхәсләр, җитди тәнкыйтькә урын һәрчак булды.

Иҗтимагый тормышка кискен үзгәрешләр алып килгән сиксәненче еллар азагы "Татарстан коммунисты" өчен дә яңарыш һәм эзләнүләр чоры булды. Журналның исемен "Татарстан" дип үзгәртү аның эчтәлеген яңарту җәһәтеннән дә зур яңалыклар алып килде: анда республикабызның сәяси һәм икътисадый тормышын, фән һәм мәдәниятне, халкыбыз тарихын яктыртуга, аның рухи мирасы белән таныштыруга юнәлгән язмалар урын ала башлады. Журнал суверенлык һәм милли яңарыш өчен көрәшнең дә алгы сызыгында атлады. Яңа йөзен эзләү чорында "Татарстан", республикабыз тормышы һәм анда яшәүче халыклар турында дөрес һәм тулы мәгълүмат бирүче басма булырга омтылу сәбәпле, тематик яктан үзен артык чикләмәде.

Һәм менә 1998 елның дүртенче саныннан башлап укучы игътибарына "Татарстан" журналының гамәлгә яңача куелган төре тәкъдим ителде. Бүген ул - полиграфик яктан югары сыйфатлы, төсле итеп эшләнгән, эчтәлеге ягыннан республикабыз тормышының барлык мәсьәләләрен күтәреп чыгучы, авторлар буларак иң абруйлы сәясәтче һәм икътисадчыларны, галим һәм язучыларны үзенә тартучы иҗтимагый-сәяси, һәм мәдәни журнал. Президентыбыз Минтимер Шәймиев әйтмешли, "Татарстанның визит карточкасы".

"Татарстан" милләт язмышы, дәүләти һәм милли идеология, милли мәгърифәт-мәдәният темаларын үзәккә куя. Гыйльми һәм фәнни-публицистик мәкаләләр ярдәмендә сәяси, социаль, икътисадый мәсьәләләр тикшерелә; мәдәни тормыш манзарасы бирелә. Журнал республикабызның абруе турында да кайгырта. Татарстанның үзен дөньяга таныту, чит мәмләкәтләр белән турыдан-туры багланышлар мәсьәләсе куела.

Мәсьәләләрне шулай теоретик яссылыкта кую хәзерге "Татарстан"ның үзеннән алда чыгып килгән иҗтимагый-сәяси, фәнни-теоретик басмалар белән бәйләнешен, дәвамчанлыгын күрсәтә. Шуның белән бергә, "Татарстан" - киң укучылар катламына юнәлтелгән басма да. Бу исә үз чиратында иншалау алымнарының башка төрләрен кулланырга этәрә. "Татарстан" сәхифәләрен аналитик төстәге язмалар белән аралашып баручы интервью, сурәтләмә, фоторепортажлар да бизи.

Журналның күпчелек саны "Хисияте миллия" исемле махсус кушымта белән баетылып чыга.

Сиксән яшьлек "Татарстан"га матур киләчәк насыйп булсын иде. Аның киләчәге, һичшиксез, Татарстаныбызныкы кебек үк, якты һәм матур булыр дип ышанасы килә.

Мөнҗия МӘРДИЕВА,
Казан дәүләт университетының татар журналистикасы кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты.

Казансу буендагы Бәйтулла-йорт

Таныш булыгыз:

Шамил Габдулла улы ИСХАКОВ - хезмәт ветераны, "Казан нуры" мәчете мөтәвәллияте рәисе, Татарстанның атказанган транспорт хезмәткәре



Без бәләкәч чакларда Казансу тирәсе яшел җәйләү иде әле. Әүвәлдә илтотар егетләрнең аргамаклары утлап йөргәндер анда. Казан ханлыгының чәчәк аткан чорлары булган бит. Соңрак инде сәйранда чегәннәр мәж килде. Тирә-як шуларның чатырлары, ала-кола атлары белән тулды.

Кызык иде шулай да!..

Заман Казансу буйларын нык үзгәртте. Әлеге биш-алты ел эчендә генә дә болынга таба, Савиново бистәсен йотып, биек-биек ташпулатлар җәелде. Биредә, яңа йортларда яшәүчеләрне сөендереп, архитектура һимматенә ия булырлык мәһабәт бина - Аллаһының Бәйтулла йорты калкып чыкты. Биек манарадан һәр көнне биш вакыт намазга чакырып мәэзиннең Азан тавышы яңгырый. Бик тә таныш тавыш хәзер бу миңа...

- "Түрәнең әтисеннән интервью алырга килгән", димәсеннәр тагын. Әйдәгез әле, Шамил абзый, каракаршы утырып, бер рәхәтләнеп гәпләшик булмаса.

- Журналистлар белән очрашырлык батырлык эшләгән юк анысы (кеткелдәп көлә). Шулай да фикерле инсаннар белән утыру үзе җан рәхәте. Нәрсәдән башлыйк икән соң?

- Бәлки, Сезнең шәҗәрәдәндер.

- Менә бит, сезнең халык уптым китереп тери стенага. Өлкәннәрдән җиде буынымны белеп кала алмадым шул. Нәселебезнең соңгыларын саклап калу өчен көрәштек, үлем белән яшәү арасында көн күрдек. Рәхмәт Камил улыма, фамилиябезгә нигез салган бабабызны ачыклап бирде.

- Ничек булды ул?

- Архивларда кайбер документсәнәтләр сакланган. Татарстандагы Татар Казысы дигән авылны ишетә беләсеңме?

- Ничек кенә әле. Казаннан ни бары 55-60 чакырымда, Питрәч районына керә.

- Үземнең барып күргәнем юкюгын. Чишмәбашыбыз менә шул Татар Казысына барып тоташа. Анда Ишимьяр атлы олуг имам-хәзрәт яшәгән. Даны еракларга таралган. Уллары да дин юлыннан киткән. Исхак исемлесе - минем Ибраһим бабамның әтисе, фамилиябезгә нигез салучы.

- Татар Казысы алайса, Шамил абзый! Минем үземнең дә кайбер тамырларым шул салага барып тоташа бит. Әтиемнең апасы кияүгә чыккан авыл. Әни ягыннан да туганлык җепләре саклана. Бәләкәй чакта кунакка бара торган идем. Хатирәләрем бихисап. Татар Казысы белән мин туган Шикнәү Чирмешәнен Олы Солтан авылы гына аерып тора. Уку йортыбыз уртак - Олы Солтан урта мәктәбе иде.

И-и, ул Татар Казысының матурлыгы без дөнья белән танышып йөргән чакларда! Атау урамы дип йөртелгәне аеруча ямьле, гел яшеллектән генә тора. Хәтфә чирәм түшәлгән ул урамда хәтта арба эзе дә беленмни. Ә кичләрен... Ике чакрымга сузылган төз авыл проспектының йорт алларында зур-зур өянкеләр үсеп утыра. Кичке эңгердә әнә шул үзара тоташа язган өянкеләр арасыннан күктә ак юл пәйда була. Гаҗәеп манзара! Ә Атау дигәнебез, авыл башындагы биек түгәрәк таулар. Менә шул тауларның берсеннән бүрәнәдәй юан булып салкын чишмә аттыра. Чын мәгънәсендә шулай. Шифасын әйтеп торасы да юк - тамак бакасын (зоб авыруын) дәвалый. Ни кызганыч, безнең көннәрдә, су торбалары уткәрәбез дип, җирне бораулаганнар. Техника җене сирпелгән изге чишмәнең суы юкка чыккан, юлын үзгәрткән, күрәсең. Атауның даны кимегән хәзер.

Ә халкы дисәгез, чат инсафлы, тәкъва кешеләр яшәде Татар Казысында. Шул авыл егете, дустым Зөфәр Хәйретдинов радио-телевизордан җырлый башласа, авылның элеккеге гүзәллеге күз алдыма килеп баса. "Куралардан җил үткән" икән шул инде... Шуңа сөйләвем, Шамил абзый, изге төбәктә затлы нәселдән чыккансыз икән бит. Бәлки, туганлык җепләре дә бардыр әле безнең арада. Мин үзем дә ишан-хәзрәт авылыннан.

- Белмәссең...

- Сүзегезне бүлдем.

- Ибраһим бабайны сөйли идем. Ата-бабасыннан зур гыйлемлек алып, махсус мәдрәсә тәмамлаган бабамны Иске Йорт авылына мулла итеп җибәрәләр.

- Күрше авылгамы?

- Юк, Арча районындагы Иске Йортка.

- Бу исемне Питрәч, Кукмара, Спас районнарындагы кайбер авыллар да йөртә - шуны ачыклавым.

- Гаҗәеп шәхес минем бабам. Бөтен гомерен укуга, камилләшүгә сарыф итә. 81 яшендә Гөберчәк авылы мулласының бик матур Сәйдә исемле кызына - минем булачак әбиемә өйләнә. Әбигә ул чакта 18 яшь (81-18) була. Үзе разый булып чыга. Бабайга бер кыз, ике углан бүләк итә. Кечесе - минем әти, Габдулла. Ә әбиебез 25 яшендә инде, нарасыйларын калдырып, бу фани дөньядан китеп тә бара. Сәбәбе билгесез.

Ятимлек ачысын күп татырга туры килә әтигә. Ул бабайдан соң Иске Йортта муллалык иткән Фәрит хәзрәттә асрамада үсә. Фәрит бабай - Казан казые (хәзергечә судья), мәгълүм шәхес Хәсәнгата Габәшинең энесе була.

- Шулай ук зыялы нәсел.

- Әйтерең бармы. Тәүге композиторларыбызнең берсе Солтан (тулы исеме Солтанхан) Габәшинe искә алу да җитәдер. Хәсәнгата абзыйның гаиләсе, барлык балалары минем әтине "абый" дип йөртәләр иде. Кызлары Оркыя, Суфия апалар бик ягымлылар иде. Суфия апаның улын үзегез дә беләсездер, Шәүкәт Якупов партия өлкә комитетында эшләде, ике телдә - русча, татарча лекцияләр укыды.

Габәшиләр гаиләсендә тәрбияләнгән әтиебез дә бик мәгълүматлы кеше иде. Шулай берзаман Суфия апа туганының килене Диләрә шылтырата. Ул Казан дәүләт университеты китапханәсендә эшли. "Шамил абый, бер килеп чык әле. Безнең архивта Габдулла абыйның хатлары ята", - ди бу. Әтием теге сикәлтәле елларда ук Хәсәнгата абзый белән хатлар алышып яшәгән. Билгеле сәбәпләр нәтиҗәсендә хатларның сәяси әһәмияте ул тиклем зур булмаса да гаиләбез өчен бик мөһим шул.

Мин үзем әти тәрбиясен күрдем, дип мактана алмыйм. Киресенчә, "мулла нәселе" дигән мөһернең ачысын татып яшәргә туры килде. Кулак дип авылдан сөрделәр. Башта таладылар, контрибуция белән изаладылар. Барысы да күз алдымда. Без ул чакта Әтнә районының Ябынчы авылында яши идек. Пүнәтәйләр көндезен дә, төнен дә тынгы бирмәде - нидер эзләделәр, соңгы пудаука оныбызны себереп алып чыктылар. Әтигә генә түгел, әнигә дә көн булмады. Ул - Урта Бирәзәнең Хәмзә бай (байлыгы ташка үлчим инде) кызы - шуны сәбәп итеп бәйләнделәр.

Авылдан киткәндә бер сандык чүпрәк-чапракны җыеп, әтинең Иске Йорттагы абыйсына калдырдык. Имеш, дөнья хәлен белеп булмый, аннан да колак кагуыбыз бар. Бер кат кием белән Себер тарафына кузгалдык. Әмма ерак китә алмадык, Кама буендагы Сарапул шәһәрендә туктап калдык.

- Күз алдына китерәм андагы "эшче сыйныфны". Яшьлегемдә үзем дә эшләдем ул якларда, Красный бор дигән районда. Редакциядә. Сезнең кебек ристаннар булып түгел түгелен. Үпкәләмә тагын, Шамил абзый, алай дигәнгә.

- Дөресе шулай ич, Госман. Ристаннар рәтендә йөрдек. Ашарга ризык, кияргә кием булмады. Бер ел яшәдек. Иген уңмады ул елны. Ачлык таралды. Әти өченче җиргә күчәргә ниятләде. Безне вакытлыча туган якларга кайтарып торырга дигән карарга килде. Терлек вагоннарында ачлы-туклы, суыктан кал-

Ягез, бер дога!..

хәтергә төшердем. Шулай үстек инде.

... Сугыш елларында хәрби заводта эшләдем. Самолет ясадык. Читлек эчендә тотылган конструктор С. П. Туполев янында. Михнәтләргә чыдый алмыйча сугышка җибәрүләрен сорадым. Рөхсәт итмәделәр. "Облава" вакытында өч тапкыр комендатурада булдым. Кире заводка кайтардылар.

● - Кызык кына килеп чыга бит әле монда, Шамил абзый. Мин өченче мәртәбә сезнең эзгә басам түгелме соң?! 22 нче заводта эшләгәнсез, мин күршедәге 16 нчыда, моторлар ясый торганында. Ул чорда п/я 735 дип аталды. Ә аңарчы, малай чакта, Казандагы иң яхшы заводларның берсендә, теш дәвалау инструментлары ясый торган предприятиедә эшли идем. Берзаман халыкара күләмдә салкын сугыш кызып китте. Шашынып кораллану башланды. Шушы ике заводка эшче гавәмне күпләп җыйдылар. Горький (Түбән Новгород), Молотов (Пермь) шәһәрләреннән дә икешәр-өчәр мең эшчене ихтыяри-мәҗбүри рәвештә Казанга күчерделәр. Җиле миңа да кагылды. Сәбәбе бар иде. Җыелышларда чәчрәп чыгучы коммунист-токарь Геркинны (фамилиясе әле дә хәтердә), мине - комсомолец-фрезерчыны, "Кызыл Татарстан" газетында түрәләр турында фельетон язып бастыручыны һәм... бүрекләр карагы (ул чакта да бар иде андыйлар) Барыевны бик әйбәтләп кенә, "партия өлкә комитеты карары нигезендә" дигән сылтау табып, шушы заводка очырдылар. Шуннан соң инде мин теге яки бу урынга гел өлкә комитет карары яки юлламасы белән генә күчерелә торган "шөрепкә" әйләндем. Хезмәт кенәгәмдә барысы да язылган. Үземне кыстырып бу заводны шуңа искә алуым, анда көн-төн өч сменада чиләндек, яңа төр ТУ-124 самолетларын ясадык. Станок артында һуштан язучылар да булды. Аңлыйм мин сезнең сугыш елларындагы хәлне.

- Шуңа да заводтан китеп, шоферлык һөнәрен үзләштердем. Берниндн бәла-казасыз 54 ел буе көпчәкләр өстендә йөрдем. Башта "Татлеспромсбыт" дигән оешмада, аннары тегүчеләрнең һөнәр мәктәбендә йөк машинасында эшләдем.

● - Савиново бистәсе, дисәләр, Исхаковлар күз алдына килеп баса. Берәр төрле аңлатмасы бардыр инде моның.

- Юк аңлатмасы. Островский урамындагы икегә бүленгән кечкенә генә бер фатирда яшәдек. Дүрт бала. Ул арада сеңел белән кияве дә өстәлде. Кешене урамда, кышкы сарайда калдырып булмый ич. Үз туганнарыңны. Сыйдырдык үзләрен. Кысанлык турында сөйләп торырга кирәкмидер, минемчә. Безнең хәлне эшемдә дә күрәләр, беләләр, кызганалар. Начальнигыбыз чакырып алды да әйтә бер көнне:

- Фатирга өмет юк, Исхаков,

тырап йөрүләребезне искә төшерәм дә тәнемә каз тәкләре бәреп чыга. Ходавәндә! Кулак качып кайткан дип, этине янә кулга алып, чын Себергә, Омскигамы, Томскигамы җибәрделәр. Булды бит шундый хәлләр. Каторжаннар арасында ике ел утырып кайтты.

Әйтергә онытып торам икән. Өебездән ат сарае ясаганнар иде безнең. Банат апаларга өйдәш булып кердек. Әти кайткач, иске өйне сүтеп, өч ярымга - өч ярым итеп бер торак әмәлләде. Өйгә мал керсен дип, Иске Йорттагы теге абыебыздан кәҗә тәкәсе алып кайттык. Савымын бирә алмадылар. Хикмәти хода, шул тәкә артыннан авылның ярты көтүе ияреп кайта башламасынмы! Ә-ә, байның малы бетмәгән икән әле дип, әни белән апаның борчак чабып алган ике капчык ашлыгыбызны алып чыгып киттеләр. Без бит дүрт бала: апам Мәрьям, мин, сеңелләрем Дөрья белән Мөдәббирә. Пушкин хәзрәтләре әйтмешли, тагын ярык тагарак алдында калдык.

Без тәкә белән сөзешеп яшәгән арада әти, Казанга барып, эшкә урнаша. Микробиология институтына атлар караучы булып. Кабан күле буендагы Әхтәмов урамында берәүләргә фатирга кергән. Әни белән икәүләп килеп төшкәндә әти ишеген бикләп тора иде. Күчтәнәч йомыркаларны сатырга дип, безне Чехов базарына алып менеп китте. Үзе эшенә йөгерде. Урлаттык без ул йомыркаларны. Әнигә утырып елаудан башка чара калмады. Мин аны кызганып еладым.

Туктале, нәрсәләр сөйлим соң мин. Кемгә кызык бу?! Ул заманнарда кайсыбызга җиңел булгандыр? Йөрәккә сеңеп калганнарны

Гаилә архивыннан. Сөекле кәҗәбез бар иде.

әллә үзең әмәллисеңме? - ди бу.

- Кесәм такыр, - дим.

- Анысына гына булышырбыз, - дип вәгъдә итте.

Савиново бистәсенә менә шулай килеп эләктек. Буш урын юнәтеп, өчкә-дүрт метр зурлыгында "сипушка", ягъни ике такта арасына пычкы чүбе тутырып, өйсыман нәрсә әмәлләп кердек. Кысанлык барыбер калды. Балалар үсә башлады. Шуннан соң йортны 6 да 7 гә шлак-бетоннан җиткердем. Иркенрәк сулыш алдык. Хәер, бу кадәресе безгә генә түгел, Дары, Җиләкле, Кәҗә бистәләрендә яшәүчеләргә дә хас-тыр. Әйттем бит, хикәятем кызык булмас дип.

- Ә нәрсә кызык соң?

- Бәлки буйдаклыгым, гаиләмнең икегә бүленүедер...

- Ну, даешь, Шамил абзый, кем әйтмешли.

- Бер дә ишетмәдеңмени анысын?

- Мине гайбәт кызыксындырмый.

- Уйдырма түгел, чын хакыйкать бу. Тугыз ел бер ялгызым яшәдем. Моңа диндарлыгым сәбәп булгандыр дип саныйм. Син уйлама тагын, болар үзара бозылышып беткән икән, дип. Беренче җәмәгатем белән дус булып калдым. Балаларны бергәләп үстердек. Хәзер дә йөрешәбез. Балалар да, "әтием", "әнием", дип өзелеп торалар. Рәхмәт үзләренә, безне аңладылар.

- Тугыз саны, аннары "хәзер дә йөрешәбез" дигән сүзләрдә ниндидер сер ята сыман. Яшь бичәгә ишарә түгелдер ич?

- Ишарә шул. Ялгызым озак яшәдем. Тәрбия кирәк була башлады. Бер ялгыз хатын белән таныштырдылар. Якташ икән үзе, җитмәсә, Арча районының Урта Бирәзә авылыннан. Ирсез калгач, Казанга килеп урнашкан, бер ялгыз карчыкны тәрбияләп торган. Иске булса да йортын шул хатынга яздырган. Карчык үлгәч, янына мин дә күчеп килдем. Тузган өйне сүтеп, яңасын җиткердек. Хәзер инде коммуналь фатирда торабыз.

- Ике бичә бик татулар, - дип кеткелди Шамил абзый. Аннары дәвам итте: - Диндарлыгымны әйткән идем бит. Аллага шөкер, иртәнге намазсыз эшкә чыгып китмәдем. Арып кайттым дип, әгүзе-бисмилласыз йокларга ятмадым. Кичен ястү намазына кайтып

Гаилә архивыннан. Уллары Наил (сулдан), Шамил абзый, Габдрәшит, Рәшидә белән Камил.

өлгерә идем. Ә казага калган көндезгеләрен ястүдән соң җыеп укыдым. Аллаһы Тәгалә үзе кабул итсен. Госелсез йөрмәдем.

- Балалар тәрбиясе турында сезнең фикерне ишетәсе килә, Шамил абзый.

- Бу мәсьәләләрдә мин әниләренә бик рәхмәтле. Балаларымны ясле-бакча тәрбиясенә бирмәдем. Үземә авырлык килсә дә, әниләрен эшләтмәдем. Кечкенәләребезне ул тәрбияләде. Йомшак күңелле булсам да, балаларга карата таләпчән идем. Татар мәктәпләре бетерелгәнлектән, рус мәктәбендә укыдылар. Ә өйдә гел татарча сөйләштек.

Кичләрен эштән кайтып керәм шулай. Тышкы ишекне ябып, әчкесен аз гына ачып, сөйләшүләренә колак салам. Дәрес хәзерләүче оланнар үзара русчага кереп китәләр бит. Шуннан әйтәм инде: "Барыгыз әле, балалар, бераз уйнап керегез, урамда туйганчы русча сөйләшегез. Өйдә татарча кирәк", - дим. Аңлыйлар үзләренең гаепләрен. Кергәч ник бер рус сүзе ишетелсен. Тыңлаучан булып үстеләр.

Азып-тузып йөрүче балалар хакында сүз чыккач, аның тамырына бәя биреп, бер фикерле дустым гыйбрәтле мисал китерде. Ферма сарыкларының көтүдән кайтканын күргәнең бармы, ди бу. Күргәнем бар, минәйтәм, әмма сынап күзәткәнем юк. Шул мәлдә машина белән авылга җибәрделәр үземне. Теге дустымның сүзләренә ачыклык кертергә омтылып, күзәтәм көтү кайтуын. Хуҗалык сарыклары томырылып кайталар да капкадан атылып кереп китәләр. Ә ферманыкылар капка төбе саен туктап, кычкырып, анда-монда сугылып узалар. Аңладым дустымның фикерен. Шуңа күрә балаларымнан ферма сарыклары ясамадым, ясле-бакча язмышына тапшырмадым. Сиңа аңлашылдымы соң, Госман?

- Дустыгыз чыннан да акыллы инсан икән.

- Тиешле тәрбия юк хәзер балаларга. Шуңа азыналар.

- Улыгыз башкалабыз мэры...

- Әйе, Камилем үз урынын тапты. Шәкерт кенә иде әле. Гел "бишле"гә укыды. Җәмәгать эшендә актив катнашты. Университетның өченче курс студентын Татарстан халык депутаты итеп сайладылар. Арттан этүчебез булмады, үзен-үзе үстерде.

Бүгенгегә килеп нәрсә әйтә алам? Казаныбыз еллап түгел, айлап, көнләп үсә, матурлана. Тузган торак бетеп бара. Моны мин үз тормышымда ук сиздем. Улым халык өчен тырыша. Шуңадыр инде үзен дә хөрмәт итәләр. Әти-әни өчен моннан да зур куаныч булмыйдыр ул.

- Шамил абзый, менә сез хәзер баштанаяк дин юлына баскан кеше. Үзегез салдырган "Казан нуры" мәчетендә эшлисез. Аллаһы Тәгаләнең берлегенә инанасыз. Ә җен дигән зәхмәтне күргәнегез бармы?

- Җен булмады бугай ул. Шулай бервакыт, кичке эңгердә каядыр ба-

рырга чыктым. Борчылган чагым иде. Үзең дә хәтерлисеңдер, хәзерге Химиклар сарае бакчасы итәгеннән инеш ага иде элегрәк. Шуңа килеп җиткәч, кайданрак кичәргә икән дип баш ватып торганда янәшәмдә бер кеше пәйда булды. Аның белән бергәләп кичтек. Нидер уйлап барам һаман. Күз алларым яктырып, фикерем ачыкланып китте бер заман. Игътибар итсәм - янымдагы юлдашымны күрмәдем. Юк, җен түгел иде ул. Бу хакта сөйлисем килми, гөнаһлы булудан куркам.

Әңгәмәбез шушы төшкә җиткәч, мәчет алдына кияү белән кәләш, аларның дуслары төялеп машиналар килеп туктады. ЗАГСтан соң мәчеттә никахлашырга ниятләгәннәр. Элек юк иде бит мондый гадәт. Казансу күпере тирәсендәге ветеринария институты бакчасында бер кулларына хәмер, икенчесенә дуңгыз колбасасы тоткан яшьләрне күреп йөрәк әрни иде. Димәк, калебләре сафлана, иман керә балаларыбызга. Әңгәмәдәшем Шамил абзый да куануын белдерде яшьләрнең бу гамәленә.

- Аерылышулар күп шул әле.

- Сәбәпләре дә күптөрле бит, Госман. Фаҗиганең башы имансызлыкта. Яшьләребезгә иман иңдерергә кирәк. Берәүнең ире эчкече, юньсез була. Икенчесенең хатыны бозык. Ә син бозык хатынны кеше итәм димә - аның җанына җен кереп оялаган була инде. Җен - бозыклыкның дусты. Шуңа аерылышалар.

Үзсүзле, кире беткән хатыны белән аерылышкан икенче бер танышым зарланды. "Юк инде кеше итә алмадым, ахрысы. Тырышлыгым туң агачка балта чабуга тиң, каптыра алмадым балтамны, чәчрәп кулдан ук ычкынды", - диде. Аның сүзләрендә нидер бар бит. Ир белән хатын бер-берсен тыңлап, үзара килешеп яшәргә тиешләр. Иншалла, бүгенге парлар бәхетле яшәрләр. Гамәлләрен изге урыннан башладылар.

- Салган мәчетең - Казанның бер бизәге, Шамил абзый.

- Алай димә, Госман, Аллаһы Тәгалә үзе ярдәм итте. Җәмәгатьчелек булышты. Төзелешне очлап чыгудагы ярдәмегез өчен гарәп дустың Абдулла Хәмид Әл-Басит белән сиңа да Аллаһының рәхмәте яусын!

- Үзегез әйтмешли, безнең хезмәт бик кечкенә, юллаучылар гына бит. Күвәйт мәмләкәте кешеләренә рәхмәт! Вәлид Әс-Сабахка. Шәхси фирмасыннан матди ярдәмне ул күрсәтте. Аның җәмәгате Нидалль ханым Әл-Хаҗри безгә Биектау районының Ямәширмә авылында Аллаһының зур бер Бәйтулла йортын салып бирде. Мәчет салучының үзенә дә Аллаһы Тәгалә оҗмахта аерым бина кылыр, диелгән хәдисләрдә. Иншалла, изгелекләре үзләренә кире кайтыр ахирәттә.

- Шулай да ничә мәчет салдыгыз Татарстанда, Госман дус?

- Егермедән артып китте. Иң матурлары Аксубай районының Карасу авылында, Саба районының Юлбат авылында һәм башка төбәкләрдә. Биектау районының Чыршы авылында сала торган мәчетләре ярты юлда туктап калган. Архитектурасы үзенчәлекле - берничә кырлы, гаять матур. Шуны аякка бастырасы иде менә.

- Бирсен Ходай.

- Бәхетлеме сез, Шамил абзый?

Картның күңеле тулды, елап ук җибәрде. Чөнки бәхете тулып ашкан иде аның. Матди байлык белән түгел, инсан рухи байлык белән бәхетле бу дөньяда.

- Әлхәмделиллаһи, бүген 76 яшемдә сау-сәламәт, җаным тыныч, күңелем саф, балаларым тәүфыйклы - тагын ни кирәк. Чабам әле шулай үз көемә.

- Фирма-предприятиеләрнең эшен тикшерәсездер инде.

- Нинди фирма ул?

- Мафиячеләр белән бер сафка куялар ич үзегезне. Халык сөйли икән, аңа җавап бирергә дә кирәктер инде, Шамил абзый. Мәр атасы дигәч тә... Бәлки, кечерәк кенә банк хуҗасыдыр үзегез.

- Хи-хи-хи... Һм! Рәхмәт, Госман, рәхәтләнеп бер көлдердең, ичмасам! Ничектер, бушанып калдым. Усал телләләр җитәрлек анысы, сиңа үпкәләмим турысын соравыңа. Җавап бирәм. Иске мәчет ишек алдына автостоянка ачып җибәргән идек, мәчет чыгымнарын күздә тотып. Шуны биш итеп сөйләделәр кайберәүләр.

- Инде бетте бугай. Татарстанның атказанган транспорт хезмәткәре дигән мактаулы исемне кайчан алдыгыз соң?

- Алмадым, бирделәр. Дүрт көпчәк өстендә йөрүемә 50 ел тулган көндә. Карале, Госман, мактаулы исем йөртүчеләргә карата, имештер, Президентыбыз Минтимер Шәриповичның указымы, ниндидер карармы бар дип ишеткән идем. Пенсияләргә өстәмә турында. Яхшы булыр иде ул. Югыйсә, бик аз бит. Пенсияне әйтәм. Үзеңнең дә мактаулы исемең булгач, кызыксын, ачыкла әле шуларны.

- Әйтергә бик атлыгып тормыйлар шул андыен, Шамил абзый. Өстәмә түләүдән шүрлиләр. Янга калдыралар, янәсе. Әлегә юк андый документ-сәнәт.

- Алайса, ни пычагыма кирәк атказанган исемнәре? Күз буяу булып чыга ич бу!..

- Киләчәк кешесен ничегрәк күз алдына китерәсез, Шамил абзый? Башка сорау биреп тинтерәтмәм.

- Нәселенә, милләтенә, расасына карамастан, адәм баласы фитрый иман белән туа анадан. Бу - Коръәни-Кәримнең үзендә үк бар. Безнең көннәрдә япон галимнәре исбатлап та күрсәттеләр. Игътибар ит әле, Госман, кешенең үпкәсенә кан тамырлары белән "Ләә иләәһә иллаллаһ" дип язылган икән бит. Фитрый иман шул була инде. Аны саклап, иман әһле булып яшәргә генә кала инсаннарга. Иманын югалткан зат - адәм түгел ул, шайтан. Андыйларда тәүфыйк, хәят, һидәят, шәфкатьлелек булмый. Зәгыйфь җанлылардан гаиләсенә дә, хөкүмәткә дә, кешеләргә дә файда тимәс. Алла сакласын иманыбызга хилафлык килүдән!

Мәчетләребез төзелә, халык иманга кайта, дин юлына баса. Аллаһының берлегенә инана, аңа гыйбадәт кыла. Иншалла, киләчәк буын бүгенгеләрдән өстенрәк торыр. Аллаһының рәхмәтендә булыйк!

- Бик, бик рәхмәт үзеңә, Шамил абзый, туры, гадел җавапларыңа. Исән-имин яшә.

Әңгәмәдәш - Госман ГОМӘР.

С. ИСХАКОВ һәм архив фотолары.

РЕСПУБЛИКАБЫЗ - МАТБУГАТ ДӘРЬЯСЫНДА

АКТАНЫШ

Соңгы елларда хезмәтнең, хезмәт алдынгыларының кыйммәте төшү күпләрне пошаманга сала килә. Бәхеткә, бу күренеш һәркайда да колач җәймәгән. Актаныш районында төрле һөнәрләрдә дан казанган кешеләрне олылау дәвам итә. Әйтик, анда район күләмендә алдынгылар слеты үткәрелә. "АКТАНЫШ ТАҢНАРЫ" газетасы шул слеттан зур язма биргән. Слетлар анда катнашучылар өчен зур бәйрәм була, дип яза газета. Аларга район хакимияте башлыгы Э. Н. Фәттахов кул куйган тәбрик открыткасы, кыйммәтле бүләкләр тапшырылган. Алдынгылар хөрмәтенә матур концерт бирелгән. Бәйрәмдә аларны республика авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры М. Г. Әхмәтов кайнар котлаган. "Актаныш - игенчелек районы, - дигән ул. - Республикабыз амбарларын баетуга саллы өлеш керткән, быелтыр ашлык сату буенча дәүләт алдындагы бурычын үтәп чыккан бик сирәк районнарның берсе".

"Хезмәткә - хөрмәт!" девизы һәркайда гамәлгә ашсын иде. Чөнки хезмәттән башка тормыш юк, алгарыш юк.

ЧҮПРӘЛЕ

"Узган ел күп кенә гаиләләр өчен истәлекле ягы белән тарихка кереп калды", - дип яза "ТУГАН ЯК" газетасы. - Меңнән артык гаилә зәңгәр ягулыклы булды, аның рәхәтен күрүгә ирешә. Район хакимияте башлыгы Җ. А. Гафуров, барлык газчыларны җыеп, сөйләшү уздырды. Сүз дә юк, ирешелгән уңышлар белән берләштән, кимчелекләр дә телгә алынды. Соңыннан газчылар, ел буе куйган мәшәкатьле хезмәттән аерылып, чәй өстәле артында кунак булдылар".

ӘГЕРҖЕ

"Шәфкатьлелек әле бетмәгән..." - шундый баш астында "ӘГЕРҖЕ ХӘБӘРЛӘРЕ" газетасы Салагыш урта мәктәбе директорының тәрбия эшләре буенча урынбасары Йолдыз Шәйхетдинованың хәбәрен урнаштырган. Анда Биктимеровлар гаиләсенең игелекле эшләре турында сүз бара. Бу гаилә Салагыш авылында гына түгел, тирә-юньдә олы ихтирам, абруй яулаган. Гаилә башлыгы Рәмис һәм аның хатыны Фәридә, мәктәпнең матди хәлен аңлап, төрле кичәләр, конкурслар үткәргәндә призлар алуга, уку алдынгыларын бүләкләүгә һәрвакыт ярдәм итәләр. Яңа ел бәйрәмен уздырганда да бу гаиләнең ярдәмен нык тоя мәктәп.

Гаиләдәге өч кыз бала - Илзирә, Асия, Диләрә дә, әти-әниләре кебек, шәфкатьле, дусларына ярдәмчел булып үсәләр. Өчесе дә - мәктәпнең уку алдынгылары.

БАЛТАЧ

Районның "ХЕЗМӘТ" газетасы хәбәр иткәнчә, хезмәте татар музыкасында тулы бер дәвер саналган, халыкның рухи байлыгын үстерүгә зур өлеш керткән Салих Сәйдәшевнең тууына 100 ел тулу уңаеннан, аның бөеклеген, музыка сәнгатенә керткән өлешен мәңгеләштерү максатыннан, район мәгариф бүлеге "Җыр булып сезгә кайттым" дип исемләнгән район җырчылар конкурсы үткәрә.

Конкурста Салих Сәйдәшевнең төрле елларда язылган бер җырын һәм ирекле темага бер җыр башкарырга тиеш булачаклар. Җиңүчеләр районда С. Сәйдәшевнең 100 еллыгына багышланган

"Бер без генә түгел,
көйләрең дә,
Сагына сине - язлар
җылысын"

дип исемләнгән искә алу кичәсендә катнашу хокукына ия булачаклар. Анда җиңүчеләргә район хакимиятенең һәм мәдәният бүлегенең кыйммәтләре призлары тапшырылачак.

АПАС

Газеталар Бөек Ватан сугышының 55 еллыгына багышланган язмаларга зур урын бирәләр. Аерым алганда "ЙОЛДЫЗ" газетасы "Җиңү солдатлары" рубрикасы астында Шәмбалыкчы авылыннан сугышта катнашкан Рифгать Мадышев турында зур материал урнаштырган. Авторы сугыш һәм хезмәт ветераны Зиннәт Хәйруллин.

Гаҗәеп язмышлы зат икән ул Рифгать агай. 1943 елның 9 февралендә 1925 елда туганнар сафында авылдан җиде егет фронтка алына. 18 яшьлек егет беренче чыныгуны Смоленск янындагы бәрелешләрдә ала. 21 декабрьдә Рифгатьнең аягы яралана. Ржев госпиталендә дәваланганнан соң янә фронтка китә, тагын яралана. Госпитальдә 6 ай ята. Аягы төзәлгәч, Шауляй шәһәренә разведчиклар әзерләү курсына языла. Биш ай укыгач, берничә тапкыр дошман тылына рейдлар ясый, командованиегә кыйммәтле мәгълүматлар алып кайта. III нче дәрәҗә Дан һәм Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнә. Немец офицерын кулга төшерү өчен ясалган бер рейдта тагын яралана. Яра шул кадәр авыр була ки, Рифгать 12 операция кичерә, 2 ел 6 ай дәвамында Ленинградта дәвалана. Яшь организм үлемнән көчле булып чыга.

1947 елда Р. Мадышев Кирәмәт авылына кайта. 20 яшендә аңа инвалидлык бирәләр. Вакыт үтү белән сәламәтлеге ныгый бара: умартачы, балта остасы һөнәрен үзләштерә. Хатыны Фәүзия белән өч бала тәрбияләп үстерә. 1979 елда гаиләгә бәхетсезлек килә: Фәүзия ханым вафат була.

Әмма Рифгать өметсезлеккә бирелми. Ул авылның яшел зонасын киңәйтә. Узган җәйне генә дә 120 төп агач утырткан.

Юныс САФИУЛЛИН,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

Көз алмасы



Көзнең бөтен матурлыгы алмада. Көзге алмалар соңрак өлгерсәләр дә, зур, матур, әчкелт тәмле һәм озак саклана торган булалар. Академия театры артисты Әзһәр Шакирны мин шуларга охшатам. Җәйге алмалар турында инде күптән онытканнар, ә көзге алма исә бөтен дөньяга ямь биреп тора.

Бу якты җир йөзенә беребез дә ата-анасыз гына килмәгән. Шуның кебек артистлар да, ягъни сәхнәләрне бизәп торган зур талантларның осталыклары да үзләреннән элгәрерәк иҗат итеп киткән сәхнә осталарыннан мирас булып калалар. Шәүкәт Биктимерне Хәлил Әбҗәлилов дәвамчысы дип атасалар, Ринат Таҗетдинны Шакир Шамилский мәктәбен үстерүче дип йөртәләр. Ә инде Әзһәр Шакирны Мохтар Мутин дигән трагедияләр каһарманына китереп бәйлиләр. Хәлбуки, якты дөнья белән бик фаҗигале рәвештә аерылышкан бу бөек татар трагигының мирасын теләсә кем күтәрерлек булмаса да. Әгәр бу легендар артистның дәвамчысы Әзһәр Шакир дип телгә алына икән, хәтта шаяртыбрак әйтелсә дә, бу бик зур дәрәҗә. Чөнки Әзһәр Шакир үзенең иҗатын трагиклар "кирәк түгел" дигән чорда башлап җибәрде.

Әзһәр Шакир (Садыйк) Ш. Әсфәндиярова белән ("Тирән тамырлар").

Әзһәр Шакир (Туктамыш... Ханбикә — Алсу Гайнуллина ("Ид...

1997 ел иде ул. Театр үзенең артисты Әзһәр Шакирны Тукай бүләгенә кандидат итеп тәкъдим итте. Мин шушы уңай белән радиотапшыру эшләргә тиеш идем. Шул чорда мине бер нәрсә бик гаҗәпләндерде, безнең берсен-берсе "ашый" торган татарларыбыз төрле төбәкләрдән Әзһәр Шакир кандидатурасын хуплап, Мәдәният министрлыгына да, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясен бирү комиссиясенә дә, Академия театрына да бер-бер артлы хатлар яудырырга тотындылар. Йөзәр, икешәр йөзәр кеше җыелышып, үзләренең имзаларын куеп җибәргән хатлар да бар иде араларында. Башкортстан, Әлмәт, Минзәлә театры артистларының да күпсанлы имзалар белән бизәлгән хатлары белән таныштык. Хат язучыларның үз артистына булган олы мәхәббәтләрен күргәч, мин уйга калдым. Кем ул драма артисты? Милли театрда эшли торган артист халкыбыз язмышында нинди роль уйный? Тормыштагы асылы нидә аның? Халык хезмәтчесеме ул? Әллә тәрбиячесеме? Милләтебезнең баш сәхнәсендә 39 ел мәйдан тоткан чорда артист Әзһәр Шакир киң халык мәхәббәтен ничек яулап ала алган соң?

Мин аны 38 ел буе якыннан күреп беләм. Бергә гастрольләрдә дә йөрергә туры килде. Беренче рольләрендә ул, әйтсәм әйтим инде, хәтта миңа да бик тәҗрибәсез артист булып күренә иде. Җитмәсә, тамашачылары да шул уйларны җөпләгәндәй: "Нәрсә уйный инде бу?" - дип куялар иде. Әйе, театрга кереп яңа эшли башлаган чорында ул мәхәббәтсез үрдәк бәбкәсе генә иде әле. Ике ел ярым армия сафларында йөреп кайткач, аны "Айдын" спектаклендә Айдын ролендә күрдем. Айдын-Әзһәр мине шаккатырды. Ирексез кулыма каләм алып, мәхәббәтсез үрдәк бәбкәсенең ничек итеп бөтен кеше таң калган аккошка, тагын да дөресрәге, лачынга әверелә башлавы турында язарга утырдым. Ул мәкаләдә төп фикер театрдагы кайбер яшь артистларның иң талантлы артистны үзләренә өлге итеп алып ул тудырган образны, артист тапкан буяуларны һәм уен алымнарын да үзенең уенында кучергеч аша күчергәндәй кулланып, шулай ансат кына уйнап, яшәп, дан казануларын, ә Әзһәрнең Рамай, Җәүдәт, яисә Дәрвишнеме уйнаганда булсын, фидакарь юлдан барырга тырышуын, үзенең табышларына бер яктан чиксез куанып, икенче яктан башкалар аңламас дип бик нык борчылуларын да, шушыларның аны билгеле бер кысаларда аяк-кулларын бәйле хәлдә тотуын да яздым. Боларны соңгы күзәтүләрем белән аралаштырдым. Айдын кебек катлаулы рольне чишәр өчен югары талантка ия булу өстенә нәкъ менә Әзһәр кебек үз юлыннан баручы, даими эзләнүчән иҗат иясе булу да кирәк, дидем. Рольнең катлаулылыгы әле ул бер нәрсә, безнең артистка бит Әзәрбайҗаннан килгән рәссам, композитор һәм Араблинскийларның театр мәктәбен дәвам итүче режиссер белән дә эшләргә туры килде. Бер якта безнең традицияләрдә тәрбияләнгән тамашачы һәм сәхнәдәшләре, икенче якта Кавказның күтәренке рухын таләп иткән постановка әгъзалары... "Кем уйлаган шушы шаярулар..." урынына "эзләнүләр" диик-әйе, әүвәл елларда кешеләрдә күбрәк көлү уяткан эзләнүләре... Әйтик, Рамайны уйнаганда бутафор ишекләрне чын ишекне бәреп кергәндәй керүе, яки Җәүдәтне уйнаганда агач итеп куелган декорацияне чын агачны коч-кандай шундый каты итеп кысып ала иде, агач шыгырдап ава ук башлый һәм артист Әзһәр аны җайсыз гына тотып алып кабат урынына бастырып куярга мәҗбүр була иде. Тавышында да сизелгәли иде аның мондый кирәкмәгән көчәнешләре. Чамасызрак хисләнеп китүен күрүчеләр аның турында, хәтта әче теллеләнеп "елак артист", дигән сүзләр дә әйткәләделәр. Әмма үзе генә белгән эзләнүләреннән Әзһәр Шакир барыбер чигенергә теләмәде, каурыйлары яңа чыга башлаган канатларын зур бөркетләрнекедәй җәеп-җилпеп кеше көлдерсә көлдерде, әмма ләкин үзенә кирәкне тормышның үзеннән чумырып алды, дөнья, тормыш, шәхес турында күргән-белгәннәрне күңеленә җыйды, барсын да күңел күзе аша үткәрде, эзләнде, уйланды, хыялланды һәм тамашачыларны да сәхнә образлары аша шуңа чакырды.

Халкыбызның ерак гасырлардан килгән җан авазын, үзенә табигать бик мул салган талантны, татар театр сәнгатеннән төбе-тамыры белән куптарып алынган Мутиннарның зур тәҗрибәләрен үзендә, иҗатында ничек уята алды икән соң ул?

1940 елның февраль ае. Азнакай якларындагы карурман уртасында посып утырган бик кечкенә, хәтта рәтле исеме дә булмаган авылда яңа тормыш аваз сала. Моңа шул ук авылның күршедәрәк урнашкан йортыннан икенче бер аваз килеп кушыла. Тавышын беркемнән дә курыкмыйча кыю итеп яңгыраткан бер яшьлек Нәҗибә була ансы. "Борчылма, энекәш, мин дә бар әле монда", янәсе. Салкын, ят дөньядан шүрләп калган кечкенә Әзһәр шундук тынычлана. Әһә, ул

"Ябырылу". Әзһәр - Федор Таланов.

Аксак карт - Ә. Шакир, Бичура ролендә К. Камал ("Бичура").

ялгыз түгел икән... Дөнья яңгыратып шаулаган, шатланган һәм бергә-бергә уйнап үскән бу ике баланың киләчәктә татарның ике мәшһүр артисты Әзһәр Шакир белән Нәҗибә Ихсани буласын укучылар инде сизенгәннәрдер.

"Ул авылның, - һич онытмыйм,- һәр ягы урман иде", - дигән Тукай үзенең Кырлае турында. Әзһәрләрнең дә туган авыллары шулай лабаса. Охшашлык моның белән генә бетми икән, әле башлана гына... "Монда бульварлар, клуб һәм танцевальня, цирк та шул, монда оркестр, театрлар да шул, концерт та шул". Бер сүз белән әйткәндә, Әзһәрләргә боларның һәммәсен табигать үзе алыштыра: клуб, радио-телевидение, электр юк дип тормый бай табигатьле авыл халкы, татар халкының борын-борыннан килгән гүзәл гореф-гадәтләрен саклап, җыр-биюләрен капка төпләрендә җыелып утыргандамы, яисә аулак өйләрдә уйналган уеннарындамы башкарып шау-гөр килеп яши бирә. Кечкенәдән китап җене кагылган Әзһәрне дә читләтеп үтми алар... Безнең милләттә гомер бакый укуга, белемгә омтылу беренче урында булган. Татар кешесе авылда яшиме, әллә шәһәрдәме, соңгы акчасын биреп булса да, баласын укымышлы ясарга тырышкан. Нәҗибә белән Әзһәрнең әти-әниләре дә унынчыны бетергән балаларын хәер-фатихалар биреп Казанга Ленин укыган университетка озаталар.

Азнакай якларыннан Казанга юл бик озын. Көне буе җәяүләп пычрак ерып килә торгач, аяк киемнәре дә шактый тетелә. Аларга ябышкан үзле кара балчыкны каерып алырлык түгел - хет сал да ташла. Яшь юлчылар шулай итәләр дә: аяк киемнәрен салып Сарман күпере астына яшерәләр һәм ялан тәпиләп кенә юлларын дәвам итгерәләр. Чаллы пароходына утырып Казан елга портына килеп кергәч, андагы гаять зур күтәрү краннарын, шалдыр-шолдыр килеп йөргән трамвайларны күргәч, беренче тапкыр олы шәһәргә аяк баскан яшүсмерләрнең йөрәкләре кысылып куя. Әмма озакка түгел; трамвай кузгалып китүгә үк, алар агач чемоданнарын күтәрәләр дә, яланаякларын ялтыратып трамвай артыннан йөгерәләр.

Казан сихри дөньяның тылсымлы әкиятедәй аларга маҗара арты маҗара бүләк итә. Шуларның иң серлесе, әлбәттә, Мәскәүнең Щепкин исемендәге театр училищесына артист булырга теләүчеләрне җыю турындагы белдерүе... Һәм менә - беренче җиңү. Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры Ш. Сарымсаков рәислегендәге комиссия Әзһәр белән Нәҗибәне һәм дә тагы артист буласы 21 абитуриентны Мәскәүгә озатып калалар. Ә анда инде "Татарлар килә!" дип сөрән салынган, һәм бер көтү халык татарларны каршыларга дип тимер юл вокзалына төшеп көтеп торган икән.

Мәскәү... Ала алган кешеләргә күпне бирә торган Мәскәү бит ул. Әзһәр Шакирны да рухи яктан бик баета Мәскәү. Тирән театраль белемле итү белән бергә, дөньяның зурлыгын, аның катлаулы булуын аңларга да булыша. Төрле милләт театрларының иҗатлары белән танышырга да, иң гаҗәбе, 1957 елны Мәскәүдә үткән декадага килгән Г.Камал театры белән дә Мәскәү очраштыра. Шулай итеп, Әзһәр үз гомерендә беренче тапкыр татар артистлары уйнаган спектакльләрне күрү бәхетенә ирешә. "Сәйяр" булып оешкан һәм шул ерак чорларда ук үз йөзен табып рус театрларындагы зур артистларның уен осталыкларын да өйрәнеп, шәрык артистларыннан да бик күпне алган милли артистларыбызның лаеклы дәвамчылары уйнаган спектакльләрне әсәрләнеп карый ул. Аның үзенә дә "Хуҗа Насретдин" белән "Зәңгәр шәл"дәге халык күренешләрендә катнашырга туры килә. Уку чорында һәм Казанга кайтып Камал театрында эшли башлагач та, әлеге спектакльләрне караганда алган тәэссораты аңа бик нык ярдәм итә. Аны аеруча хәйран иткән һәм күңеленә гомергә сеңеп калган нәрсә шул - татар артистлары арасындагы соклангыч мөнәсәбәтләр. Шушы өлкән буын артистлары аның йөрәгенә театрның иң изге урын булуын, театрда һәртөрле юньсез, ялкау-хөрәсәннәргә, бозык җаннарга урын булмавын ныклап төшендерәләр; татар театрында милли җанлы, ана телен чын күңелдән сөя һәм күз карасыдай саклый белә торган зыялы чын талант ияләре генә эшләргә тиеш дип инандыралар. Моңа чаклы, һәрбер яшь кешегә хас булганча, үз-үзенә шактый нык ышанып йөргән Әзһәр үзе дә аңламастан пошаманга төшә. Болар кебек артист булып булырмы? Икеләнә-уйлана торгач, чигенмәскә дигән карарга килә. Һәм тагын да тырышыбрак укырга, Мәскәүдәге бер генә мизгел вакытын да бушка уздырмаска омтыла. Аның сәхнәләрендә туган һәр яңа спектакльне карау белән бергә театрларның изге Мәккәсе - Мәскәүгә килгән дөнья театрларын карап барырга да өлгерә. Аңа 1960 елны инглизләрнең "Виктория әби" ("Олд Вик") театрының "Макбет" (Шекспир), "Җитди булу бик мөһим" (Уайльд), "Изге Иоанна" (Шоу) спектакльләрен, итальяннарның 1947 елны ук театрда иҗатны сәүдә-акча артыннан куу белән алыштырган театрларга көндәш рәвешендә Милан шәһәрендә оешкан "Пикколо-театро" труппасының "Өч тиенлек опера", "Сычуаннан килгән яхшы кеше" (Брехт), "Бүген яңача уйныйбыз" (Пиранделло) спектакльләрен күрү дә насыйп була. Остазлары, шул исәптән курс җитәкчесе М.Н.Гладков аларга 1928 елгы гастрольләре вакытында японнарның атаклы "Кабуки" театры уйнаган спектакльләр турында да, французларның 1956 елда Жан Вилар җитәкчелегендә "Халыкның милли театры" килеп күрсәткән гаҗәеп үзенчәлекле спектакльләре турында да җентекләп сөйлиләр.

Сүз дә юк, һөнәр серләренә тәҗрибәле остазлардан өйрәнү зур бәхет. Әмма артистка ул гына аз. Ул чын мәгънәсендә режиссерның һәм драматургның фикердәше, газизе, тамашачыларның маягы, юлбашчысы булсын өчен артистның эчке дөньясы да зур үзгәрешләр кичерергә тиеш. Яшь кеше өчен белем генә түгел, үрнәк алырлык шәхесләр дә кирәк. Әзһәр үзе дә, курсташлары да андый кешеләрнең беренчесе итеп Щепкин курсының йөрәге дип йөртелгән, милләт өчен җан атып яшәгән Хәлил Әбҗәлиловны күрсәтәләр. Иң беренче рәхмәтне аңа юллыйлар.

Инде кабат Әзһәр Шакирның иҗатына кайтыйк. "Ай тотылган төндә" спектаклендә Шириаздан ага 25 яшьлек Әзһәргә бик өлкән яшьтәге Дәрвиш ролен бирде. Күпләр аны карамаган, ахры, хәтерләмиләр... Спектакль үзе дә озын гомерле булмады. Аннары Әзһәр абый икенче составта да иде. Беренче составта Шириаздан ага үзе уйнады. Шириаздан абый бик шәп уйнаган кебек тоелса да, нишләптер Әзһәр-Дәрвиш миңа ныграк ошый иде. Һәм чыннан да шул чорда уйнаган башка рольләренә караганда монысы хәтергә ныграк кереп утырган. Дөрес, әлеге дә баягы, "уйный белмәве" монда да җитәрлек иде. Әйтик, тирмәгә икешәр метрлы адымнар белән килеп кереп, Шәфәкъ тирәли дә зур-зур атлап йөрүләре, кулындагы таягын җир селкенерлек итеп җиргә

кадап алулары һәм сындырырлык итеп чытырдатып кысып куюлары, айны сүндерәм дигән сәхнәдә күкле-яшелле табышлар белән кычкырып җибәрүләре күпләргә ошамады. Әмма мин бөтен спектакль буенча Дәрвиш өчен ут йотып, аны хаклы санап, аның Шәфәкъ белән кавышуын теләп утырдым. Иң беренче көрешүендә үк аның Шәфәкъ каршында алсу алма күреп сихерләнгән сабыйдай кулын сузып туктап калуы, дөньядагы иң изге, иң кадерле нәрсәсен очраткандай, ул, кая гына барса да, аның артыннан ияреп юлбарыстай гәүдәсе белән җиргә аякларын тидерер-тидермәс, бик кыюсыз гына басып йөрүләре, кайчандыр затлы байбичәләр кочакларын ачып җәннәткә чакырганда да иманына тугры калып гөнаһ кылмаган бу изге Дәрвишнең, инде килеп, яшь гомерем заяга үтте, дип өзгәләнгән фаҗига тулы җанын якын итмәү һич мөмкин түгел иде. Һәм менә күңелдәге шушы дулкынландыргыч образ янәшәсенә Айдын да кереп урнашты... Айдыннан соң инде аның турында "уйный алмый" дип әйткәннәрен ишеткәнем булмады. Чөнки ул рольдән рольгә - "Чамасына күрә чарасы" - Анджело, "Чит кеше" - Манагаров, "Чикләвек төше" - Саматов, "Намус хөкеме" - Арсланов, "Синең урыныңа кайттым" - Наил, "Ябырылу" - Таланов, "Без китәбез, сез каласыз" - Акчурин, "Ташлама утны, Прометей" - Зевс, "Бичура" - Аксак образлары аша туктаусыз үсә барды... Икенчедән, әле санап үтелгән рольләр, Айдын шикелле үк, кайбер "уйный белгән" артистларның да тешләрен сындырырлык каты чикләвекләр иде.

Рус театр белгечләре арасында аерым бер ихтирамга ия Борис Поюровский бервакыт: "Әзһәр Шакиров академия театрының тиңдәшсез комигы", - дип язып чыгып безне бик нык шаккатырган иде. Ә бит чыннан да, ул бу өлкәдә дә онытылмаслык образлар иҗат итеп килә. Н.Исәнбәт әсәрләре буенча куелган "Хуҗа Насретдин", "Качаклар", "Портфель" спектакльләрендә Гыймай баскак, полковник Ишмурзин, Миргаян мулла образлары, Г.Камалның "Банкрот"ында Җамалетдин, Тинчуринның "Зәңгәр шәл"ендә Тимуш, Островскийның "Агай-эне ак мыег"ында Большов, Вампиловның "Метранпаж"ында Колошин...

Артист Әзһәр Шакирга гына хас тагын бер сыйфат. Ул инде 25 яшен тутыргач ук өлкән яшьтәге ир һәм картларны уйный башлады. Бу өлкәдә дә уңышка ирешкән рольләре бик күп булды аның. Арадан аеруча Т.Миңнуллин пьесалары буенча Сәлимҗанов куйган "Монда тудык, монда үстек"тәге Саттары, "Илгизәр+Вера"да Нурхәмәте зур яңгыраш алды.

Театрда яшьләрнең иң якын дусты кем, дип сорасаң, Әзһәр Шакир исемен атарлар. Артистлар гына түгел, драматурглар арасында да моны күпләр раслар... "Китәм инде"нең авторы Ризван Хәмид Инсафетдин карт образы өчен, "Мирас"ны язган Гафур Каюм авыр язмышлы Хакимне шәп уйнаганы өчен, "Бичура"ны иҗат иткән Мансур Гыйләҗев спектакльнең ансамблен гәүдәләндерүдә башкаларны бергә туплаучы Аксак карт өчен дияр, ә мин исә 1981 елда "Алмазбулат"та патшаны уйнарга алынганы һәм бу спектакльнең иң җаваплы чорында хәлиткеч ярдәмне күрсәткәне өчен, дип әйтергә телим. Чөнки әсәремдә халыкка азатлык бирүче курайны сихердән арындыра торган тылсымлы сүз "И туган тел!" дип язган идем... Режиссер Сираҗиев, аны җыр итеп яңгыратабыз, гимн итәбез, дигәч, аңа күпләр каршы төште. Әнә шунда, һәм тагын башка кайбер мөһим чараларны да, Әзһәр абый үз абруе белән яклап калды. "И туган тел!" җыры нәкъ менә аның ярдәмендә "Алмазбулат" спектаклендә ун елга алдарак гимн булып башкарылды.

Әзһәр Шакирны Тукай премиясенә "Ахырзаман"дагы Бостон, "Хушыгыз!"дагы Галимулла, "Бичура"дагы Аксак, "Идегәй"дәге Туктамыш хан образлары өчен тәкъдим иткән иделәр. Башта ук үзгә юл сайлаган, иҗатта Мутиннар юлын яңарту уе белән янган Әзһәр ялгышмады. Бер генә театр да үзгәрешләрсез, эстетик яңалыклар алып килүче яңа буын режиссерларсыз иҗат итә алмый. Әдәбиятта да, тормышның башка өлкәләрендә дә бу шулай. Яшьләр өлкәннәрнең иҗатын да яшәртә киләләр. Иң әүвәл Әзһәрнең Сәлимҗанов белән тапкан табышларының бик күп булуын әйтеп үтү кирәк. Барсын санап бетереп булмый, әмма "Сүнгән йолдызлар"дагы Надир мәхдүме бу табышлар арасында үзенә аерым урын тотканы хак. Р.Хаҗиәхмәтов белән иҗат иткән Халик Саматов образын инде башта ук телгә алган идек, Д. Сираҗиевка килгәндә ул, әлбәттә, аларның "Ахырзаман"дагы Бостоннары. Артистның бу спектакльдәге хезмәте турында үзенә бер махсус мәкалә язып булырлык. Эксперимент рәвешендә куелган "Бичура"дагы яшь Ф.Бикчәнтәев белән ирешкән уртак җиңүләрен киң җәмәгатьчелек шулай ук яхшы белә. Моңа аның Аксак ролен режиссерның автордашы буларак тигез эзләнеп иҗат итүе аркасында ирешелде. Милли сәхнәнең бик мөһим бизәге булган сабыр, саф күңелле Галимулла ("Хушыгыз!" - Т.Миңнуллин) шулай ук артистның күптәнге эзләнүләреннән баш алды. Шиллерның "Юлбасарлар" трагедиясен куярга килгән яшь режиссер В.Ярюхин да (атаклы А.Васильевның иң яраткан шәкерте) безнең Ә.Шакирга гашыйк булып китте. Моор картны зур осталык белән уйнаганы өчен генә түгел, ә спектакльнең рухын тудырырга ярдәм иткәне өчен дә. Һәм иң гаҗәпләндергәне шул, яшь режиссерлар тартылган кебек үк, аны зур мастерлар да үз спектакльләренә бик теләп алалар, берсүзсез, үзләренең автордашлары итеп таныйлар. Моңа иң ачык мисал Марсель Сәлимҗанов куйган "Идегәй" трагедиясе. Репетицияләр әле башланып кына килгәндә Әзһәр абыйның әсәрне кыскартырга кирәк дияю күңелне борчып куйган булса, Шәүкәт абыйның миңа пьесага кагылышлы берничә кыйммәтле киңәш бирүе Шәүкәт абый белән арабызны тагын да ныграк якынайта төшкән иде. Һәм менә... премьера. Дөресен әйтим, миңа репетицияләр барышында да һәм спектакльдә дә һәр ике Туктамыш та бик ошады. Аларның Идел-Урал арасындагы Идел-йорт белән саубуллашкан сәхнәләре һәр ике трактовкада да тетрәндерә иде. Беренче спектакльне Д.Сираҗиев карап утырганын күреп, спектакльдән соң аны эзләп таптым да: "Йә, ничек?" - дип сорадым, ул: "Тукта, мин әле Әзһәр белән дә карыйм", - диде. Әзһәр-Туктамыш ханны карагач, Дамир мине котларга керде, һәм: "Менә хәзер бар да урынында... менә бу арыслан зоопарктан түгел..." - диде. Арыслан дип ул Туктамыш ханны күз алдында тотып әйтте. Зоопарктан түгел дип әйтеп артистның чын трагедия югарылыгындагы уенына соклануын белдерде.

Әзһәр Шакирны көзге алма дип юкка атамадым. Ул 60 яшендә дә яшь артистлар кодрәтенә ия. Ак бәхетләр аңа. Татар халкыннан бик иртә тартып алынган Мохтар Мутин өчен дә иҗат итү бәхете насыйп булсын үзенә.

ЗӨЛФӘТ

Канаты бозлы былбыл

Флора ханым Әхмәтова-Урманчега

I

Алганнар... Аткан-асканнар
Җанкайны кыеп -
Шуңа татарның күңеле
Гомергә боек...

Соловкида безнекеләр...
Кемнәр ул? Кемнәр?..
Кем булсын? Бәйле бәндәләр!
...Богаулы көннәр.

Тыннарны каплап дулаган
Давыл артыннан
Салкын ташлар җилен ерып
Гел килә сыман

Урманчелар... Мирсәетләр...
Бөдәйли ага...
Киләләр...
Татар дигән бер
Боек дөньядан!

Ник ышансын сандугачлар
Сайрар җир барга? -
Аттылар сандугачларны
Шыксыз елларда...

Кыргый бер ләззәт -
асылны
Кыйнап елату -
Еламассың! Ил шөгыле -
Сандугачны бикләп кыйнау,
Сандугач ату!

Эзәрлекләр өчен генә
Салынды эзләр -
Сандугачсыз илдә
Козгын
Үләксә эзләр.

...Ышанып булмый
сандугач
Сайрар җир барга -
Терәлде килеп халыклар
Былбылсыз ярга.

Сукмак эзе... Шул боеклар
Йөридер сыман.
Офыкта - сагыш йолдызы.
Һәм сәер томан...

Рәссам һаман тарих белән
Бергә, янәшә -
Сөембикәнең үзен ул
Дәшеп киңәшә.

Сөембикә... Әнә бит ул -
Мең рәнҗештә!

Карашы -
кайнар шарлама
Упкынга төшә...

Заманның тарих төбеннән
Илтеп килеше
Рәссам керфегеннән тамган
Гаҗәеп төсне!

Былбыллы таңны ясарга
Туңадыр кулы -
Котып бураны туңдыра
Илнең былбылын...

Бу Җирнең сандугач качкан
Явыз төшендә
Мең таңнарны уятырлык
Былбыл күшегә...

Күрәсең, шуңа без моңлы
Җырлыйбыз һаман,
Томшыгы туңган сандугач
Сайраган сыман...

II

Бозлы Ак Диңгез ярында
Уйланып торам -
Бөкрәеп Бакый абзыкай
Киләдер сыман...

Канга сусаган чор
Бүре
булып улады.
Ныклы уллары халыкның
Түзде... Сынмады!

Үзе Җирдә мең җәфалар
Чиккәнгә микән -
Урманче
шагыйрь Тукайны
Бәхетле иткән.

Кымызлы дала - сурәттә.
Дөньялар бөтен,
Дөньяның монда үзәге,
Мондадыр чите...

Казакъ илендә - сөргендә
Ясалган сурәт...
Абайны да, Тукайны да
Сыйдырган йөрәк.

...Урманченың үзен саклый
Йозак та тимер -
Соловкида - ак төннәрдә
Уза яшь гомер.

Нәкъ урманчы, сабанчының
Куллары ләса!
Шушы кулларның җылысы
Күкләргә аша...

Карадым... Шәп бармакларын
Күрдем дә аның -
Чаңгы башына охшатып
Шаккатып калдым!

Чаңгы башыдай, бармаклар
Бөгелгән иде,
Ашалган иде ул куллар...
Күп күргән иде!

Җәфалы күңел дәшә гел
Ерак-еректан -
Җан күчә актан карага,
Карага - актан.

Калевала чорларыннан
Саф дулкын кага.
Кабына төсләр дөньяда,
Мең төсләр яна...

Сокланмыйча буламыни
Төсле дөньяга!
Сын-сурәтендә
Тукайның
Йөрәге яна...

Ходай сулышы

Инде кайтмас яшьлек
Йә якында,
Йә еракта учак кабыза,
Якын-ерак айкала да ялкын,
Бәгырьләрне өтә... Җан сыза!

Шул баш бирмәс еллар - кайнар яшьлек
Уңны-сулны белмәс булганга -
Кагылганмын былбыл оясына
Һәм басканмын
кара еланга...

Дөрли генә яшьлек, ут шикелле,
Сүнмәс, капмас өчен кабынган -
Кичке шәфәкъләрдә учак кабыз
Кичәге таң офыкларыннан!..

...Ходай сулыш өргәч җан кергән бит
Безгә -
сынга -
үзле балчыкка!
Бәлки... тагын сулыш өрер Ходай?
"Җитте..." - димә, йөрәк, ашыкма!

Ут йөгергән икән шул сулыштан
Сулык-сулык типкән бу канга -
Димәк,
сөю булып килеп керден
Үзең гомер итәр Ватанга!

Билләһи, дим:
Гомер дигәнебез,
Еллар белән санап карасаң,
Мең афәтле еллар түгел һич тә -
Мәхәббәтле еллар лабаса!

Чәчләремне җилләр тараганда
Уйларымны еллар тарады -
Йөрәгемне былбыл чакты минем,
Кара елан миңа сайрады.

...Ник тоташтан гашыйк булам һаман?
Алгысытыр еллар күп мәллә?
Ходайның бер Кашка тәкәсеме?
Яшәр җирем - Изге күк мәллә?

Туймас-тәкәнмәс бу гыйшкым өчен
Ни диярмен анда - азакта?
Яратудан кылган гөнаһларым
Саналмасмы икән савапка?

Уйнаклап кан,
әйбәт җөмләләрне
Яшьтән шигырь итеп мин шаштым -
Болар миңа савап саналмас шул...
Болар -
минем бетмәс гөнаһым!

Китмәс өчен килде, ахры, яшьлек...
Тетрәп,
дөнья онытылганда
Кагылам гел былбыл оясына,
Һәм...
Басам гел кара еланга!

Рәхмәт, дөнья,
Язмышның син миңа
Тоташ шигырьлесен сайладың, -
Йөрәгемне былбыл чакты минем,
Һәм өздереп елан сайрады!..

Упкын төпләрендә гөлләр үскән
Кыяларны белеп сайладым...
Мин
былбылдан
сезне чактырырмын,
Тыңлатырмын елан сайравын.

Нәсел тамгасы

Ерак бабайлардан килгән тамга,
Безнең тамга - нәсел тамгабыз...
Әткәемә килеп ирешкән ул...
Нәсел тере! Исән калганбыз!

Ул тамганы әткәй
өй салганда
Балта белән чапты нигезгә.
- Хәтерләп кал, улым, бу тамганы
Һәм яман сүз аңа тигезмә!

Бу тамгада -
адәм, фикер, очыш...
Шулар һич тә туктап калмасын!
Тапшыра күр, берүк, оныкларга -
Бу тамганы сулар агызмасын,
Бу тамганы утлар алмасын!

Сукбай каны түгел -
тамырыңда
Борынгыдан килгән кан яна! -
Синең өчен нәсел кызармасын,
Син дан өстә шушы тамгага!

Җиде юл чаты

Әллә нинди яман бер киная,
Ым бар сыман тоя күңелем -
Белгәнгәме кемне йотканлыгын
Мең тугыз йөз утыз җиденең?

Язмыш шулай сайлаганмы әллә
Иҗади җан сулар вакытны?
Дәшкән еллар
Дантесларны түгел -
Күн киемле бозбаш маңкортны!

Гигант илнең табигате шундый,
Һаман да шул шомлы җил исә -
Күр -
Пушкинны кача-поса җирләү
Нәкъ безнеңчә - утыз җидечә!

Тарихыңнан кая качмак кирәк? -
Гүзәл храмны бу ил бар кылган...
- Бүтәннәр төземәсеннәр! - дип,
Осталарның күзен чукыган.

...Сәер "җиде" һаман җанга тиде -
Егерме лә җиде яшендә,
Үлеп, халкын Тукай ятим итте...
Артык сергә мәллә төшенгән?

Афәт арты афәт... Бу зур илгә
Кем каргышы тиде? Ник тиде? -
Октябрьле бер ел ымсындырды! -
Тик ул -
мең тугыз йөз унҗиде...

Хәер, дуамал ил сан тылсымын
Санга сукмас иде... Болай да
Элеп кенә ала, селкеп сала -
Җан котыла качып Ходайга...

Белми генә китте микән Пушкин
Газраилнең атта җиләсен -
Шагыйрьләрне дуэльләрсез генә
Аулар Утыз җиде киләсен?
Юньле илдә юньле шагыйрьләрне
Көтәр иде җиде юл чаты...
Ил шагыйрьсез калмас... Әмма бу ил
Күпне алды... Азны югалтты -
Азны... тере язны югалтты!

Ак акчарлак хәле

Җем-җем генә килә елгыр балык -
Тәңкә-тәңкә тере яктылык!
Канат очы кара акчарлаклар
Ак яшендәй төшә атылып.

Тырнакларда тыпырчына балык...
Балык оча!
Гаҗәп хәл күктә!
Җилпенми ул... Һава - кошны гына,
Су - балыкны гына җилкетә.

Ау уены -
гадел!
Күктән аска
Томырылып төшкән ау гына
Койрык күрсәтә дә,
чума балык!..
Аучының җен куба ачудан!

Ау һөнәре - иң борынгы һөнәр,
Шәфкатьле дә һөнәр,
Гадел дә!
Ау икән ау! Куып сук корбанны!
Котыл аудан -
килсә хәлеңнән!

Һәр тере җан, хәрам кылмый гына
Тапса икән хәләл тәгамне,
Иң беренче һөнәр - ау һөнәре -
Адәм иткән безне - адәмне.

Ләкин...
Өнсез итә бер тамаша:
Гигант чүплекләрнең өстендә,
Юк, үләксә козгыннары түгел -
Горур акчарлаклар чемченә...

...Актарына ап-ак акчарлаклар,
Юаш тавык гүя тибенә...
Иблис җиңгән фәрештәме алар,
Демон мәллә Ходай күгендә?

Хәлләр болай барса, Иблис җиңсә,
Ак хыяллар тәмам җиңелсә,
Сандугачлар хәер теләнсәләр,
Тиреслектә Пегас тибенсә,

Бу - яшәүме булыр? Шул акчарлак
Хәле килде безгә, иптәшләр!
Кая менеп, ни дип оран салыйк?
Сәнгатьтәшләр,
хәл бит бик хәтәр...

Бөек табигать бит үзе иде
Иҗатчының иң зур остазы!
...Чүплек башы... Ап-ак акчарлаклар
Юаш тавык сыман җим казый...

Татарстанның халык артисткасы Асия Галиева 27 гыйнварда үзенең 70 еллык юбилеен билгеләп үтте. Г. Камал театры бинасына бу көнне күренекле артистканы туган көне белән котларга иҗатташ дуслары, яраткан тамашачылары, укучылары җыелган иде. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Роберт Миңнуллин Асия ханымга Президент исеменнән Мактау грамотасы тапшырды.

Асия Галиева тамашачыларга Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская булып Гөлҗамалны уйнавы белән, И. Юзеевның "Таныш моңнар"ындагы Резедә һ.б. образлары аша яхшы таныш. Халык аны ярата, үз итә. Бу кичәдәге чәчәк бәйләмнәре һәм алкышлар шул турыда сөйли.

19 гыйнварда Ш. Камал музееның җыйнак кына экспозицияләр бүлмәсендә халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиевнең тууына 70 ел тулу хөрмәтенә искә алу кичәсе уткәрелде. Бирегә әдипнең укучылары, шәкертләре, каләмдәшләре, җырчылар һәм иҗатын, шәхесен хөрмәт итүче күп кенә затлар җыелган иде. Мөхәммәт Мәһдиев - зур язучы, гаҗәеп сүз остасы. Искиткеч матур, аһәңле, нечкә фәлсәфәле, халыкчан әсәрләре белән ул татар укучысының мәхәббәтен яулап, күңеленә мәңгегә кереп урнашты. Халык аны укый, ярата, сагына.

"Кеше китә - җыры кала" дип исемләнгән әлеге кичә Мөхәммәт абыйның чын халык язучысы, аның сөекле заты икәнен тагын бер кат раслады. Ихтимал, шундый олы язучының 70 еллыгы зур, якты залда үтәргә тиеш булгандыр. Истәлегенә лаеклы хөрмәтне дә күрсәтә белсәк иде.

Р. Якупов фотолары.

135 еллык тарихы булган Татарстан Милли китапханәсе "Ел китапханәсе" исеменә лаек булды.

Россия күләмендә уздырылган бәйгедә, 60 мең китапханә арасында, лауреат исемен яулап алу - ул зур дәрәҗә.

Татарстан Милли китапханәсе үзенең укучыларына 3 миллион 34 мең китап һәм башка төрле мәгълүмат чыганаклары - борынгы төрки, гарәп кульязмаларыннан алып иң заманча электрон басмаларга кадәр тәкъдим итә. Бу китапханәнең укучылары саны 50 меңнән артык. Ул Татарстанда гына түгел, аннан читтә - татарлар тупланып яши торган төбәкләрдәге китапханә фондларын татар телендәге китаплар белән тулыландыруга да ярдәм итә.

"Яңа исемнәр" дип аталган Беренче Бөтенроссия бәйгесеннән Казанның кыллы квартеты - Элиза Бухарова, Наилә Хәсәнова, Альбина Жур һәм Айдар Баһаветдиновлар лауреат исеме алып кайттылар.

Иҗади ярышлар П. Чайковский исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясенең Зур залында узды. Анда Россиянең бөтен почмакларыннан 700 дән артык яшь музыкант катнашты. Аларны Россиянең беренче Президенты Б. Ельцин, Россия Президенты вазыйфаларын башкаручы В. Путин, Мәскәү мэры Ю. Лужков, Бөтенроссия һәм Мәскәү патриархы Алексий II сәламләде.

Лауреат исемен яулап кайткан әлеге дүртлек Казан дәүләт консерваториясе каршындагы мәктәп-лицейда белем ала. Остазлары - Юлия Виват.

Татарстан сәүдә-сәнәгать палатасында "Асыл затлар" күргәзмәсе ачылды.

Бирედә Казан тарихында билгеле бер урынны алып торган купецларның (алар үзләрен сәүдәгәр дип атамаган) эшчәнлеге, җирле үзидарә тормышындагы роле, ике дистәдән артык купец династиясе хакында бай мәгълүмат тупланган.

Күргәзмәне ачу тантанасына купец Борнаев, Үтәгәнов, Мусин, Апанаев кебек күренекле шәхесләрнең уллары, оныклары да килгән иде.

Гармунчыларның Ф. Туишев исемендәге VII республика һәм курайчыларның И. Мусин исемендәге республика бәйгеләре башланып китте. Балтач, Питрәч, Алексеевск, Буа, Минзәлә районнарында һәм Әлмәт, Казан шәһәрләрендәге җиңүчеләр апрель аенда йомгаклау концертына Чаллыга җыелачак. Әлеге бәйгеләр С. Сәйдәшев белән И. Мусинның 100 еллыкларына багышлана.

Берләштерелгән дәүләт музеенда "Татарстанның беренче аламе" дигән күргәзмә ачылды.

Анда дәүләтебезнең барлык билгеләре: байрак, герб һәм гимн ноталары куелган. Шулай ук узган гасырдан алып бүгенге көнгә хәтле чордагы милли хәрәкәткә багышланган газета-журналлар, фоторәсемнәр тупланмасы да кызыксыну тудырырлык.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында "Зәңгәр шәл"нең чираттагы премьерасы куелды.

Ничә еллар буе сәхнәдән төшми уйналган, театрның гына түгел, халкыбызның йөзек кашы булырлык "Зәңгәр шәл" - К. Тинчуринның 110, С. Сәйдәшевның 100 еллыгына багышланган. Спектакльнең режиссеры - Марсель Сәлимҗанов. Сәхнәне искиткеч матур бизәкләргә төрүче - Таң Еникеев. Биюләрне театрның күренекле балетмейстеры - Сәлимә Әминова куйган. Төп рольләрне Әзһәр Шакиров (Ишан), Илсөя һәм Рамил Төхфәтуллиннар (Мәйсәрә, Булат) башкара.

"Зәңгәр шәл" беренче тапкыр 1926 елда уйнала. К. Тинчурин үзе режиссер һәм төп рольне башкаручы буларак танылa. Оркыя Кушловская, Галия Кайбицкаялар да спектакльдә катнаша. Өч елдан ул яңартып куела. 1937 елга чаклы "Зәңгәр шәл" сәхнәдән төшми. Шушы елны К. Тинчурин кулга алына.

1956 елда гына Ш. Сарымсаков җитәкчелегендә кабаттан уйнала башлый.

"Зәңгәр шәл" - тамашачы мәхәббәтен яулаган, татар халкының җыр-биюләрен, гореф-гадәтләрен үзенә сыендырган асыл әсәрләрнең берсе ул.

4 февраль көнне Татарстан язучылары үзләренең еллык эшләренә йомгак ясадылар. Җыенны Язучылар берлеге рәисе, Татарстан халык депутаты Фоат Галимуллин ачып җибәрде һәм алып барды.

Биредә Язучылар берлегенә яңа кабул ителгәннәргә язучы таныклыгы тапшырылды, исемле премияләргә лаек булучы язучылар игълан ителде.

Язучы, тәнкыйтьче Рифат Сверигин - проза, Владимир Корчагин - рус язучылары иҗаты, Марс Шабаев - публицистика, Рафис Корбан - балалар әдәбияты, Галимҗан Гыйлманов тәнкыйть турында докладлар белән чыктылар.

В. И. Качалов исемендәге Казан дәүләт академия Зур рус театры VII Бөтенроссия Пушкин театр фестивалендә катнашты.

6 февральдә Псков шәһәрендә узган театрлар җыенында казанлылар "Пиковая дама" спектаклен күрсәттеләр. Безнең артистлар бу әсәр белән Франция сәхнәләрендә танылып өлгергәннәр иде инде.

Сәнгать музеенда Шакир Мөхәммәтҗановның графика әсәрләре күргәзмәсе ачылды. Рәссамның 100 еллыгына багышланган әлеге күргәзмәгә аның хезмәтләре һәм тормышына багышланган документлар куелган.

Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле Мәскәү тамашачыларының ихтирамын яулап кайткач, Самарага юл алды. Сызрань, Самара, Тольяттида яшәүче милләттәшләребез ансамбль чыгышын яратып кабул иттеләр.

Үз чиратында Самараның "Ялкынлы яшьлек" ансамбле дә Казанда, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында концерт куйды.

"Татарстан" дәүләт телерадиокомпаниясе журналисты Дмитрий Нестеров Мәскәүдә узган Бөтенроссия "Спорт элитасы - 99" бәйгесендә иң яхшы өч журналист арасына керде.

"Елның иң яхшы журналистлык спорт проекты" номинациясендә ул "Спорт һәм допинг" телефильмы һәм Алисә Галләмова катнашында шахмат буенча дөнья беренчелеге матчының телевизион трансляциясен тәкъдим итте.

Австралиянең татарлар яши торган Аделаида каласында Татар-башкорт музее ачылды.

Музейны Австралиянең татар-башкорт җәмгыяте оештырган. Бүгенге көндә биредә Татарстан халкына яхшы таныш булган фотохәбәрче Нурислам Исмәгыйлев әсәрләреннән төзелгән фотокүргәзмә эшли.

Татарстан газета-журнал нәшрияты "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексы дигән яңа исем алды.

Нәҗип МАДЬЯРОВ

Әптән Гәрәе мәҗаралары

Р. Абзалов рәсемнәре.

Туеп беткән

Бер күршеләрендә туй вакытында, ишек алдына тәнәфескә чыккач, Әптән Гәрәенең хатыны скрипкәдә уйнап, Әхмәдишаны биетә икән. Әхмәдиша арый башлагач, Гәрәй алдына килеп тыпырдарга керешкән. Янәсе, биергә чык!..

- Башканы чакыр, хатынның мине үз кубызына биетүеннән өйдә дә туеп беттем инде, - дигән Әптәныч.

Ярамаган тагы...

Әптән Гәрәе унсигез яшьлек балдызын култыклап киного бара икән. Бу хәл аның күршесендәге йортта яшәүче Шәяхмәтнең күңеленә хуш килмәгән.

- Бик яшь бит, үзең алтынчы дистәгә киттең түгелме соң инде? - дигән ул.

- Ярамаган тагы безнең ишегә, - ди аңа Әптәныч.

Сөрмә галәмәте

- Хәснетдин, шушы да булдымы егетлек? - дип орыша икән Әптән Гәрәе күршесен. - Хатыныңны нигә шулкадәр каты кыйнадың? - Күз төпләре зәңгәрләнеп, кара көеп беткән бит.

- Сөрмә галәмәте ул, сөрмә...

- Сөрмә белән суктың ни, тимер белән ни - барыбер юньле хәл түгел инде, - дигән аңа Әптән Гәрәе.

Эзли

Әптән Гәрәе авыл буйлап, якягына карана-карана, нидер эзләп йөри икән. Бер әйләнгән ул урамнарын, ике әйләнгән. Шул ук вакытта ындыр артларына да күз төшергәләп ала икән. Аның болай тыз-быз йөрүенә гаҗәпләнеп, авылдашлары:

- Гәрәй, ни булды, шушы кадәр хафага калып, нәрсә эзлисең? - дип сораганнар.

- Һи-и-и, бәгырькәйләрем, кемдер капканы ачык калдырган да, хатын чыгып киткән, чәнчелгере! Дөнья бетереп, шуны эзлим, - дигән Әптәныч аларга.

Чәчләр чәчкә бәйләнсә

Бер пеләш кеше Әптән Гәрәенә килеп, моң-зарын сөйли икән:

- Абзыкай, мин әле нибары утыз ике яшьтә, әмма баш түбәмдәге чәчләрем коелып бетте. Шулай да, әгәр очып килеп кунса, чебен таеп егылырлык шоп-шома ялтыравык баш булуыма карамастан, бер бик чибәр кызга кызыгып йөрим. Әмма ул минем тәкъдимнәремне егермеутыз мәртәбә кире какты инде. Гәрәй ага, дим, дөресен генә әйт әле, шул сылубикә миңа кияүгә чыгар микән?

- Чәчләрегез чәчкә бәйләнсә, нигә чыкмасын, чыгар, - дигән аңа Гәрәй Әптәныч.

Юньсез мәчеләр

- Атасы, - ди икән Әптән Гәрәенә бервакыт хатыны. - Безнең өйалдындагы маебызны мәчеләр урлап ашаганнар бит әле...

- Юньсезләр икән алайса, - дигән Әптәныч аның кайгысын уртаклашып. - Соң ул майны аларга урламыйча гына ашап китсәләр дә ярый бит инде.

Остарып җиткән

Бервакыт Хәдичә түтинең ашы бик куерып киткән бит. Бу нәрсә әйтер икән, дип, ул иренең ашаганын күзәтеп тора икән. Әмма тегесенең анда-монда эше юк, ашавы ашау. Түзмәгән Хәдичә түти:

- Йә, ничегрәк соң? - дип сораган.

- Искиткеч яхшы, мондый тәмле ризык ашавымны һич кенә дә хәтерләмим. Бу дөньяда сиңа җиткән беркем дә юктыр, ботка пешерергә тәмам остарып җиттең, карчык, - дигән Гәрәй Әптәныч.

Белемен күтәрә

Әптән Гәрәе үзе язган дәфтәр, кәгазьләрне, укыган китапларын чормага менгереп киштәгә асып куя икән. Бу хәлне күзәтеп торган хатыны гаҗәпләнеп:

- Атасы, ни өчен алай эшлисең, нәрсәгә аларны чормага менгерәсең? - дип сораган.

Ә Әптәныч аңа болай җавап биргән:

- И, карчык, шуны да аңламыйсыңмыни? Үз белемемне күтәрү өстендә эшлим ләбаса.

Ашыгып алмаган

Әптән Гәрәе кармак белән балык тотканда үзенең өйләнгән вакытларын исенә төшереп, уйланып утыра икән. Шул мәлдә чиртә башлый да, ул тиз генә кармагын судан тартып чыгара. Әмма балык эләкми, төшеп кала. Бу хәлне күзәтеп яр өстендә торучы Шәяхмәт:

- Ашыгыбрак алдың син аны, Гәрәй, ашыгыбрак, - ди.

- Юкны сөйләмә, нишләп ашыгып алыйм, ул чакта мин егерме биш яшькә җиткән идем бит инде, - ди аңа Гәрәй Әптәныч.

Безнең кәҗәләр дә юкмы?

Әптән Гәрәе бала вакытта көтүдән кайтмаган кәҗәләрен эзләргә чыгып киткән. Караңгы төшкәнче эзләсә дә, тапмаган аларны. Үзем генә өйгә кайтсам, әти орышыр мине, дип, ул бер кешенең мунчасына кергән дә, ләүкә астында урын-җир әмәлләп, йокларга яткан. Шул вакыт мунчага ике карак кереп, шәһәрдә урлаган акча янчыгын тикшерә башлаганнар.

- Карале, моның эче бүлем-бүлем икән, - ди бер карак.

- Бер бүлем, ике бүлем, өч бүлем, - дип саный башлый икенче карак.

- Абыйла-а-а-ар, ул бүлемнәрнең берсендә безнең кәҗәләр дә юкмы-ы-ы? - дип кычкыра ләүкә астыннан Гәрәй.

Аны ишетүгә, караклар, җен галәмәтедер бу, дип, куркудан нишләргә белмичә, хәтта акча янчыгын төшереп калдырып, мунчадан чыгып тайганнар, имеш.

БӘЛКИ, ЯРДӘМЕ ТИЯР

Утын белән ягыла торган туз-ган су җылыту колонкасын ташларга ашыкмагыз. Ул әйбәт мич була ала. Моның өчен аның эченә өске су тишеге аркылы комкатнаш балчык салалар. Бу катнашма тузудан хасил булган тишекләрне каплый. Сыемның калган өлешенә дыңгычлап ком тутыралар һәм су парлары чыгып торсын өчен өске тишеген ябмый калдыралар. Су керә торган аскы тишекне әйбәтләп томалыйлар. Мондый мичтә җылы озак саклана.

* * *

Башланган банкада тозлы яшелчәләрне бозылудан саклау өчен су яки ком тутырылган полиэтилен пакет кулланырга киңәш ителә. Ул банка эчендә басым вазыйфасын үти. Ышанычлы булсын өчен пакетларны 2-3 кат итәргә кирәк.

* * *

Магнитофонның кыен үтеп керә торган җирләрен майлау өчен шприц энәсен файдаланырга киңәш ителә. Энә майлагычның томшыгын озынайту өчен файдаланыла. Энәнең нечкә булуы майны төгәл микъдарда кертү өчен уңайлы.



КРОССВОРД

Сулдан уңга: 7. Татар халык әкияте. 8. Г. Ибраһимов хикәясе. 9. Татарстандагы шәһәр. 11. Шатлык, сөенеч хисе. 12. Түбәне, түшәмне күтәреп торган сыман итеп ясалган ир кеше сыны. 13. Организмдагы күзәнәкләрнең протоплазмасын һәм төшен төзи торган төп материал. 16. АКШның көньягындагы шәһәр. 17. Җимеш агачы. 18. Кытайдагы автономияле район. 19. Шәһәр җәмәгать транспортын йөртүче. 21. XVI гасырда яшәгән Италия скульпторы, ювелир һәм язучы. 23. Авызлыксыз йөгән. 26. Сәнгать әсәрләрен халык алдында башкаручы. 28. Испан халкының милли биюе. 29. Ш. Камал повесте. 30. Акка күчерелмәгән язу-сызулар. 31. Тере организмның төзелеше турындагы фән.

Өстән аска: 1. Биек булып үскән чүп үләннәре. 2. Йомыш. 3. Йорт җиһазы, мебель. 4. Спортчы. 5. Бал кортлары өчен махсус торак. 6. Берәмлекнең бер яки берничә тигез өлешеннән төзелгән сан. 9. Тел турындагы фән. 10. Г. Кутуй драмасы. 13. Затлы металл. 14. Үсемлек кәүсәсе. 15. Өстенә такталар тезелә торган борыс. 20. Һава шары. 22. Татар галиме һәм язучысы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты. 24. Язгы чәчәк. 25. Агач саплы, тимер каптыргычлы йорт кирәк-ярагы. 27. Кимерүче хайван. 28. Кашсыз йөзек.

Төзеде: Ренат ГАЛӘВИН.

Журналыбызның 1 нче санында басылып чыккан сканворд җаваплары

Сулдан уңга: бармак, сыра, Ләйлә, төс, бала, ала, ай, ля, кияү, ир, кра, урак, рак, мәче, бра, Ык, ре.
Өстән аска: Кырлай, балта, мал, Илсөяр, йон, әти, бай, ни, бүрек, ликер, кам, кар, кер.

Февральский номер журнала открывается фотоочерком, посвященным сессии народных депутатов Республики Татарстан нового созыва, также журнал знакомит своих читателей с новыми руководителями Государственного Совета Татарстана.

February issue is opened by photo gallery dedicated to the session of Tatarstan people's deputies of new convocation, the magazine presents to its readers new leaders of State Council I of Tatarstan.

Далее журнал предлагает статью Председателя Госсовета РТ Ф. Х. Мухаметшина, которая посвящается шестилетию Договора России и Татарстана "О разграничении предметов ведения и взаимном делегировании полномочий между органами государственной власти РФ и РТ". Автор подчеркивает важность этого исторического документа в развитии федерализма в новой демократической России.

Further, the magazine offers the article of State Council Chairman F. Mukhametshin devoted to the 6th anniversary of the Treaty between Russia and Tatarstan "On demarcation of subjects of management and mutual delegation of authorities between state bodies of Russian Federation and Republic of Tatarstan. The author underlines the importance of this document in development of federalism in new democratic Russia.

Целый блок статей отводится сельскохозяйственной теме. Начинается он беседой нашего корреспондента с заместителем Премьер-министра, министром сельского хозяйства и продовольствия М. Г. Ахметовым, где он подчеркивает перспективы и недостатки сельского хозяйства. "Надо в корне менять отношение к земле", - говорит министр.

A number of articles cover agricultural topics. It starts from the conversation of our correspondent with vice-premier, minister of agriculture M. Akhmetov where he dwells on perspectives and drawbacks of Republican agriculture. " One must entirely change the attitude to land" - minister says.

Т. Авдеева касается темы налоговой политики. Налоговая система должна строиться в зависимости от того, насколько много произведено продукции и как она реализуется. При сборе налогов должны быть учтены собственность налогоплательщика, его доходы и т.д. И вообще, налоговая политика России должна быть такой же, как принято в развитых странах мира, так считает автор.

T. Avdeyeva touches the problems of tax policy The tax system should be built in connection with how much output was produced and how it is being traded. While tax collection, the property of taxpayer and his earnings must be taken into account. And more, the tax policy in Russia should be similar to European countries, author thinks.

Рубрику "Событие века", которая посвящена Октябрьской революции, продолжает академик И. Тагиров. Автор рассматривает, как татары относились к этому историческому событию, все ли татары поддерживали ее, были ли ее противники. И все же в этой революции татарский фактор был заметный.

The section "Events of Century" dedicated to October Revolution continues academician I. Tagirov. The author analyzes how Tatars perceived this historic event? Whether all Tatars supported it and what about its opponents. Anyway Tatar's trace in this revolution was quite remarkable.

В рубрике "Человек века" академик Ф. Мусин широко представляет выдающегося писателя, общественного деятеля Гаяза Исхаки, который всю свою жизнь боролся за самоопределение татарского народа, выражал его чаяния и стремление к свободе.

In the section "Man of Year" academician F. Musin speaks widely about outstanding public figure Gayaz Iskhaki who for all his life had struggled for self-determination of Tatars, their aspiration to freedom.

Отрывки из книги Я. Шафикова "Фикрат Табеев" продолжают знакомить читателя с интересными фактами и событиями жизни и деятельности бывшего первого секретаря Татарского обкома КПСС Ф. Табеева.

The passages from the book by Ya. Shafikov "Fikrat Tabeyev" continues to acquaint the readers with interesting facts and events from the life and activity of former first secretary of Tatar Regional Communist Party Leadership F. Tabeyev.

60-летию со дня рождения известного артиста театра имени Г. Камала А. Шакирова посвящена статья Ю. Сафиуллина, где он подробно анализирует творчество этого своеобразного актера.

The article of Yu. Safiullin devoted to 60th birthday of famous Kamal theatre actor A. Shakirov. The author describes life and creativity of this talented master.

Также журнал публикует стихи Зульфата, дает обзор культурной жизни республики.

The magazine prints also the verses by Zylfat and gives cultural outlook of the Republic.

ТАТТЕЛЕКОМ

предлагает услуги электронной цифровой АМТС

- междугородные и международные разговоры по автоматической связи
- сервис услуг автоматической связи по прямому междугородному телефону
- сервисное обслуживание по немедленному расчету за междугородные и международные разговоры гостей гостиничного комплекса г. Казани и райцентров Казанской зоны
- дополнительные услуги по автоматической международной связи:
  - прямая связь со страной;
  - бесплатный телефон
- предоставление междугородных и международных разговоров с таксофонов

ТАТТЕЛЕКОМ

предоставляет в пользование

- каналы тональной частоты, цифровые каналы с различной пропускной способностью
- телеграфные каналы AT50/TELEX (до 200 бод)
- студию для проведения селекторных совещаний

Телефон для справок: 36-08-24

ТАТТЕЛЕКОМ

весь мир в телефонной трубке

КИЛӘСЕ САНДА

Безнең индекс - 73377

“Өченче дулкын” лидеры

Сиксәненче еллар азагында башланган милли күтәрелеш татар халкының рухын яңарту, аның дәүләтчелеген кайтару юнәлешендә мөһим адымнар ясарга мөмкинлек бирде. Бу чор кыю рухлы, үткен һәм туры сүзле күп кенә милләтпәрвәрләрне киң сәяси аренага чыгарды. Татар милли хәрәкәтенең лидеры, галим һәм сәясәтче, Татарстанның халык депутаты Марат Мөлеков әнә шундыйлардан иде. Журналыбызның киләсе санында тарих фәннәре кандидаты Дамир Исхаков “өченче дулкын” татар милли хәрәкәтен җитәкләгән Марат Мөлеков шәхесе турында үзенең истәлекләре һәм уйланулары белән уртаклаша.